Ил йолдызы
Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006
УДК 821. 512.145.0
ББК 83.3(2Рос=Тат)
И45
Җыентыкны төзүче, искәрмәләр һәм аңлатмаларны язучы
*ЗӨФӘР МӨХӘММӘТШИН*
**Мөхәммәтшин З.Г.**

Ил йолдызы: Татар мөһаҗирләре матбугатында Габдулла Тукай / Төз. З.Г.Мөхәммәтшин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 190 б.

ISBN 5-298-03939-1

Г.Тукайга багышланган башка басмалардан аермалы буларак, җыентыкта бөек шагыйребез турында милли мөһаҗәрәтебезнең— эмигрантларның төрле матбугат органнарында басылган истәлек язмалары һәм хәбәрләре тупланган. Моңарчы киң даирә китап укучыларга билгеле булмаган бу материаллар күпләрнең дикъкатен җәлеп итәр дип уйлыйбыз.

ISBN 5-298-03939-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Мөхәммәтшин З.Г., төзү, 2006

## КЕРЕШ СҮЗ

Берничә меңьеллык тарихы булган милли-мәдәни цивилизациянең бер өлешен тәшкил иткән татар әдәбияты узган юл инде мең ел белән исәпләнә.

Аның тарихында XX гасыр аерым бер әһәмияткә ия. Тирән иҗтимагый үзгәреш-әверелешләр, дөньякүләм низаглар, сугышлар, кешелек дөньясын тетрәткән фаҗигаләр, афәтләр — болар барысы да шул йөз ел эченә сыйган һәм шактый ук дәрәҗәдә аның йөзен билгеләгән. Әлбәттә, әдәбият дөньясы да олы коллизияләр, инкыйлаблар кичергән. Искедән баш тарту, аны онытып яңа, «дөнья күрмәгән» мәдәният, шул исәптән әдәбият тудыру — XX гасыр башы өчен типик омтылыш, аңа үтә хас булган тенденция. Милли әдәбиятыбыз бигрәк тә 1905—1907 ел революциясеннән соң кискен үзгәрә, аңа чит-ят идеологик агымнар килеп керә. Шулар диңгезендә батмыйча шигърият һәм нәсернең милли йөзен саклап калу әдипләребез алдына иң мөһим бурычларның берсе булып баса. Ул ни дәрәҗәдә үтәлдер, анысы — махсус тикшеренүләрне сорый торган бик җитди мәсьәлә. Һәрхәлдә XX гасыр башы әдәбиятыбызның тирән кризис кичергәне ачык. Ул елларда аның бер уңай, бер тискәре яклары күренде, әдәбиятыбыз вакыт-вакыт зәһәр зәкъкум агачын, вакыт-вакыт кәүсәр чишмәсен хәтерләтте, күп яктан отты, байтак җәһәттән оттырды.

Татар шигъриятенең алтын таҗы, титаны Габдулла Тукай нәкъ шул чорда яшәде, кыска гына гомерендә үз халкының моң-зарын, хәтерләргә сеңгән тарихи үткәнен, аның фәлсәфи фикерләвен әсәрләрендә гәүдәләндерде дә. Икенчедән, чын лирик, фәлсәфи, халыкның бөтен фаҗигасен, хәтта бу очракта милли фаҗигасен бөтен тирәнлеге белән ачып биргән шагыйрь үзе дә зур тетрәнү кичерергә тиештер. Өченчедән, талантлы шагыйрь булу өстенә маңгай тирләрең акканчы хезмәт итү дә сорала бугай. Дүртенчедән, бишенчедән... Бу саннарны шактый дәвам итәргә мөмкин. Ни генә әйтсәң дә, шигърияттә генә халыкның җаны аша чыккан эчке кичерешләре, зары, шатлыгы, уй-хисләре, кайгы-хәсрәте бар тирәнлеге белән чагылыш таба ала. XX йөз поэзиясенең патшасы Тукай исә шуларны сәнгатьчә югарылыкта тасвирлауга иреште. Сәяси вазгыять бертуктаусыз үзгәреп торган заманнарда Тукай тудырган шигърият патшалыгына төрлечә бәя бирелде, хәтта үзе исән вакытта да шагыйрьлек таҗын төшерергә тырышучы шәхесләр дә табылды, әмма шуңа карамастан гасырның титаник фигурасы, татар кайда гына яшәмәсен, халык үзе таныган сыйфатта — халык шагыйре булуыннан туктамады.

* * *

Үткән XX гасыр шулай ук, бер караганда, тоташ мөһаҗирлек гасыры. Халыкларны мәҗбүри дә, ихтыяри-мәҗбүри дә туган җиреннән, рухи Ватаныннан аерган гарасатлы XX гасыр. Мәгълүм ки, Октябрь инкыйлабыннан соң Россиядән 2 миллион кеше чит илгә китә, 20 нче еллар урталарында башланган сәяси репрессия нәтиҗәсендә СССРның төрле почмакларына төрмәләргә сөрүләр, Ватан сугышы, шуларга өстәп мәңге бетмәс «гигант» төзелешләр, инде икмәк бирүдән гаҗиз калган «чирәм җирләр»... Халыклар сөрелделәр дә, сибелделәр дә. Шул дәһшәтле гасырның барлык фаҗигаләрен үз җилкәләрендә татыган һәм рухи мирасыннан баш тартмаган болгар-татар милләтен Тукай фигурасы бергә җыйган, бергә туплаган. Алар өчен шагыйрь шәхесендә, аның иҗатында калку күтәрелгән хис һәм фикер берлеге, миллилек мотивларының гәүдәләнеше халыкны бер йодрыкка тупларга, милли хис тәрбияләргә, телне сакларга

этәргеч биргән. Бу тенденция, 30–40 нчы елларда мөһаҗирлектә нәшер ителгән «Яңа милли юл» журналында (Берлин, 1928–1939), «Милли байрак» (Мукден, 1935–1945) гәзитендә һәм «Казан» (Төркия, 1970–1980) журналында Тукайга багышлап язылган шигырь яисә мәкаләдә булсынмы, шагыйрьнең туган һәм үлгән көннәрен искә алу кичәләрендәме, һәрьяктан ассызыклана.

Тукай татар өчен кем? Ни өчен шагыйрь шәхесенең фаҗигале язмышы милли фаҗига буларак яңгыраш алган? Үз Ватанында аңа вакыт-вакыт «революционер», вакыт-вакыт вак буржуаз шагыйрь исемнәре тагылганда, ни сәбәпле ул мөһаҗирлектәге татар өчен чын милли шагыйрь буларак тәкъдир ителгән?!

Шагыйрь иҗатына карата басылган мәкаләләр, аңа багышлап уздырылган кичәләр турындагы язмалар белән танышканда, «Ни өчен Тукайның туган көне түгел, бәлки вафат булуы искә алына?» дигән сорау борчыды. Дөрес, халыкның борынгыдан килгән традициясе буенча, кешенең үлгән көнен искә төшергәннәр. Ләкин монда сәбәпләр башка икән. Мөһаҗирлек тормышын сайлаган милләттәшләрнең кулларында бөек шагыйрь хакында материалларның аз булуы (үләр алдыннан үзе төзеп калдырган «Мәҗмугаи асаре» (1914), аңа Җ.Вәлиди язган кереш мәкалә, кайбер истәлекләр, мәкаләләр, туган көнен төгәл күрсәтүгә мөмкинлек бирмәгән. Рокыя Мөхәммәдиш 1936 елда бастырган «Тукай көне» мәкаләсендә түбәндәгечә яза: «...Тукай вә аның иҗаты төбенә кадәр дәвам ителгән, тикшерелеп беткән бернәрсә түгел. Иң гади генә кешенең тормышында да мәгълүм булган көн Тукай тормышында мәгълүм түгел. Без бүгенгә кадәр шагыйребезнең кайсы айда, нинди көндә тууын да әйтә алмыйбыз. Ул үзе дә, «ятимлек тормышым кайчан башланса да башланган инде» дигән кебек, үзенең «Исемдә калганнар»ында бу хакта бернәрсә дә язмый. Җ.Вәлиди мәкаләсендә дә бер сүз әйтелми». «Яңа милли юл» һәм «Милли байрак»та басылган чыганаклар шуны раслый. Күренекле галим Миркасыйм Госманов инде 1946 елны Шәркый Төркестанда Г.Тукайның 60 еллыгын билгеләп үтүгә әзерлек баруын, әмма сәяси вазгыятьнең үзгәреп китүе сәбәпле, бу бәйрәмнең 1947 елга күчерелүен хәбәр итә (Госманов М. Ябылмаган китап. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. — 146–150 б.). «Казан» журналында урын алган материаллардан күренгәнчә, мөһаҗирлектәге татар диаспорасы Тукайның туган һәм вафат көннәрен дә тиешле югарылыкта билгеләп үткән.

Туган туфрагыннан, рухи мирасыннан аерылган милләт вәкилләре, телиме-теләмиме, вакытлар узу белән, Ватаныннан читтә, башка халыклар арасында йотылырга, йомылырга мәҗбүр. Бу хәл булмасын өчен мөһаҗирлектәге татарларның Тукай шәхесенә, иҗатына кат-кат мөрәҗәгать итүләре шуны раслый. Беренчедән, читтә телне саклап калу, икенчедән, рухи бердәмлекне югалтмау бурычы тора. Бу мәсьәлә бигрәк тә Ерак Шәрыкта һәм Төркиядә яшәүче татар диаспорасына кагыла. Әлеге проблеманы Хөсәен Габдүш «Тукай һәм яшьләр» исемле мәкаләсендә менә ничек күрсәтә: «...туган телебезгә күңел бирүдә түбәннән җимерә торган сәлби бер хәл бар, ул да, аянычка каршы, ата-аналарыбызның кайберләре арасында «Татарча укып ни чыга?» дигән бер бозык карашның урын алып, шуның балалар, яшьләр дөньясында куертылып торуыдыр. Әҗнәби телләрне өстән-өстән генә түгел, бик яхшылап өйрәнүнең кирәклеге хакында ике фикернең булу ихтималы юктыр. Аларны өйрәнүдән «икмәк ашау» мөмкинлеге күз алдыбызда. Ләкин шуның белән бергә үз телеңне оныту, онытуны кимчелектән санамау, йомшак әйткәндә, бик түбәнлектер». Шагыйрь иҗаты мөһаҗирлектәге татар яшьләрендә һәм балаларында туган телгә мәхәббәт уятуда һәм милли хисне югалтмауда бер чара буларак файдаланганлыгы ачык күренә. Бу чаралар, никадәр генә каршылыклар, авырлыкларга очрамасын, нәтиҗәсез калмаган, әлбәттә. Мәсәлән, Шәмсия Апакай 1975 елны Казанга сәфәре вакытында Тукай булган урыннарны күрүен искә ала. Ул: «Туганнарым белән очрашу, алар белән булган сөйләшүләремнең берендә мәшһүр шагыйрь, бала чагыбыздан күңелебездә урын алган Габдулла Тукай белән бәйле җирләрне күрергә теләгәнемне сөйләдем», — дип яза. XX йөзнең 80 нче еллар урталарында башланган сәясәттәге уңай якка үзгәрешләр тәэсирендә дөньяга сибелгән татарларның, рухи Ватаннарына кайтып, әби-бабалары эчкән чишмә суын эчүләре, туган туфракның җылысын тоюлары — туган телгә мәхәббәтнең сүнмәвен, милли хиснең саклануын күрсәтүче мисаллар.

Милләтнең ачы язмышына әверелгән Тукай, кайда гына, нинди генә шартларда яшәүгә карамастан, бервакытта да игътибардан читтә булмады, һәрвакыт үзәк фигуралардан саналды. Ләкин шул югарылыкны саклау өчен шигъри әсәрләрен бастыру, төрле аспектта бәя бирү, халык традицияләренә нигезләнгән бөек Тукай шигърияgreen буыннардан буыннарга тапшыру сорала. Мөһаҗирләр өчен шагыйрьнең иҗатын җентекле өйрәнү дә, әсәрләрен нәшер итү дә — кул җитмәслек авыр мәсьәләләрнең берсе. Шулай да, күз курка — кул эшли дигәндәй, теләгең бар икән, максатка ирешү өчен юлларын табарга мөмкин. Тукай җыентыкларын чыгару никадәр генә тормышка ашмас проблема булып күренсә дә, татар мөһаҗирләренең күпчелеге яшәгән Ерак Шәрык диаспорасы Тукайның үлүенә 20 ел тулган көннәрдә бер көнлек газета, җыентыклар бастыру, шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү нияте белән ашкынып йөрүләре — шатлыклы хәл, әлбәттә. Шуңа карамастан, матди чыганакларның аз булуы, татар диаспоралары арасындагы бәйләнешнең әле җитәрлек дәрәҗәдә түгеллеген искә алып, Г.Исхакый «Тукай истәлеге» мәкаләсендә шагыйрьнең «Мәҗмугаи асаре»н кабат бастыру иртәрәк дип саный. Ул: «...аның «Мәҗмугаи асаре»н бастырырга безнең мөһаҗәрәттә матди көч юк дигән фикердәбез. Аның кайбер әсәрләрен аерым-аерым бастыру һәм Тукайга багышлап бер китап, бер мәкалә җыентыгы чыгару эше кала», — дип яза. Ничек кенә булмасын, 1933 елда Токиода Тукайның «Мәҗмугаи асаре»нең тулы басмасы дөнья күрә. Тукайның үлүенә 25 ел тулган көннәрдә Мукден шәһәрендә «Тукай рисаләсе»н бастыралар. 20 мәкалә һәм күп кенә шигырьләрен эченә алган 98 битле җыентык Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татар җәмгыятенең мәркәз әгъзалары Хөсәен Биглитси һәм Сабир Җиһаншаһларның матди ярдәмендә нәшер ителә. Мәктәп дәреслекләре төзеп бастырганда да, Тукай шигырьләре беренче урында торган. XX йөзнең 40 нчы елларында Олуг Төркестанда да Голҗа татарларының матди ярдәме белән Тукай җыентыгы басылып чыга (Госманов М. Күрс. хезм.). Бу традиция татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә соңрак та дәвам итә. Бер мәкаләдә аларның һәрберсен атап үтү мөмкин эш тә түгелдер, мөгаен. Югарыда атап үткәнемчә, 1933 елда Ерак Шәрык төрк-татарлары Тукай шәхесен мәңгеләштерү уе белән карар кабул итәләр. Аның маддәләре түбәндәгечә:

1. Тукай исеменә Аурупа яки Азиядә булган югары мәктәпләрнең берендә, Ерак Шәрыктагы барлык оешмалар белән берләшеп, бер стипендия ачу;

2. Мәхәллә хозурында бер Тукай бүлмәсе ачу.

3. Тукай исеме белән һәр ел аның үлгән көнендә ана телендә иң оста язылган әдәби әсәргә мөкяфәт бирү өчен фонд төзү;

4. Балаларга махсус Тукай әсәрләреннән кечкенә генә бер рисалә нәшер итү.

Дөрес, еллар үтү белән моның белән генә чикләнми шагыйрьне мәңгеләштерү, Тукай клублары төзелә, Тукай исемендә китапханәләр барлыкка килә.

Мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр булган татар халкы Ватанының бәйсезлеген күрергә тели, шуңа омтыла. «Яңа милли юл» журналы һәм «Милли байрак» гәзитендә басылган һәрбер мәкаләдә, шул исәптән Тукай иҗатына караганнарында да, татарның милли бәйсезлеккә ирешүенә ышаныч, рус дәүләте тарафыннан үткәрелгән милли сәясәткә ризасызлык ярылып ята. Өметен өзмәгән татар үзенең дини-милли һәм мәдәни киләчәге өчен көрәшне мөһаҗәрәттә дә дәвам итеп килә. Тукай шул көрәшнең башында тора. Аның образы аша милләтнең якты киләчәге күз алдына килә. Вакыт-вакыт халкының азатлыгын максат итеп куйган татар мөһаҗирләре өчен өметсезлек тә уятып куя. Шаһвәли Келәүле шигыренә игътибар итик:

Әй, Ватан, туган Ватан,
Иркәләп сөйгән Ватан!
Максаты мәрхүм шагыйрьнең
Җанланыр синдә кайчан?

Шул ук мотив Солтанның (Әхмәт Виргаз) «Тукай рәсеменә» дигән шигырендә сизелә:

Әй, татар, күрәмсең,
Моңлы карыйдыр күзләре.
Әй, татар, беләмсең,
Бу шагыйрь — ил корбаны.

Милли изү астында яшәгән татар өчен шагыйрь — ил корбаны. Бу фикер Хөсәен Габдүш, Гали Биктимер, Шакир Йосыф, Рокыя Мөхәммәдиш мәкаләләрендә яңгыраш ала. Сәгадәт Чагатай, Мәдинә Салиәхмәт исә, фикерләрен бернинди пафоска төрмичә, Тукай иҗатына милли аспекттан чыгып, дөнья мәдәни цивилизациясенең бер өлеше буларак бәһаләрен бирәләр. С.Чагатай, шагыйрьнең әсәрләрендә кайбер кимчелекләрне күргән хәлдә, бары яхшы шигырьләрен генә укучыга җиткерү кирәклеген ассызыклый. Тикшерү объекты итеп лирик-фәлсәфи, сәяси яктан әһәмиятле, халык арасында киң танылу алган шигырьләре генә алына, шуларга күбрәк игътибар юнәлтелә.

Шәхеснең таланты буш урында гына дөньяга килми. Нәселдән килгән традицияләрнең дәвамчылыгы, тирәлек, шәхес яшәгән чор талантның ачылып китүенә этәргеч бирә. Тукай талантын аның ятимлегенә, авыруына, кыска гомерле булуына бәйләп карау совет чорында аеруча ачык сизелде. Дөрес, ятимлекнең ачы хәсрәте бу очракта шагыйрьнең сәләте ачылып китүгә бер сылтау гына. Г.Тукай — мулла баласы. Җиде буыны асыл зат — мулла нәселе. Шуңа өстәп ул яшәгән тирәлек тә, ул аралашкан мохит тә шигъри талантның үсүенә ярдәм иткән. Р.Мөхәммәдиш түбәндәгечә яза: «...шагыйрьнең тормышы, иҗаты белән танышканда, иң төп нокта итеп аны чолгаган мохитне, аны тудырган халыкны, ул яшәгән әсир Идел буен алу кирәк булачак. Чөнки бер шагыйрьнең дә, бер язучының да иҗаты мохиттән тыш, тирә-якның тәэсиреннән тыш ясалмый. Үзләренең эчке халәте рухияләреннән тышка чыга алмаган шагыйрь һәм язучылар, өслүбләренең матурлыгына, телләренең садәлегенә карамастан, халык күңелендә урын таба алмаган кебек, халык белән бергә халык яшәгән кадәр үк яши дә алмыйлар».

Мәкалә авторы күрсәтеп үткәнчә, XX йөз башы шагыйрьләренең күпчелеге һәм соңрак шигърият мәйданына килгән шагыйрьләр, халыкчан әсәрләр тудыра алмау сәбәпле, укучы күңеленә үтеп керә алмадылар. Совет чоры әдәби тәнкыйтендә яисә гуманитар фәнендә шагыйрь иҗатында халыкчанлык, ул яшәгән тирәлек, мохит, нәселе хакында фикер әйтү акылга сыймаслык хәл иде шул.

Нишләмәк кирәк, әдәбият — әдәбият, шигърият шигърият буларак бернинди сәясәткә буйсынмыйча яшәргә лаек кебек тоелса да, тормышның кануннары башкача. Сәясәт корбанына әйләнгән шагыйрь шул кануннарны танырга теләмичә тарткалаша, буыла, түзә алмыйча юкка чыга. 1905–1907 елгы рухи күтәрелеш дулкыннарын күргән Тукай сәяси реакция елларында беркадәр өметсезлеккә бирелә, бу аның шигъриятендә, язмышында чагылыш тапмый калмады. С.Чагатай язганча, «хәзерге дәверебез, әдәбият дәвере булудан артыграк, көннән-көн сәяси дәвер була баргангa», үз Ватанында шагыйрь иҗатын бер күккә чөйсәләр, сәяси вазгыятьнең кинәт тискәре якка үзгәрү белән җиргә салып таптарга да күп сорамадылар. Мөһаҗәрәттә исә шагыйрь иҗатын саллы-саллы мәкаләләрдә югарыга күтәрергә теләсәләр дә, С.Чагатай әйткәнчә, «Тукайны коры хәтерләү аның хакында язылган иске сүзләрне тәкрарлаудан гыйбарәт булып каладыр». Ни генә булмасын, Тукайның титаник фигурасы, ул тудырган халыкчан бөек иҗат татар халкын гомумтөрки дөньяга гына түгел, бәлки дөнья мәдәни җәмәгатьчелегенә танытты.

*** * ***

Мөһаҗирлектәге татар диаспорасын бер йодрыкка туплауда әһәмиятле роль уйнаган Тукай кичәләре һәрдаим уздырылган һәм алар үз чиратында милли-мәдәни үзәкне тәшкил иткәннәр. Чыганаклардан күренгәнчә, Тукайга багышлап үткәрелгән кичәләрнең яисә мәҗлесләрнең географиясе шактый киң. 30–40 нчы елларда Ерак Шәрык дәүләтләре Япония, Кытай, Кореяның күп кенә шәһәрләрендә, Варшавада, Берлинда, Һельсинкида, Тампереда, Абода, Ка-

һирәдә, 70 нче елларда Әнкара һәм Истанбулда, Америка җирлегендә Тукай иҗатын искә алуны оештырулары мәгълүм. М.Госманов мәгълүматлары буенча, Голҗа шәһәрендә дә бу истәлек көнен һәр ел билгеләп узганнар.

Бер караганда, бары хәбәр бирү рәвешендә генә язылган булсалар да, бу материаллар тарихи яктан шактый үк мөһим. Шуны искә алып, Тукай кичәләренә тукталу урынлы шикелле тоелды. Ни өчен? Сорауга җавапны апрельнең 15 ендә Берлинда яшәүче милләттәшләребезнең шагыйрьнең үлеменә 20 ел тулу уңае белән уздырылган кичә турындагы хәбәрдән табабыз. «Саф, бик җыйнак эшләнгән бу чәй мәҗлесендә, Тукай җырларындагы шикелле үк, шатлык та, кайгы да бер үк авырлыкта тора иде. Халыкның үлмәс рухы, сүнмәс уты, сынмас гайрәте аны, нинди генә авырлыкка төшсә дә, тагы тартып чыгара. Ул аны бер генә минутка да өметсезлеккә төшерми. Менә монда читтә, тормышы һәм тормышының шартлары белән ятрак булган бер халык эчендә дә халкыбызның барысын да бергә җыйган, аларны бер үк теләк әйләнәсенә китергән бер уртак нәрсә бар. Бу — халыкның киләчәге өчен кыйммәтле бер нигез ташы, бу нигезне күрү безнең өчен шатлык. Кайгы — шагыйрьнең шигырьләренә моң биргән илнең, халыкның бүгенге хәле авырлыкта; анда рух та, сүз дә, уй да богауланган. Анда шагыйрьнең моңы да куначак урын таба алмый...» Нәкъ менә шул сәбәпләр Тукай исеме астында берләшүгә, чит халык, чит мәдәният тәэсире астында югалып калмаска чакырган.

Гадәттә, шагыйрьгә багышланган чаралар мәктәпләрдә үткәрелгән. Тукайның балаларга атап язылган шигырьләре укылган. Бу мәҗлесләрдән өлкәннәр дә читтә калмаган. Баштарак кичәләр бер-берсен еш кына кабатласалар, соңрак үзгә төсмерләр дә өстәлгән. Тукай иҗатына карата төрле темаларны эченә алган чыгышлар оештырылган, шагыйрьнең кайбер шигырьләренә сценарийлар төзеп, шуларны тамашачыга җиткерү, шагыйрьнең дә, милләтнең дә ачы хәсрәткә дучар ителгән язмышын гәүдәләндергән шигъри әсәрләрен татар халкының борынгыдан килгән көйләренә салып җырлау туган җирләреннән аерылып яшәүче милләттәшләрне, хыялда гына булса да, рухи Ватаннарына алып кайткан. Моңга сарылган мондый кичәләр, мәҗлесләр һәркемнең актив катнашлыгы белән узган. Тукай шигърияте өлкәннәр, яшьләрнең эчке кичерешләрендә илне сагыну хисен уятса, балаларда исә туган телгә ихтирамны, ата-ана телен сакларга кирәклеген сеңдергән милли горурлык, ватанпәрвәрлек миссиясен үтәгән.

Чыганакларны барлау һәм өйрәнү барышында һәрвакыт: «Ни өчен Тукай кичәләре генә оештырылган?» — дигән сорау бимазалап торды. Бу сорауга җавап Р.Мөхәммәдиш мәкаләсендә өлешчә табылган иде инде. Мөһаҗәрәттәге милләттәшләр Тукай язмышында үз язмышларын күргәнгә, шагыйрь шәхесенә, ул тудырган иҗат мирасына, башкалар белән чагыштырганда, өстенрәк урын бирделәр. Икенчедән, Тукай иҗатына гомер дәвамында ихтирамын югалтмаган, Идел-Урал төрк-татарының милли горурлыгы, лидеры Г.Исхакыйның да роле зур булгандыр, мөгаен.

Еллар да, гомер дә бер урында тора алмый. 40 нчы еллар уртасына кадәр гөрләп яшәгән Ерак Шәрык татар мөһаҗәрәте сәяси вазгыятьнең тискәре якка үзгәрү нәтиҗәсендә кризис хәленә төшә, бик күп милләттәшләр дөньяның төрле кыйтгаларына — читкә китәргә мәҗбүр ителә. Шул сәбәпле Тукай кичәләре уздырылу да туктала. Икенче бөтендөнья сугышы башлану белән Польшада һәм Германиядә гомер кичергән милләттәшләр дә Төркиягә, Америкага юл тоталар. Бары Финляндиядә яшәүче татарлар гына кабат күченүдән котылып кала. Милли горурлыгын саклаган, үзенең үткәненә ихтирамын сүндермәгән татар инде Төркиядә, Америкада, Австралиядә Тукай кичәләрен уздырырга керешә. Шул үк рух, шул үк дәрт белән халыкны бергә туплау йөзеннән милли кичәләр оештырыла. Аның башында һәрвакыт Тукайның үлмәс исеме тора. Ул, татар кайда гына, нинди генә шартларда яшәмәсен, халык яшәгәнчә яши, дөньяга сибелгән милләткә илһам бирүен дә дәвам итә.

Укучыга тәкъдим ителгән бу җыентыкта мөһаҗирлектә яшәгән, яшәүче милләттәшләрнең Тукай иҗатына мөнәсәбәтләрен белдергән шигырьләре, мәкаләләре яисә аңа багышлап уздырылган кичәләр турындагы хәбәрләр — барысы да бергә җыелып бетте, бергә тупланды, дип әйтергә иртәрәк. Бу эш әле башланды гына. Аерым мәкаләләрдән күренгәнчә, җыелачаклары тагын да күбрәк. Минем максатым татар халкы бөек Тукайны ничек олылавын, аны ничек хөрмәтләвен күрсәтү белән бергә аларны халыкка таныту да иде.

*Зөфәр Мөхәммәтшин*

**М.Х.Ф.**

## ТОРМЫШ САГЫШЫ

*Г.Тукайның үлүенә 20 ел тулды*

Шигырь — күңелдәге уйлардан сыгып чыгарылган бер уч тормыш.

Шагыйрь — үзенең йөрәгеннән ташыган уйларны калыплап, аларны, йөрәк каны берлә буяп, кояш күзенә чыгаручы.

Уйлар. Алар үзләре дә җиңел түгел.

Көннәрне — айлар, айларны еллар ясыйлар алар.

Алар аркасында яшь яңаклар саргая, өметле күзләр тона, утлы йөрәкләр сүнә...

Шул уйларны сыйпап үстерүче җылы йомшак тормыш нурлары булмаса...

Авыр уйлар янына уйлар күк үк (күгүк) авыр сагыш кушыла.

Сагыш — өмет-өметсезлекнең кушылуыннан туган эзләнү.

Тормыш, әйләнә-тирә күңел күрергә теләгән күк ямьле түгел, аның юлы меңнәрчә киртәләр берлә тулган.

Көннәрнең кояшы берлә төннәрнең йолдызлары арасында аһәң юк.
Ник?
Тормышның төп сере нәрсә?

* * *

Сорау тамгалары арта, арта, арта...
Алар башка сыймыйлар: ташыйлар, елга булып агалар...
Меңнәрчә еллардан бирле аның җавабын эзлиләр. Кешенең меңнәрчә еллык тарих юлы алар берлә тулган.
Мин аларга җавап бирә алырмынмы?
Юк.
Кирәкми дә!
Мин аны үзем ясыйм. Күңелемдәге тойгыларымны җыям да, аларны салават күперенең ямьле эзенә тезеп, үземнең юлымны түшим.
Үземә үземчә тормыш корам, юл сызам.
Узганның, киләчәкнең төпсезлеге нигә кирәк?!
Мин тормышны яратам.
Мин яшим!!!

* * *

Ашкынганнан күңел читлектән чыга, дөньяны коча.
Күбәләк күк очып,
Чәчәк күк үсеп,
Күкнең киңлегендә үзенең моңын, куаныч моңын үрә башлый...
Кояш нуры — аның юлдашы.
Аккан су — аның җырчысы.

* * *

Көннәр үтә, кояш нурлары суына. Җәй китә. Көз килә.
Кышның суык карлары җирне баса.
Күңелнең юлдашлары язмышның тимер кулыннан буылалар.
Ялгызлык башлана...
Күңел моңлана.
Югалту моңы йөрәкне сара.
Аның ачысы күзләрдән чыга!..
Тормыш кыска,
Ашкынган күңелнең,
Омтылган йөрәкнең юлы...

**Шаһвәли Келәүле Илдәр***

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙГА

Безгә калдырдың, шагыйрь, син мәгънәви бетмәс азык,
Якты нур кебек мәңге сүнмәс җанлы шигырьләр язып.
Халкыбызның тормышында күп җитешсезлек табып,
Юк, алай түгел, болай, дип, якты юллар күргәзеп.
Милләтнең тәмам сүнеп барган вакытта пыр тузып,
Ялтырап чыктың кояш кебек, безнең өскә нур сызып.
Милли егылган халыкка зур ышаныч кергезеп,
Моңлы, җанлы шигырең илән барчабызны тергезеп.
Син көрәштең халкыбызга аң-белем бирмәк өчен,
Киң тәрәкъкый юлларына милләтең кертмәк өчен.
Яшь буыннар шигыреңнән милли тойгы, дәрт алып,
Милли байрак көрәшчеләр мәйданә чыксын өчен.
Син, шулай балкып чыгып, безгә аң биргән вакыт,

Милләтемне пакьлим дип, зур план корган вакыт.
Сынды кылыч, бетте көчең керләнеп, авыру ятып,
Зур тәәссеф ташладың син, безне кан-яшь егълатып.
Әй каһарман милли шагыйрь! Яшьли киттең дөньядан,
Файдалы орлык чәчеп син безгә бүләк ядкарән.
Әй Раббым! Ник соң алдың яшьли аны дөньядан?
Ачы авазлар белән без яд итәбез һәр заман.
Аерылып китсәң дә бездән, данлы шагыйрь, мәңгегә,
Калды эшең һич югалмас тарихи милләткә.
Бар төрк-татар бу көндә баш иябез рәсмеңә,
Рухыңа оҗмах телибез һәр догада Тәңрегә.

**Солтан (Әхмәт Виргаз)**

## ТУКАЙ РӘСЕМЕНӘ

Әй, татар, күрәмсең,
Моңлы карыйдыр күзләре.
Әй, татар, беләмсең,
Бу шагыйрь — ил корбаны.
Илле яшь тулды аңар,
Картаймый аның җырлары.
Ялтырап анда ятадыр
Халкыбызның моңнары.
Аңлата алмабыз халкыбызның
Аһларын, моң-зарларын.
Җырлый алмам мин аларның
Күңелгә ниләр салганын.
Әйт үзең, әйтче шагыйрь!
Тыңлыйм сөалемә җавап...
Чәнечкели күңелемне уйлар,
Сын кебек торам карап.

**М.Ф.**

## ТУКАЙ ӨЧЕН

Тулды инде утыз ел да
Синең вафат булуыңа;
Бүген милләт дога кыла
Синең газиз рухыңа.

Төште иртә бик [...]*
Алтын каләм ак кулыңнан;
Ни эшләргә чарабыз юк,
Килә язмыш бер Ходадан.

Язган моңың — шигырьләрең —
Үзең өчен түгелдер.
Аңлый алса безнең халык,
Бар да милләт өчендер.

Яшьли бигрәк, бигрәк яшьли
Ташлап киттең безне син.

Арабызда рух йөрде,
Ләкин үзең түгел син.

Узды инде бик күп вакыт,
Үтәр әле күп еллар;
Бәхетсезгә, бәлки, безнең,
Туар синдәй шагыйрьләр.

Төрк-татарың горурланып
Торганы тик син идең.
Милләтне нурландырып
Тотканы да син идең.

Ят син инде тынычланып,
Булсын газиз рухың шат.
Милләтең дә синең тиздән
Булыр тыныч (вә) рәхәт.

**Солтан (Әхмәт Виргаз)**

## ШАГЫЙРЬГӘ

Китсә дә еллар агып,
Картаймый аның җырлары.
Чөнки анда яңгырыйдыр
Халкыбызның моңнары.

Кайнап чыккан мәгърур ут диңгезен
Йөзеп чыктың илнең юлында.
Кара тормыш, золмәт арасында,
Йолдыз кордың изге юлыңда...

Куркытмады көчле, яшь шагыйрьне
Куркынычлы үлем уйнавы.
Күкрәгенә уклар кадалса да,
Эзләдең син якты юлларны.

Караңгы, тар, суык бүлмәләрдә
Михнәткә син яттың төренеп.
Әйтче, шагыйрь! Сиңа карадымы
Язгы кояш көлеп һәм сөеп?!

Халык арасында эзләдең син
Илне ачарга бәхет ачкычы:
Караңгыда битең чәчәк кебек,
Күрә алмадың кояш яктысын.

Канлы көннәр үтәр... Еллар китәр,
Иленең бәхте беркөн ачылыр.
Бер кайгыда синең, бер шатлыкта
Илкәй сине мәңге сагыныр!

**Шаһвәли Келәүле Илдәр**

## ТУКАЙ ЭЗЕННӘН

Кич белән беркөн Ватанга
Мин дә киттем уйланып.
Ник Тукай ямьле Казанга
Юлда барган моңланып?
Мин шулай да юнәлсәм
Туп-туры илгә карап,
Һич Тукайсыз ямь табалмыйм,
Сүзләрен алам талап.
Иң бөек халык шагыйре,
Кайда ул ямьле Казан?
Кайда ул мәсҗедләреңдә
Иштелә моңлы азан?
Кайда пар ат? Кайда калфак?
Кайда алтын балдагың?
Барсы бетте, милли шагыйрь
Җанланырмы бер тагын?
Бетмәде золмәт һаман да,
Кипмәде тир җәбһәдә.
Ул синең сөйгән Казанда
Милли һәр эш шөбһәдә.
Тик синең белән пар ат та
Ирекле ил, ямь бирә.
Шул матур моңлы азанда
Ил якын, якын килә.
Әй, Ватан, туган Ватан,
Иркәләп сөйгән Ватан!
Максаты мәрхүм шагыйрьнең
Җанланыр синдә кайчан?

## ИЛ ЙОЛДЫЗЫ

Әнә офык аша балкып тора
Якты йолдыз — илнең бизәге.
Карап аңа күңел моңга тула,
Җыламыйча йөрәк түзәме?

Ил йолдызы диеп без таныйбыз
Сине, бөек шагыйрь, бу көндә.
Сызган юлларыннан һәм карыйбыз —
Син торасың илнең күгендә.

Син идең бит, шагыйрь, дәртең белән
Халык уртасында гизүче;
Ярлы, ятим, сынык күңелең белән
Ил моңнарын сызып бирүче.

Хәтереңдәме? Илнең чүп-чарларын
Син тазартып безне пакьләдең.
Ерак торып калган ил даннарын
Җир казыгыч белән җанладың.
Бар иде бит заман безнең илдә
Җитешмәгән караңгылык дөньясы.
Имеш: «Дию-пәри, фәлән
Ыжгырадыр, абау, ун башы».

Балкып чыктың, шагыйрь, шул арада,
Якты йолдыз кеби нурланып.
Бөтен дию-пәри шау-шу кага,
Үлеп бетте шунда хурланып.

Авыр йөкне син таратып киттең,
Бөек шагыйрь, илнең баласы.
Шиңгән чәчәкләргә сулар сибеп,
Күренми һәм суның анасы.

Ил йолдызы сүнмәс, якты янар,
Ил догасы белән бизәлер.
Шигырьләреннән халык азык табар,
Яктылыктан мәңге тирбәлер.

Баш иябез шагыйрь рухына,
Ялварабыз бөек Тәңрегә:
Кертсен изгелекләрнең горуһына,
Оҗмах итсен урның мәңгегә!

**Сания Ишыкай**

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙГА
## 90 ЯШЬ ТУЛУ УҢАЕ БЕЛӘН

Тарих сәхифәләре ничә онытылмас исемнәре белән
тулгандыр,
Кыска вакыт гомере белән болардан бере дә
Габдулла Тукайдыр.
Ул туксан елдыр күңелләрдә яшәгән, янә яшәячәктер,
Халкының кояшы, нуры, мәңгелек символы һәм баш таҗыдыр.

Мәмләкәт мәхәббәте, бәйсезлекне ишетү аның шигырьләрендә,
Халкыны болар белән туендырды милли рух
алгарышларында.
Хәтерләрне бизәкләде, зиһеннәрне ныгытышты Тукай,
Танылып хөрмәтләнде, сөелде,
халкы күңелендә мәңгеләште Тукай.
Туксан елдыр аңа, рухларда бәрабәр, иртәгесе көн дә
бәрабәрдер,
Еллар соңында да халкының күңелендә янә ул милли
лидердыр.
Үлмәде, үлмәячәк улан , мәңгеләшкән бер даһидыр ул,
Бөек шагыйрь, язучы, миллиятчелектә исә Илаһига тиңдер ул.

**Миннаҗ**

## ДАҺИ ТУКАЙНЫ ИСКӘ АЛУ

Һәр милләтнең була йолдызлары,
Һәр милләтнең була зурлары,
Һәр милләтнең була халкын сөйгән

Каһарманнары, батыр уллары.

Тукай да бит безнең якты йолдыз,
Тукай да бит безнең улыбыз.
Караңгыда якты нурын чәчкән
Абдулла да безнең зурыбыз.

Караңгылык баскан Идел буе
Тукай килгәч куәт-көч алды.
Тукай безгә якты маяк булды,
Тукай бит ул безгә юл салды.

Сукырларны син бит күз иттең,
Наданнарны керттең ак юлга.
Синең Сак-Сокларны, Кара Әхмәтләрне
Мин йөртәмен һаман кулымда.

Күз алдыма килә пар ат белән
Казан каласына килгәнең.
«Болгар» номерында матур итеп
Милли көйне җырлап йөргәнең.

Печән базарын да искә алам,
Искә алам Болак буйларын.
Бертуктамый сине уйлап йөрим,
Синдә генә бөтен уйларым.

Шүрәлең дә һаман бертуктамый
Күз алдымнан китми әйләнә.
Су анасы йөгерә әйләнәмдә,
«Бир тарагым» диеп бәйләнә.

Кырлай авылын да төштә күрәм,
Сак-Сокларың белән маташам.
Төннәремдә һаман бертуктамый
Карәхмәт белән саташам.

Окопларда туплар шартлаганда,
Синең җырларыңны ятладым.
Кабан буйларын да бик күп уздым,
Тик үзеңне генә тапмадым.

Авыр минутларда синең җырың
Юлдаш булды минем юлымда.
Һаман саклап килдем җырларыңны,
Бүген дә әле менә кулымда.

Алар миңа авыр минутларда
Көч бирделәр, саклап калдылар.
Көрәш кырларында, алгы сафта
Минем белән бергә бардылар.

Ялгыз калган кыен чакларымда
Синең белән бергә йөри идем.
Сиңнән илһам алып, гайрәтләнеп,
Авырлыкны сизми, белми идем.

Синең җырың белән коралланып,
Җырлап үттем бик күп илләрне:
Азия, Африка, Аурупаны —

Белмим тагы күпме җирләрне.

Син теләдең
Якты көннәр, таңнар атуын.
Теләмәдең мескен милләтеңнең
Пәрдә корып йоклап ятуын.

Армый-талмый, һаман җиң сызганып,
Алга таба армый атладың.
Бөтен гомерең үтте халкың өчен,
Башкалардай йоклап ятмадың.

Син җырладың безгә матур итеп
Халкыбызның матур җырларын.
Мактап илебезнең урманнарын,
Сахраларын, болын-кырларын.

**Гаяз Исхакый**

## ТУКАЙ ИСТӘЛЕГЕ

*Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә*

Тиздән керәчәк булган 1933 ел безнең өчен бик зур тарихи көннәрне эченә ала. Бөтен төрк (төрки) дөньясына каратып, «Телдә, фикердә һәм эштә берлек» шигаре берлә чыгарыла башлаган «Тәрҗеман» гәзитенә бу елда 50 ел тула.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы, —

дип яза башлаган халык шагыйре Габдулла Тукайның үлүенә дә бу елда 20 ел тула. Аның, соң шигырен язып:

И мөкаддәс моңлы сазым! уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрыламыз, ахрысы, —

дип, үзенең шагыйрьлек тормышына нокта куелганына 1933 елның 15 апрелендә 20 ел тула.

Исмәгыйль Гаспринский бөтен төрк иленең уртак пәйгамбәре булганга, «Тәрҗеман»ның 50 еллыгын бәйрәм итү, аны искә төшерү — бөтен төрк кабиләләренең уртак бурычы. Олуг төрк милләтенең бер өлеше әле үз эшенә үзе хуҗа булганга, бу бурычны да ул үтәр дип ышанабыз. Тик Тукайның 20 еллыгын кем искә төшерәчәк?

Габдулла Тукай безнең Идел буе төрк-татары шагыйре булганга, ул безнең халкыбызның моңын җырлаучы, безнең дәрдебезне күпләүче булганга, аны искә алу да тугрыдан-тугры безнең өстебезгә йөкләнә.

Ләкин безнең илебез, безнең йортыбыз хәзерге көндә безнең «үзлегебезне» бетерергә бил баглап керешкән кызыл урыслар кулында булганга, андагы халкыбызның бу кадерле шагыйрьне олугларга имкян табачагы бик шөбһәле. Тукай татар халкы өчен аның кайгы-хәсрәтен әйтеп бирә торган бер халык шагыйре булса да, совет карашыннан ул — мулла баласы, милләтче, динче; коммунизм карашыннан ул — урыслаштыру тәрбиясенә киртә салып торучы бер контрреволюционерчы; илебезне-йортыбызны урыс мөһаҗире (күчеп килүчеләре) берлә тутырырга теләүче кызыл Мәскәү карашыннан ул — шовинист милләтче; бөтен большевик сәясәте карашыннан ул — үзенең халкы кебек, үз илендә бөтен нәрсәдән мәхрүм «хокуксыз-лишинәтс».

Моннан ике ел элек кайбер татар большевиклары Тукайның 20 еллыгына әзерләнү өчен бер програм ясаган булсалар да, бүген ул програмны ясаучыларның да бик күбесе, милләтчелектә гаепләнеп, Соловкига (Соловки — төньяктагы атаклы сөргенлек җире исеме) җибәрелеп бетерелгәнгә, илебездә Тукай хөрмәтенә бернәрсә ясалуын көтүе бик читен. Шул көннең якынлашуына карамастан, большевик татар матбугатында бу турыда һич бу нәрсә язылмавы да бу фикердән ваз кичкәнлекне күрсәтә.

Кызыл урыс золымы астында яшәгән халкыбыз үзенең кадерле шагыйрен шул тарихи көндә рәсмән хәтерли алмаса да, халкыбызның дөньяның иркенлегендә яшәгән өлеше өчен бу тарихи көнне искә төше-

рергә һичбер маниғъ юк. Һәрбер төрле юлда шул көнне хәтерләргә, шул көнгә карап эшләнәчәк милли эшкә киң бер мәйдан бар. Шуны эшләү! Һәм ничек эшләү? генә кала.

Илебездән читтә яшәгән илдәшләребез, мәгаттәассеф, бик таркаулыкта яшиләр, алар бер-берсендән әллә ничәшәр мең чакрымлык җир-су берлә аерылган кебек, алар мәгънән дә төрле-төрле чит мәдәниятләрнең тәэсирендә калалар. Бу таркау бер милләтнең балаларын берләштерә торган мәдәни мәркәзебез юк. Мондый уртак булган милли йөкне күтәрә торган мәдәни бер оешмабыз да юк. Шуңа күрә бу эш тә аерым-аерым гөруһларның тәшәббесләренә кала. Безнең мөһаҗирләребезнең гыйльми яктан көчле җире Төркия булганга, безнең андагы илдәшләребезнең мондый мәдәни эшләребездә юлбашчылык итүләре кирәк иде. Ләкин, мәгаттәассеф, анда да мондый бер хәзерлек күренми. Кала Ерак Шәрык берлә Аурупадагы мөһаҗирләребез.

Ерак Шәрыктән Хөсәен Габдүш әфәнде, Тукайның 20 еллыгын хәтерләтеп, Харбинда бер рисалә бастырып таратты һәм бу мәсьәләгә дикъкатьне җәлеп итәргә тырышты. Хөсәен әфәнде үз тарафыннан билгеле бер програм тәклиф итмичә, фикер эшләтер өчен юллар гына күрсәтә. Ул: «Аерым мәҗмугалар бастырып булмыймы? Тукайның аерым әсәрләрен кечкенә рисаләләр төсендә итеп бастыруны аерым мәхәллә һәм оешмалар үз өсләренә ала алмыйлармы?» — дип сөальләр бирә һәм шуның җавабын көтә. Аурупадагы мөһаҗирләрнең оешкан өлеше сәяси көрәш алып барырга мәҗбүр булганга, аның да үз өстенә йөкләнгән вазифасы бик җиткән; аның да матди-мәгънәви көче чикле булганга, бу уртак эшне аңа гына йөкләргә һәм аннан гына көтәргә ярамый.

Безнеңчә, бу һичбер сәяси булмаган эш өстендә безнең бөтен мәдәни көчләребез берләшергә һәм, кайда гына булсалар да, бергәләшеп шул уртак бурычны үтәргә тиеш. Инде бу искә алуның програмына килгәндә, хәзерге көндә Тукайның аерым әсәрләрен бастырып булса да, аның «Мәҗмугаи асаре»н бастырырга безнең мөһаҗәрәттә матди көч юк дигән фикердәбез. Аның кайбер әсәрләрен аерым-аерым бастыру һәм Тукайга багышлап бер китап, бер мәкалә җыентыгы чыгару эше кала. Тукайдан соң үткән ел безнең тарихыбызда бик мөһим урынны тотканга, бу дәвердә Тукайның ролен һәм халыкның аңа карашын күрсәтә торган мәкаләләр җыентыгын туплар өчен безнең гыйлем, әдәбият әһленең кыйммәтле язулары кирәк булган кебек, аның басылуы һәм таралуы өчен дә һиммәтле милләттәшләребезнең матди ярдәмнәре кирәк. Бу эштә юлбашчылык итәр өчен, безнеңчә, урта бер җирдә бер вакытлы һәйәт вөҗүдкә китерү лязим. Менә шул һәйәт мәгълүм бер мөддәттә алынган мәгълүматларга карап, күрсәтелгән матди ярдәмнәрне үлчәп, үзенең ни төстә хәрәкәт итәчәген кисәттерә алачак һәм матбугат аркылы бу турыда милләттәшләребезне таныштырып тора алачак.

Вакытның бик кыска икәнлеген игътибарга алып, Тукай хатирәсенә хөрмәт иткән бөтен әһле каләм һәм әдәбтән бу эшкә катышачакларын тиздән белдереп, мәкаләләрен җибәрүләре һәм һиммәт ияләренең дә үзләренең ярдәмнәрен тиздән күндерүләре матлуб.

Төрле җирләргә таркалган милләттәшләребез мәҗмугабыз аркылы һәйәткә мөрәҗәгатьләрдә булсалар, шулай ук һәйәттә үзенең эше турында илдәшләребезгә мәгълүмат биреп торырга теләсә, аларга мәҗмугабызның битләре һәрвакыт ачык.

**Шакир Йосыф**

## ИСКӘ АЛГАНДА

*Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә*

*Тирән, әллә нинди зарлы бер моң. Милли татар моңы күп тарихларны агызган Идел агымына кушылып ага. Урал тау итәкләренә тарала.*

*Ишетте, хәйран булып тыңлап торды бу моңны бөек Кушлавыч ятиме.*

*Тыңлап торды-торды да, үзенең сынык, ятим күңелендә шул моңны яндырып, безнең өч йөз ел буена ничек изелүебезне әйтеп бирде.*

*Зур-кечкенәләребез, яшь-картларыбызның барысы да аңлардай садә, ләкин искиткеч оста бер телдә аңлатып бирде. Халкыбызның җыры, мәкаль һәм табышмаклары кебек бер ишетү берлә хәтердән чыкмый торган сүзләр-шигырьләр белән телебезнең матурлыгын һәм байлыгын күрсәтте.*

*Тукай шигырьләрендә беренче кат туган телебезнең матур музыкасы яңгырады, шунлыктан йорттан йортка, кулдан-кулга күчеп йөргән авыл малае кечкенә бер Апуш булып кына калмады — татар халкының онытылмас шагыйре Габдулла Мөхәммәтгариф углы «зуп-зур Тукай» булды.*

*Хөсәен Габдүш*

*«Татар шагыйре».*
*Харбин, 1932*

Шагыйрь — халык баласы. Ул күңеленең бөтен тамырлары берлә халыкның тормышына бәйләнгән. Халык шатлыгы — шагыйрь шатлыгы. Халык кайгысы — шагыйрь кайгысы. Бу сүз башкаларга караганда да тирәнрәк мәгънә берлә безнең шагыйребез Тукай турында әйтелә ала. Чөнки ул тарихының соңгы елларында ятим калган милләтенең ятимлектә үскән баласы.

Тукай язмышы — халык язмышы. Аның күңелендә ут яна иде. Халык күңелендә дә шул ук ут гөрли иде. Ул татар халкының үз тарихында үстереп дөнья мәдәниятенә бирә килгән төрек милләтенең бер баласы иде.

Без узган көннәребезнең караңгы булганын беләбез. Без бу көнге тормышыбызның да ачы булганын яшермибез. Шуңа күрә дә без киләчәгебезне — халкыбызның язмышын — якты һәм ямьле итеп күрергә телибез. Шуның өчен без халкыбызның үзлеген саклый торган һәм бөтен авырлыкларга каршы нык итеп тота торган бөтен юлларны һәм бөтен терәкләрне эзлибез.

Бу юлның иң кирәклесе — халкыбызның күңеле. Бу терәкнең иң ныгы — халкыбызның теләге. Тукай — безнең халкыбызның һәм шуның берлә бергә бөтен төрек милләтенең күңелен һәм теләген ачкан һәм шуны ачарга тырышкан өчен — безнең җырчыбыз.

Халык язмышы — Тукай язмышы.

Көннәрнең суыклыгы, төннәрнең караңгылыгы шагыйрьгә аның тормыш эзен яктыртырлык, аның учагын җылытырлык бер очкын бирә алмады. Ул, яшьлекне татырга да өлгермәстән, үлем тырнагына эләкте. Ашкынган йөрәкнең көчсез канаты сынды. Тик бу сынуда күңелләр берлә бергә безнең дә, иленең дә гөнаһы юк түгел иде. Аның йөрәген кем җылытты? Аның күңелен кем җуатты? Шагыйрь үлде. Үпкәне кимергән үлем корты аның тормышка бәйләнгән соңгы тамырын өзде.

Тик моның берлә генә безнең шагыйребез каршында булган бурычыбыз беттеме? Бетмәде.

Бу бурыч бетмәде. Бу бурыч артты. Ул, бер кешегә, бер шагыйрьгә, бер Тукайга булган бурычтан чыгып, халыкка, милләткә һәм кешелек дөньясына булган бурычка әйләнде. Ул Тукай исеме берлә халык өчен булган бурычка әверелде.

Тукайны кимергән үлем корты бүген халыкны кимерә.

...Илебез соңгы елларда бик күп төрле күренешләр кичерде. Ил йөз елларча көткән теләгенең барлыкка чыга башлавын күрергә өлгермәде, язмыш аны тагын борынгы тартыш сафына чакырды. Алсу кызыллыктан яңа бер таңның яктылыгын көткән ил икенче бер янгын алдында калды. Аның бик зур авырлыклар берлә генә саклап килә алган бөтен барлыгы да бу янгында янды, көл булды.

Халык язмышы — шагыйрь язмышы.

Халык берлә бергә шагыйрьнең теләге дә, аның эше дә, аның көче дә бергә янды. Шул янгынны ерактан карап торучы, илдәге моң-зарны читтән ишетеп торучы халык уллары — алар нишләделәр? Алар нишләргә телиләр?

Бер халыкның барлыгы һәм шул барлыкның киләчәге өчен кирәк булган билгеле төп нигезләр бар. Шул нигезләр булмыйча торып, бер халык яши алмый. Шул нигезе булмаган йә шул нигезне югалткан халыклар бетәргә — югалырга мәҗбүрләр. Бөтен нигезләрнең барысы да халык күңел тормышының үз булып калуы, куркынычын-кайгысын үзенчә сөйләве һәм үзенчә көйләве. Бер халык тиңсез тартыш эчендә ярлылана ала. Ул үзенең бөтен матди барлыгын югалта ала — болар бары да вакытлы нәрсәләр. Ә халыкның күңеле, халыкның күңел көрәше — бу меңнәрчә еллардан бирле җыелып килгән. Аның ярату көчен ясаучы нәрсә — ул халыкның язмышы. Ул — халыкның үзе.

Бу күренеш бер безнең өчен генә түгел, бүген бөтен төрек милләте үзенең барлыгының, киләчәгенең нигезен бер калыпка суга. Аның бу көнге эше төрек милләтенең киләчәк төсен һәм аның ярату көченең киләчәктәге чиген билгеләячәк. Милләтнең бу көнге тартышы аның мәдәнияте һәм мәдәниятенең чикләре өчен бара.

Милләтне — илне саклау юлында бирелгән корбаннар, милләтнең сәяси истикъляле өчен бирелгән корбаннар алар бары да бер нәрсәнең — милли мәдәниятнең саклануы һәм шул мәдәниятнең үсүенә каршы куелган киртәләрне җимерер өчен бирелгән корбаннар.

Бу төп нигезне саклау һәм шуны ныгыту юлында эшләнгән эшнең зурысы-кечкенәсе юк. Ул бер үк төстә зур, ул бер үк изгелекнең юлына бирелгән ярдәм.

Бу тарихи көннәрдә, халкыбыз кичергән авыр һәм караңгы төннәрдә халыкның, илнең төп нигезен саклау өчен безгә тагын Тукай ярдәмгә килә. Шул нигезне кору юлында үсеп җиткәнче егылган, чәчәк ат-

канчы шиңгән шагыйрь, үзенең көчле тойгысы берлә җир астыннан калкып чыгып, безгә тагын ярдәмгә килә.

Ул, үзенең рухы берлә безнең баш өстебездән очып, безне уйларга, сөйләргә һәм сөйләгәнне эшләргә чакыра!

Үлеп, егерме ел кара салкын туфрак астында ятса да, ул, үзенең янган-көйгән куанычы-кайгысы берлә тагын безгә килеп, «татар халкы ниләр сизгәнен» өзелеп-өзелеп әйтеп бирә. Ул үлгәч тә безне шул турыда уйларга һәм шул уйны үзебез өчен кирәкле һәм файдалы юлда барлыкка чыгарырга чакыра.

Ул, безнең бөтенебезгә карап, өстебездә торган шул изге эшне, шул мөкатдәс бурычны үтәүдә дә барыбызның да бер үк аң берлә эшкә башлавыбызны көтә.

Ул безнең бөтен әрвахларыбыз өчен, халкыбызның сансыз корбаннары өчен үзенең туктаусыз аккан күз яше белән безнең әле торган, яшәгән, сулыш алган илдәшләренең-милләттәшләренең тойгыда, сүздә, эштә берләшүләрен көтә.

**Гали Биктимер**

## ЭЗЛӘНГӘНДӘ

Шагыйрьнең тормышы авыр иде. Ул аны бөтен ачылыгы берлә үзе дә язып калдырды. Аның шигырьләре дә авыр моңга төрелгәннәр.

Шагыйрьнең ярату көче турында да әле тәнкыйть коесы капланган юк. Берәү аны, Шәрык тәэсирендә, диде, берәү аны, Гарәп тәэсирендә, диде, берәүләр аның җитди шигырьләрен күтәрделәр. Икенчеләр аның һөҗүле шигырьләренә күбрәк әһәмият бирергә тиешлек турында яздылар. Өченчеләр аның балаларга карата язган шигырьләрен беренче урынга куйдылар. Берәүләр өчен ул үзенең ярату көчен халык әдәбияты коесыннан алган оригиналь шагыйрь иде. Икенчеләр өчен ул тәрҗемәче һәм тәкълидче иде.

Иде!.. Иде!..

Боларның барысы өчен дә аның шигырьләрендә һәм тормышында җитәрлек шаһит бар иде...

Бу турыда язучылар аның шигырьләренең тышкы күренешен генә күз алдында тотып фикер йөрттеләр. Алар шул шигырьләрне язарга мәҗбүр иткән шагыйрьнең эчке күңел тормышын карый алмадылар. Шуңа күрә бу эчке күңел тормышын дулкынландырган төп сәбәпләр дә капланып калды. Бу уңай берлә халыкның алдына ачылып салынырга тиешле бик күп ачы хакыйкатьләр дә ябылган көе калды.

Тукай ник «болай» иде? Тукай ник «тегеләй» иде?

Моның җавабы: Тукай үзе «болай» йә «тегеләй» түгел иде. Тукайның күңелен дулкынландырган татарның тормыш шартлары йә «болай» йә «тегеләй» иде. Тукайдагы күренеш, аның шигырендәге төрлелек әнә шул тормышның күренеше һәм шул тормыш шартларының төрлелеге иде. Шагыйрь күңеле шул күренешләргә көзге иде.

* * *

Тукайны корбан иткән еллар безнең тормышыбыз өчен «өметлерәк» еллар иде. Без артка түгел, алга таба бара идек. Истәлек бәйрәмнәрен иткән көннәребезнең башлангычы ул елларда иде. Шуңа күрә без тормышының ул көнге күренешен тәнкыйть күзе берлә карарга теләмәгән идек...

Чыннан да, Тукай еллары безнең өчен йөз елларча эзләгән һәм киләчәге өчен бер нык юл сызмаган халык өчен нормаль тормыш идеме?

Чынлап та ул көннәр бер «күңел»гә ут-ялкын бирерлек, бирә алырлык көннәр идеме? Ул елларда бер генә юл да, бер генә өслүб тә, бер генә төр дә тибрәнә алырлык идеме?

Әлбәттә, ул көннәр дә бу көнгесе шикелле үк авыр иде, бу көнгесе шикелле үк караңгы иде. Ул көннәр дә әле безнең тарихыбыздагы шанлы көннәребезне җанландырырлык түгел иде.

Тукайны бер кеше итеп аңлар өчен, аның күңел тормышына кереп, аның тойгысы берлә яшәр өчен безнең ул көннәргә чаклы уздырган якын тарихыбызны бөтен авырлыгы, бөтен ачылыгы берлә күз алдыбызга китерергә тиешбез.

Бу тарихта бер уй иясе өчен өмет бирерлек бер күренеш бар идеме?

Бер Тукайда гына түгел, аның алдыннан торган «дөньядан бизүчеләр»не дә карагыз, бернichә буынның үткән тормышы берлә ничә буынның киләчәген уйлый алган һәм үзенең хәрәкәтен шул ике күренешнең мәсьүлиятенә нигезләнгән кеше өчен ул көнге тормышта чиксез өмет табу бик җиңел булмас.

* * *

Шагыйрь күңелендәге сүнмәс очкын — аның идеалы. Шагыйрь идеалы — халык идеалы. Бу идеал шагыйрьгә генә түгел, бөтен халыкка тормыш азыгы бирә. Ул аңа авыр көннәрне өметсезләнмичә уздырырга ярдәм итә. Ул аңа елларның җиленә-суыгына каршы торырга көч бирә. Ул көннән-көн шул идеалга якынлаша, якынлашкан саен, аның көче арта бара.

Тукай көннәрендә безнең халкыбыз өчен, шулай ук халыкның мәгънәви азыгын әзерләгән әдәбиятыбыз өчен бу идеал юк иде. Тик шуның юклыгын күргән һәм шуның кирәклеген белгән бер даһи аны әзерләргә тиеш иде.

Тукай шуны эзләүче иде. Аның шигырьләрендәге тыштан караганда бер-берсенә каршы күк күренгән моң бер үк күңелнең туктаусыз тормышы иде. Шуңа күрә ул төрле иде. Шуңа күрә ул ачы иде.

1905 елны күргән шагыйрь күңел ачарга өлгермәде. 1917 елны күргән булса иде, без бу күңелнең балаларча куануына шаһит булыр идек. Тик бу шатлык та кыска гомерле булыр иде. Тукай да шәйхулла юлыннан китүне артык күрер иде.

* * *

Бер шигырьдә бөтен нәрсә дә шагыйрьнең үз малы гына түгел, шагыйрьнең андагы хакы — аның бер фикерне халык күңеленә, тойгысына яраклы итеп, һәрьяктан үз итеп калыпка салуы. Мондагы осталыгы шагыйрьнең иҗат көчен үлчәргә җитә. Халык биргән материалдан ямьлелек, ярату һәм шул материалдан яңадан-яңа формалар кою бу шагыйрьнең иҗат көченең тирәнлегенә, чынлыгына бәйләнгән.

Менә монда Тукай бер оста иде, һәм башкаларга үрнәк булырлык бер оста иде.

Тукайның иҗадиятен аның шигырьләре аркылы тикшерү безнең бүгенге теләгебезнең максаты түгел. Бу юлдагы тәҗрибәне икенче урында бирергә мөмкин булыр. Без монда бу көн уңае берлә Тукайдагы төрлелекнең төп сәбәбен генә күрсәтергә теләдек.

* * *

Тукай көннәрендә үзенең якынлыгы берлә ачылык тудырган бу идеал нәрсә соң?

Без үз илебездә яшибез, тик дошман кулында яшибез. Дошман безнең тормышыбызның төп нигезләрен җимерә. Ул безне изә, җиребезне кыса, халкыбызны матди һәм мәгънәви ярлыландыра. Дәһшәтле ачлык еллары тарихыбызның безнең өстебезгә ташлаган югалу куркынычының бер кечкенә шәүләсе генә. Бу куркыныч бүген дә дәвам итә. Ирек ул һичбер вакыт мәгънәви генә була алмый. Ирекнең нигезендә матди ирек салынган булырга тиеш. Матди ирек халыкның язмышы үз кулына кучкән чакта гына тормышка аша ала.

Коллыкта торган һәм коллыкта яшәргә күнгән халык тулы мәгънәсендә бер мәдәният тудыра алмый. Чөнки мәдәният ул нәрсә икәнлеге билгеле булмыйча һавада очкан бер төтен генә түгел, ул көндәлек тормышның куанычыннан һәм кайгысыннан туган һәм шул куаныч һәм кайгы өчен халыкның үзе корган оешмаларының эшендә генә туа ала.

Бу халыктан бер дәүләт һәм бер үз булган идарә сорый. Бу сорауга җавап бирү халыкның идеалы булырга тиеш. Без, халыкның иҗат көченә бер бәһа куйганда һәм аның даһиларына күңел куюларын актарганда, әнә шул идеалга хезмәт итүнең дәрәҗәсен үлчәү итәбез.

* * *

Тукай безнең шул идеалыбызны эзләүдә бөек шагыйребез иде. Ул шул туктаусыз һәм тиңсез тартышта безнең арабыздан китте. Тик аның юлы калды: аның ачы булса да ямьле, ямьле булса да ачы моңы безгә юаныч һәм куаныч булып калды.

Аны искә алу көне безне тагын да аның язмышына һәм шуның берлә безгә халык язмышына тирәнрәк карарга һәм ул язмыштагы сорауларга тагын да ачыграк җаваплар эзләргә өнди.

## ТУКАЙНЫ АҢЛАР ӨЧЕН

Бүгенгә чаклы Тукайның тормышы һәм аның әдәби иҗаты турында язылган тикшеренүләрнең иң мөһиме, шөбһәсез, Җамал Вәлиди каләме берлә язылып, Габдулла Тукаевның «Мәҗмугаи асаре»нең беренче басмасына кергән мәкалә иде.* Үзенең киң һәм тирән карашы берлә Тукайның шигырьләрен аңларга бик күп юллар ачкан җитди тәнкыйтьченең бу беренче басмадагы фикерләрен без бүген бөтенесе берлә кабул итә алмыйбыз. Кирәк Тукайның үсүенә караштa булсын, кирәк аның шигырьләренең эчке төзелешен аңлауда булсын, без бүген башка юл берлә барырга тиешбез.* * Без шагыйрьләрдә, бигрәк тә Тукай-

да, үзебез күрергә теләгән йә үзебез аңлаган якларны гына эзләп, үзебез күрмәгән йә күрергә теләмәгән якларны читкә ташламыйча, шагыйрьнең шигырен генә алып, аның шигырен генә аңларга тырышырга тиешбез. Бер шигырьне аңлар өчен, аны тәнкыйть күзлегеннән уздырыр өчен, без шул шигырьне язучының күңеленә һәм аның күңелен дулкынлаткан мохиткә керергә тиешбез. Без, үзебезне шагыйрь урынына куеп, аның рухы һәм күзе берлә карый алганда гына аның әдәбияттагы урыны турында тулы бер фикергә килә алачакбыз.

Тукайның иҗатын аңлар өчен дә без иң элек бөтен ваклыклары берлә аның тормышын, шулай ук ул яшәгән мохитнең тормышын, аның берлә алып барган гаясын һәм уен белергә тиешбез. Тукай тормышы үзенең башыннан алып ахырына чаклы бик сирәк була торган бер тормыш тезмәсе булганга күрә, бу тормышны ачык иттереп күз алдына китерү бик күп авырлыклар берлә бәйләнгән. «Исемдә калганнар»дан соң Тукайның тормыш юлына яңа яктылык төшерә торган икенче бер тикшеренү әлегә чаклы мәйданга чыкканы юк. Шуңа күрә ул планның икенче өлешен язмавына ничаклы үкенсәк тә аз булачак. Шул ук сүзне Тукай дәвере турында да әйтергә мөмкин. Тукай яшәгән көннәр безнең халкыбызның тормышында язгы ташу көннәре иде. Узган көннәргә бер чик сызылган, яңасына меңнәрчә ашкынуның очкыннарыннан нурлар түшәлгән иде. Боларның төп гаялары һәм өметле учаклары ничаклы бер булмасын, аларның тормышка тәэсире, аларның тышкы йогынтылары бик төрле иде. Без моның Тукай берлә багланышы булган өлешен дә бик ачык күрерлек бер хәлдә булырга тиешбез.

Тукай сахраи кәбирдә яшәмәде. Ул ничаклы кешеләрдән качмасын, аның дуслары, танышлары һәм бергә эшләгән кешеләре бар иде. Казан безнең мәдәни мәркәзебез иде. Моның өчен меңнәрчә кешеләр Тукайны күрделәр, белделәр. Без менә боларның да истәлекләрен күрергә теләр идек. Алар ничаклы әһәмиятсез күренмәсеннәр, алар Тукай һәм аның көннәрен аңлар өчен бик файдалы булачаклар.

Шул ук сүзне Тукайның әсәрләре турында да әйтергә мөмкин. Тукай язган шигырьләр, шөбһәсез, аның үз кулы берлә җыелган мәҗмугага кергән шигырьләр берлә генә чикләнми. Тукайның шигырьләр җыентыгын без тагын да калынрак итеп күрәбез. Шагыйрь, бигрәк тә Тукай, үзенең кайбер әсәрләренә әһәмият бирми китә ала. Шагыйрьнең шул ук вакытта тәнкыйтьче дә булуын сорау авыр. Безнең өчен менә бу шигырьләрнең дә әһәмияте зур булачак.

Тукайны искә алу көннәрендә аңар туктаусыз мактау сүзләрен яудыру безнең якын тарихыбызның турыдан-туры материалы булачак. Менә бу якларга да тиешле игътибарны бирүне онытмау кирәк иде.

Бу шагыйрьне тикшерү бер кешене тикшерү түгел, ул — халыкның күңел тормышын тикшерү.

**Солтан (Әхмәт Виргаз)**

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ҮЛҮЕНӘ 22 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕ БЕРЛӘ*

Һәр милләтнең, һәр халыкның, тарихи язмышына карап, үзенең моңы, җыры, көе, зары була. Һәрбер милләт кайгыра, шатлана, моңлана, зарлана... Һәрбер милләтнең моңын, шатлыгын, кайгысын әйтеп бирә торган үзенең шагыйре — халык шагыйре була.

Без — Идел-Урал төрк-татарларының да үзебезнең кайгыбызны, шатлыгыбызны, барлыгыбызны — халкыбызның еллар буенча күңелендә янган тойгысын әйтеп биргән шагыйребез булса, ул да мәрхүм Габдулла Тукай иде. Тукай халык иде. Тукай теле халык теле иде... Тукай үзенең иҗаты, шигыре берлә халкыбызның әйтергә теләгән тойгыларын җиңел, шома, искиткеч матур бер телдә әйтеп бирде. Менә шуңа күрә Тукай, татар әдәбияты тарихында зур урын алып, «халык шагыйре» дигән исемне алды. Тукай үзенең аз гына гомерендә шундый әдәби җәүһәрләр чәчрәтте, ул җәүһәрләрне җыярга, Тукайны өйрәнергә Казанда һәм башка җирләрдә аерым Тукай түгәрәкләре дөньяга килде. Кыскасы, Тукай үзенә бер мәктәп тудырды. Тукай төрк-татарның классик бер шагыйре булды. Тукай шигырьләрендә халкыбызның тибеп торган күңел чишмәсе, шуңа күрә аның шигырьләре җанлылар... Тукай шигырьләрен укыган саен, мәгънәсе арта бара, мәгънәсе арткан саен, Тукай югары күтәрелә. Тукай теленең иң төп хосусияте җиңел, шомалыгында булса, шигырьләрен укыган саен, мәгънә һәм фәлсәфәнең арта баруы да җанга азык булып, күңелгә утырып калуындадыр. Бу шагыйрь чын мәгънәсе берлә каләмен күз яшенә манып язды:

Күпме михнәт күргән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр берлә ялкынланып,
Сызылып-сызылып чыга күңелдән.

Идел-Урал төрк-татарларының кайгысын, шатлыгын җырлаган шагыйрьне искә алганда һәм тарихыбызның караңгы битләренә барып төртелгәндә, шагыйрь әйтмешли: «Аһ, дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе!..»

Бөтен мәдәният дөньясы инглизнең Байронын, алманнарның Гётесын һәм башка әҗнәби милләтләр үзләренең милли шагыйрьләрен дөнья күләмендә таныткanda, ни өчен соң без — төркләр — үзебезнең әдипләребез, шагыйрьләребез, гомумән алганда, әдәбиятыбыз берлә дә таныштыра алмыйбыз?! Бу, әлбәттә, бездә начар әдипләр, шагыйрьләр булудан түгел, моның төп сәбәбе менә нәрсәдә: әгәр Тукай русның залим, канлы кулы астында изелгән мәхкүм милләтнең шагыйре булмыйча, үзенең хөр илендә иркен яшәп, истикъялен алган бер милләт шагыйре булса иде, ул башка милләтләргә дә күптән танылган булыр иде. Тукай хакында да чит матбугатта мәкаләләр язарлар иде. Чөнки Тукай зур шагыйрьләр берлә тиңләшерлек бер шагыйрь. Ләкин гасырлар буенча изелгән, русның жандарма көче һәм безнең бөтен милли хәрәкәтебезгә русның балта чабып килүе аркасында, без — Идел-Урал төркләре — күңелебездә янган ялкынлы теләкләребезне яза алмый килдек...

«Милләтләр зинданы» ватылып, Русиядә инкыйлаб дулкыннары купкач та, Русия кул астындагы һәрбер милләт, үзенең милли фикерен бәйнәлмиләл сәясәт мәйданына ташлап, үзләренең истикъялен даулый башладылар. Һәм кайберләре үзләренә үзләре хуҗа да булдылар. Болар шуның нәтиҗәсендә хәзер үзләренең фикерләрен, шагыйрьләрен, әдәбиятларын чит милләтләргә яхшы танытып киләләр.

Тукайның үлүенә 20 ел тулганда гына безнең шагыйрь дә чит милләтләргә киңрәк күләмдә мәгълүм була башлады. Бигрәк тә безнең кеби рус кул астында изелгән милләтләр, безнең тарихыбыз, әдәбиятыбыз аркылы, безнең берлә аңлашмакчы, берләшмәкче булалар. Тукайның үлүенә 20 ел тулганда, поляк телендә чыга торган «Daleki wschod» журналы, Тукайның рәсемнәрен төшереп, мәкаләләр багышлап, берничә шигырен тәрҗемә дә иткән иде. Шул вакыт башка чит матбугатта да язылып үтелде. Болар әле беренче карлыгачлар гына.

Тукай әле үзебез өчен дә өйрәнеп бетмәгән бер шагыйрь... Ул елдан-ел өйрәнелә, Тукай шигырьләре татар ләһҗәсендә булганга күрә, алар халкыбыз тарафыннан сөйләп укыла. Тукай шигырьләре халык әдәбиятыбыз кеби җиңел һәм тиз ятлана... Без әдәбият тарихыбызны карасак, Тукайдан алдарак килгән шагыйрьләр бар. Бигрәк тә «уяну дәвере»ндә бездә Тукай берлә бергә килгән күп кенә шагыйрьләребез бар. Һичшиксез, бу шагыйрьләребез арасында үзенең шигърияте берлә халыкның күңеленә иң якын торучы ул — Тукай. Безнең Идел-Уралда Тукайны белмәгән бер караңгы почмак бармы? Тукай каләме астында Идел-Урал әдәбияты чәчәк атты. Тукай татар ләһҗәсенең матурлыгын, рухын аңлатты. Ул халкыбызның сөйгән җырчысы — халык шагыйре булды...

Тукайның күп шигырьләрендә көлке-һөҗү кыйсемендә, «Шүрәле» кеби әсәрләрендә мәүзугъ итеп халык хикәяләре, әкиятләре алынган, менә шуның өчен дә аның шигырьләрендә халкыбызның язмышын, шатлыгын, кайгысын бигрәк тә ачык күрәбез. Тукай шуларның барысын да татар ләһҗәсендә бик оста, матур, шома җырлап бирде:

Шадыман ул мәркадең дә,
Без онытмыйбыз сине;
Белмәсәк вактында кадерең,
Инде котлыйбыз сине.

**Рокыя Мөхәммәдиш**

## ТУКАЙ КӨНЕ

Милли барлыгын сөйгән, милли үзлегенең кадерен белгән Идел-Урал төрк-татары өчен 15 апрель көне милли хәзинәсенең байлыкларын барлау, тикшерү көнедер. Бүген халкыбыз үзенең бөек шагыйре Габдулла Тукайны искә ала, аның милләтенә калдырган кыйммәтле бүләкләрен күз алдыннан кичерә. Мәрхүм шагыйребез Габдулла Тукайның кыска гына тормышында аерылу көне — 15 апрель — безнең халыкның күңелендә бер яктан матәм көне булса, икенче яктан үзенең үсешенең уңышларын барлау көнедер. Тукай төрк-татар мәдәнияте тарихының асыл ташларын арттыручы, төрк-татар теленең матурлыгын мәйданга китерүче вә милләтнең милли хисен уйнатучы халык шагыйре булганга, мәңгелеккә китүенә инде егерме өч ел тулса да, халкының күңелендә аның хатирәсе үзенең көчен югалтмыйдыр. Тукай шигырьләрендәге милли барлык рухы халык күңелендә әле дә яши, милләт хисе күтәрелгән саен, аның шигырьләренең кыйммәте арта бара. Шунлыктан халык, Тукай кичәләре, Тукай истәлекләре ясап, Тукай иҗаты аркылы үзенең милли үзлегенең күргәзмәсен күз алдыннан үткәрә. Шулар аркылы үзенең милли хиссиятен күтәрә вә шундый бөек шагыйрь булган бер милләтнең тулы хокуклы булып яшәргә хакы барлыгын аңлый. Шуның өчен безнең милләтебез вә динебезнең тамырына балта чабарга тырышучы руслар әүвәл жандарма төсендә, хәзер ГПУ төсендә халкыбызга мондый тупланышларны ясарга мөмкин булган кадәр

мәңгы итәргә тырышалар, тырышып килделәр. Дошманнарыбызның милли үзлегебезне (бетерү) ноктаи назарыннан караганда, бу бик тугры. Чөнки халыкның шагыйренә багышланган тупланышлары, аның иҗаты белән танышу вә шуның аркасында милли хиснең көчләнүе белән баглы. Бигрәк тә Тукай кебек шагыйрьнең һәркем аңларлык садә сүзләре белән «Күпме михнәт күргән безнең халык өч йөз елда»ны хәтерләтү безнең үзәгебезгә ачу салырга тырышучылар өчен бу бик табигый. Ләкин халкыбызның теләгенә бераз гына ирек бирелгәндә, ул үзенең мактанырлык милли байлыгы — Тукайны искә алып китүдән, аның белән һаваланудан вә шуның белән бергә үзенең дә Тукай кебек мәзлум төрк-татар милләтенең әүвәлге баласы икәнен дә хәтерләп узудан тыела алмый. Шуңа күрә төрле мәнгы итүләр эчендә Тукайның вафатыннан соң илебездә 15 апрель «Тукай көне» исемендә мәктәп балалары күләмендә генәме яки зуррак үлчәүдәме искә алынып килинде. Тукайны искә төшерү илебездән мөһаҗәрәткә чыккач та, чит халык арасындагы тормышның авырлыгы эчендә онытылып калмады. Тукай үлүгә 20 ел тулу көне бөтен мөһаҗәрәтебез тарафыннан аерым бер хис белән үтәлүе Тукайның халкыбыз күңелендә урыны никадәр зур булуының тагы бер күрсәтмәсе булды. Хәзерге вакытта халкыбызның сөекле шагыйренә багышлап ясалган бер кечкенә генә мәрасиме дә контрреволюцион дип каршыланганга, милли хисне җанландырырга теләүчеләрен төрмәләр, сөргеннәр көткәнгә, илебез үзенең кыйммәтле баласын, арага русның әллә нинди кирәкмәгән фәлсәфәләрен катнаштырмыйча, үзе теләгәнчә искә алып уза алмады. Ләкин мөһаҗәрәтебез исә, бер-берсеннән мең чакрымнар мосафә белән аерылган булса да, үзенең мәдәни барлыгының тарихи көнен билгеләп үтүдә берләште. Халык үзенең мәдәни үсешендә ни дәрәҗәдә югары торуын күрсәтә торган шагыйренә хөрмәтенең зурлыгын, сөюнең тирәнлеген аңлатыр өчен аңа бер һәйкәл торгыза алмаса да, бүгенге мөһаҗирлектә җитешә торган яшьлегенең күңеленә милли барлыкны сөю орлыгын чәчәргә тырышты. Тукай рухына багышланган кичәләрдә, Тукайның тәрҗемәи хәле вә иҗаты белән бергә, төрк-татар халкының күңел чишмәсе байлыкларын берәм-берәм күз алдыннан үткәрде. Бер җирдә берсе Тукай хакында сүз сөйләде, аңа багышлап бер генә көнлек булса да гәзит чыгарды, мәкалә язды, аның исеме белән атап китапханә, кыйраәтханә ачты, аның исемен онытмас өчен, аның «Мәҗмугаи асаре»н, боларга үзенең кирәгеннән узып булса да, авыр хезмәт белән тапкан тиеннәрен бирде. Болар барлыгы белән бергә алганда да, Тукайның безгә калдырган милли хәзинәсенең зурлыгына, байлыгына нисбәттән бик кечкенә, диңгезгә тамызган бер тамчы кебек кенә булса да, болар барысы да халкыбызның үзенең милли барлыгын сөйгәннән килеп чыкты, чын теләк, чын ихлас белән эшләнде. Шуның өчен боларның кыйммәте бер зур һәйкәл утыртудан да артыктыр, мәгънәлерәктер. Бу кечкенә генә тупланышлар, бу сүзләр, бу язулар халыкның үзен-үзе яшәтергә теләвеннән туды. Халыкның милли барлыкка омтылуыннан мәйданга килде. Быел да мөһаҗәрәтебезнең бөтен милләтче кыйсеме бу көнне искә алуда шулай ук берләшәчәктер. Быел да бөтен оешма вә җәмгыятьләребез, бөтен мәктәп вә яшьләр түгәрәкләребез Тукай вә аның иҗаты белән халкыбызның киң катлавын таныштырырга иҗтиһад итәчәкләр. Халкының бәхете өчен янган, халкының теленең матурлыгын үзенә илһам итеп алган кыйммәтле шагыйребезнең рухы бездән шуны көтәдер, шуңа чакырадыр. Ләкин мәрхүм шагыйребезне яд иткәндә коры мактау, матур сүзләр сөйләү белән генә калмыйча, илебездә еракта үсүче яшьләребезгә милли-тәрбия бирү ноктаи назарыннан карап, Тукай иҗатыннан халкыбызның күңел байлыгын, милли-мәдәни барлыгын чүпләргә тиешбез. Яшьлегебезне милли рухта тәрбияләр өчен кулыбызда материал булмаган заманда Тукай кебек халкыбызның күңел көзгесен күрсәтүче шагыйрьнең шигырьләре арасыннан милли барлыгыбызның кыйммәтле энҗеләрен эзләргә, аның шигырьләрен тәфсирләргә тиешбез. Тукай халкыбызның баласы, милләтебезнең мәдәнияте биргән кыйммәтле җимеше булганга, ул үзенең кыска, ятим тормышында кешеләрдән читкәрәк качарга тырышса да, һәр җирдә үз халкыбыз эчендә яшәде. Илебезнең мәркәзе Казанның мәдәни учагында кайнады. Бу көнне Тукайга багышланган кичәләрдә, Тукай шигырьләренең кыйммәтен аңлар өчен дә, шулар арасыннан яшьлегебездә милли рух урнаштырыр өчен дә, ул яшәгән дәверне, ул туган-үскән даирәне, аны татарның бөек шагыйре итеп җитештергән мохитне бөтен ваклыклары белән күз алдыннан кичерергә бурычлыбыз. Чөнки бер әдипнең яки бер шагыйрьнең истигъдады көчле булуы гына аны мәгълүм юлдан алып китми. Даирә, мохит аңа үзенең мөһерен басмыйча калмыйдыр. Тукай хакында бу 23 елда шактый күп нәрсә язылды, тикшерүләр ясалды. Ләкин әле моның белән генә Тукай вә аның иҗаты төбенә кадәр дәвам ителгән, тикшерелеп беткән бернәрсә түгел. Иң гади генә кешенең тормышында да мәгълүм булган көн Тукай тормышында мәгълүм түгел. Без бүгенгә кадәр шагыйребезнең кайсы айда, нинди көндә тууын да әйтә алмыйбыз. Ул үзе дә, «ятимлек тормышым кайчан башланса да башланган инде» дигән кебек, үзенең «Исемдә калганнар»ында бу хакта бернәрсә дә язмый. Тукайның бөтен тормышын вә аның иҗатын тулы көенчә күздән кичерүче Җамал Вәлиди дә бу хакта «1886 елда дөньяга килде» белән генә канәгатьләнә. Тукай хакындагы хатирәләр аның белән бер дәвердә үскән, бер мохиттә җитешкәннәрнең хәтерендә, шиксез, хәтердә саклана торгандыр, әллә кайдагы берәүнең искереп беткән бер көндәлегендә яки бер хатирә дәфтәрендә онытылып ятадыр. Тукайны яд итү кичәләребез дә өстән төшерелә торган коры

бер вазифа, мәгълүм сүзләрне сөйли торган бер тупланыш төсен алмасын дисәк, Тукай иҗаты хакындагы тикшерүләргә әһәмият бирергә вә милли матбугатыбызда Тукайның иҗаты хакында фикерләр йөртергә, аның әсәрләре арасыннан яшьлегебездән милли барлык байлыгын эзләттерергә тиешбез вә бу милли хәзинәбез аркылы яшьлегебезгә халкыбызның милли-мәдәни зурлыгын аңлатырга иҗтиһад итәргә бурычлыбыз. Чөнки бер милләт өчен бер галимне искә алу, бер язучысын, бер шагыйрен хәтерләүнең бөтен мәгънәсе дә үзенең мәдәни үсешенең зурлыгын, милли барлыгының көчен киләчәк буынга күрсәтүдәдер вә шуңа яшьлеген хәзерләүдәдер.

**Хөсәен Габдүш**

## БӨЕК КУШЛАВЫЧ ЯТИМЕ

*Шагыйрьгә 50 яшь тулу уңае берлә*

Язганың булса бәкалы , ул бәкага тарта ала,
Мин дә булдым һич тә онтылмас кеше шул аркада.

*Г.Тукай*

Аның исеменнән үк халкыбызның үзлегеннән аерып алынмас бер нота яңгырый: Тукай! Ата-анасы кушкан исеме — халкыбыз арасында иң күп таралган вә сөелеп әйтелә торган исем — Габдулла.

Тукай — бу Габдулланы башка бик күп Габдуллалардан аерып, аны «Кечкенә Апуш»лыгыннан чыгарып, «зуп-зур» төрк-татар шагыйре дәрәҗәсенә күтәргән исеме дә арабызда сирәк очрый торган саф үзебезчә, милли бер исем. Тукаев түгел! Бу исемнең күңелгә якынлыгы да аның шул «Тукай» дип әйтелүендә. «Тукаев» дидеңме, аның бөтен музыкасы югалып, аннан паспорт исе килә башлый.

Тукай — бу исем халкыбыз арасында, яшькә-картка карамыйча, иң күп таралган исем. Җамал Вәлиди әйтмешли, төрк-татар тарихында мәңге онытылмаслык бер исем.

Шагыйребезнең исеме халкыбыз арасында шул дәрәҗәдә киң таралган ки, кайбер вакыт әдәбияттан бөтенләй хәбәрсез, надан кешеләрнең авызыннан да аның берәр шигырен ишетергә туры килә. Тупасрак булса да, кечкенә генә бер мисал: берничә таныш, җыелып, әңгәмә корып утырабыз. Уен-көлке арасында бурыч түләмәү турында сүз чыкты да, арабызда, әле генә әйткәнчә, шигырь вә әдәбиятка бөтенләй чит булган бер абзый: «Түләмәсәң... түләмәсәң... бит Тукайныкы... ничек әле?..» — дип сүзгә катнашмакчы булды. Без ярдәмгә килдек:

Чыгып барганда, дөп-дөп типкәлиләр,
Яман сүзләр белән дә сипкәлиләр.

«Менә, менә үзе!» — дип куйды Тукайны сөюче. Әгәр дә ул Тукайны белмәсә, бу урында сүзгә «әдәбирәк» рәвештә катнашу өчен, берәр халык мәкале әйтеп җибәрер яисә Хуҗа Насретдин ләтыйфәләреннән берәрсен сөйләп куяр иде. Хуҗа Насретдин димәктән, сүз җае килгәндә әйтеп узыйк: халкыбызның бөтен катлаулары арасында исеме күп таралуда Тукайның бердәнбер көндәше Хуҗа Насретдин булса кирәк.

Җамал Вәлиди үзенең «Тукай шигырьләре хакында мөляхәзәләре»ндә яза: «Тукай мәгънәне, фикерне бик ачык әйтә. Ул сүз астына төрелми, сәнгать артына яшеренми, ачык вә тәкәллефсез сөйли. Аның сәнгать пәрдәсе шулкадәр юка вә шәффафтыр ки, аның аркылы **иң гади күзләр дә** (ассызык минеке. — *Х.Г.*) үтә». Шунлыктан Тукай — халыкныкы.

Габдулла бәк Батталның кыйммәтле әсәре «Казан төркләре»ндә Тукай хакында шул сүзләрне укыйбыз: «Безем илдәшемез Хәмид Зөбәер бәк бу шагыйрьгә мөнәсәбәтле француз телендә бер маҗар (венгр) мәҗмугасында яздыгы мәкаләдә шагыйрьнең авыр язмышын, аның фәлакәтен дә халыкның язмышына охшата»*.

Тукайның яратышы шулчаклы киң вә төргә бай ки, нинди генә милли мәүзугъта берәр мәкалә яисә әсәр язма, шуның башына Тукай «Мәҗмугаи асаре»ннән һәрвакыт үзеңнең төп фикереңне җыйнап тора торган берәр шигырен язып куярга мөмкин.

Югарыда китергән кечкенә генә мисалыбыз Тукайның көнлек тормышыбызның иң гади (прозаик. — *Х.Г.*) хадисәләрендә «тел очында гына» торган нәрсәңне әйтеп бирергә ярдәм итүен күрсәтә.

Тукай үзе дә шагыйрь Сәгыйть Рәмигә язган бер мәктүбендә шулай ди: «Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган шагыйрь генә түгел, мин дипломат, сәяси, җәмәгать хадиме бит. **Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә**». (Вәлиди Җ. «...мөляхәзәләр». Ассызык минеке. — *Х.Г.*)

Без хәзер, Тукайга 50 яшь тулу уңае берлә, кулыбызга аның шигырьләрен алабыз, алар хакында язылган мәкалә вә шагыйребезгә багышланган хатирәләрне укыйбыз. Болар арасында иң мөһиме булып бүгенгәчә, мөһаҗәрәттә бигрәк тә, мәрхүм Җамал Вәлидинең шагыйребезнең үлүеннән соң нәшер ителгән «Мәҗмугаи асаре» берлә бергә басылып чыккан Тукайның шигырьләре хакында «...мөляхәзәләр» саналып килә. Әдәбият тарихыбыз өчен аерылып торган бу 50 еллык юбилей уңае берлә башыбызга килгән кайбер фикерләрне «Яңа милли юл» укучылары арасында уртаклашыр өчен кулыбызга каләм алганда, әнә шул «...мөляхәзәләр» берлә файдаландык. Бу «...мөляхәзәләр», сүз уңае берлә әйткәндә, шагыйрьнең вафатыннан соң язылган беренче җитди язмалар булгангамы, ничектер «Тукай китабы»ның тартып алынмастай бер өлеше булып киткәндер.

Тукай халкыбызның күңеле берлә шул дәрәҗәдә берләшеп беткән ки, халкыбыз хакында фикер әйткәндә, Тукайны искә алганда, милләтебез тугрында сүз сөйләми мөмкин түгел. Алар бер-берләреннән һич аерылмыйлар.

Җамал Вәлиди, ачы бер хакыйкать турында сүз ачып, шул сүзләрне яза: «Безнең татар халкының бер хасияте һәм хосусияте рухиясе күз алдына килә. Чөнки бу ноктада без Тукайны артык татар итеп күрәбез. Шөйлә ки, татар халкында түземлек, ихаталы күреп, ерак ноктаны күзәтеп эш күрү юк. Шуның өчен аның күп куәтләре җилгә китә, аның эшендә дәвам вә сәбат булмый. Моңа иң кечкенә эшләребездән алып иң зур тарихи әхвалебез шаһит. Татар куәи мохаййәләсе дә моннан мөстәсна түгел. Ул һичбер башы-ахыры могаййан, бөтен, тулы әтрафлы бер хыял тудыра алмады. Аның асаре-шигъриясендә хыялый бөтенлек, киңлек түгел, бәлки бер хисси чуарлык, тарлык күрәбез. Хәтта бу тарлык, бу чуарлык шул дәрәҗәдә ки, ул бөтен ике мисраглык бер җыр җырлый алмый. Һич мөнәсәбәтсез вә туп-тугры Ак Идел буйларыннан үзенең җанкәсенә күчә, тәрәзә капкачыннан туган иленә килеп төшә.囗Иштә безгә Тукайда да иң ачык күренә торган нокта元арның берсе ошбудыр. Аның әсәрләре бик аз бер кыйсеменә истисна иткәндә, кыска ноктalардан гыйбарәт. Аларны рәттән укып барсаң, үзеңне, әлеге татар җырларыны тыңлагандагы кебек, мең төрле хиснең алмашынуы каршысында күрәсең». (Вәлиди Җ. «...мөляхәзәләр».)

Тукай көннәренә багышланып язылган мәкалә вә хатирәләрдә шагыйребезгә мактау сүзләре генә язып утыру берлә канәгатьләнү җитми, бу уңай берлә гомумән милли тарих, әдәбият, тормыш вә мәгънәви ихтыяҗларыбыз хакында туган фикерләрне матбугат битләренә чыгара баруыбыз кирәк.

Халкыбызның «иң кечкенә эшләребездән алып иң зур тарихи әхвалебез»нең шаһадәте берлә аерылып торучы кимчелекле хосусиятләрен тикшерер вә җентекләргә безнең, бая әйткәнебезчә, мөһим бер әдәби юбилее уңае берлә, тик бер гади Тукайны сөюче буларак кына «тибрәтү» өчен алган каләмебезнең көче җитәрлек түгел. Көчле вә тәҗрибәле каләм ияләребезнең бу гаять дәрәҗәдә кызыклы мәсьәлә хакында игътибарлы фикерләре матбугатыбызга чыга барсалар, яшь буыныбыз өчен бик файдалы булыр иде. «Иң кечкенә эшләребез» дөньясында Җамал Вәлидинең фикерен куәтләү өчен, үкенечкә каршы, бик күп табыла торган башланып бетмәгән эшләребезнең уңыш берлә нәтиҗәләнмәүләренә нинди сәбәпләр бар? «Иң зур тарихи әхвалебез» галәмендә кайсы вакыйгалар безнең шул күңелсез хосусиятләребезгә шаһит? Чыңгыз «Яса»* сыннан калма «Башланып та бетмәгән эш — җансыз эш» дигән шигарь безнең өчен буш сүзләр генә булып калдылармыни? Җырларыбыздагы хосусиятне, «тәрәзә капкачыннан туган илгә күчүләрне» җырларыбызның аерым матурлыгыннан санаучыларыбыз да бар. Бу шулаймы?

Болар барысы да үзләренә җаваплар көтеп торучы сөальләр. Көчле бер милләтчелек агымында йөзмәктәбез; бик күп яшь йөрәкләребез, милли кыйблабызга борылып, үтмешебездән илһам көтеп торалар; алар тарих вә әдәбият сәхифәләребездән олуг каһарман вә үз кешеләребезнең исемнәрен эзлиләр; милли вә милли ифтихар тойгысы аларда көннән-көн үсә бара. Шундый вакытта мондый «...мөляхәзәләр» яшьләребезгә, табигый, файдалы яктан тәэсир итмиләр.

Тукайның үзендә дә әнә шул «хисси чуарлык» җимешләре булса кирәк.

Татар бәхте өчен мин җан атармын,
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

(«*Үз-үземә*»)

Бу шигырь берлә бергә:

Ни диерсең, сүз татар тугрында булса?
Табалмый сүз, диерсең: «ул сакаллы».

(«*Хасият*»)

Татар халкы, син үләргә мәхкүм инде,
Дару үтмәс дәрәҗәдә мәсмүм инде;
Тиберченмә, терелмисең, юл өстендә
Ятма аунап, үзеңне үзең күм инде.

(«*Милләтчеләр*»)

Җыгылдык без, икөч чакрым да китми, —
Җегетләр! Бездә көч юк, — ахры, булмас.

(«*Яшьләр*»)

Сиңа, дустым, сүзем шулдыр: татарга сатма матбугат,
Тырактир ач татарга, — сат та тор һәртөрле мәшрубат, —

(«*Бер гәзитә идарәсе хәленнән*»)

кеби күңел суындыргыч шигырьләр дә бар.

Кимчелекләребезне санау гына түгел, аларның төп сәбәпләрен вә аларны төзәтү юлларын күрсәтеп, аңлатып бирү — укымышлы сыйныфыбыз өстенә килеп төшкән милли вазифаларның берсе.

Димәк, Җамал Вәлиди әйткәнчә, Тукай әнә шул тәнкыйтьчебез санаган кимчелекле хосусиятләребездә үзе дә «артык татар», чын татар булып күренә.

Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән,
Әллә ничек! — мыр-мыр итеп мәче чыга.

*(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)*

«Вакыйган, Тукайның шигырьләренә карасак, монда былбыллык берлә мәчелек бер-берсен нәүбәтләшеп кенә тора. Аның койрыгы былбыл, башы мәче булган шигырьләре дә юк түгел». (Вәлиди Җ. Шунда ук.)

Шулай итеп, без Тукайның яратышы һәм халкыбызның рухи хосусияте арасында бик күп тиңдәш нокталар табабыз. Җамал Вәлиди дөрес әйтә: «Тукай шигырьләрен укыганда, чынлап та, татар җырларын тыңлагандагы кеби, бер тойгы сизелә». Тукайның бу хосусиятен җанландырып күрсәтү өчен, мисал итеп, аның «Саташкан» шигырен алырга мөмкин. Шуның берлә бергә күңелгә бер сөаль килә: Тукайның иҗадияте аның «артык татар» булганлыгыннан гына шундый бер «хисси чуарлык» эченә төрелгәнме? Аның түбәндәге шигырьләре шагыйрьнең шәхси хәятында, эчке дөньясында мәҗбүри рәвештә шундый бер «тарлыкта» булуын күрсәтмиләрме?

Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым,
Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм.

(«*Хәстә хәле*»)

Йә, минем кайда хикәям? Ник аны читкә борам?
Юк, зарарсыз: мин шулай язган чагында йөткерәм.

(«*Күк сыер*»)

Бу «йөткерү»ләрнең аның яратышына башка яклардан да тәэсирләре юк түгелме?

Тукайны сөеп укучылар: «Тукай китабын кулга алган саен, анда бер яңа нәрсә табасың», — диләр. Гаҗәп түгел. Чөнки, югарыда әйтелгәнчә, Тукай — «күзе күпне күреп, колагы күпне ишетеп» язган шагыйрь... «Сәнгать — сәнгать өчен» дип кенә җырлаган бер шагыйрь түгел. Безнең милли аңыбыз, милли хисебез үсә барып, мәгънәви тормышыбызның офыклары киңәя вә тәҗрибәбез арта барган саен, Тукай шигырьләре күбрәк аңлана барачак.

Олуг кешеләрнең кыйммәте, карагыз, ни дәрәҗәгә җитә! Инглиз Карлейль шулай ди: «Күрәсез, Шекспир безнең өчен кем булып китте?! Ул безнең иң бөек бер мәликебез. Чит халыклар арасында үзебезнең милли шөһрәтебезне таныту мәнфәгате йөзендән без һичбер вакытта да Шекспирдан кайтылачак түгелбез. Әгәр бездән сорасалар иде: «Инглизләр, сез кайсына разый буласыз: үзегезнең Һиндстанда биләп торган җирләрегездән ваз кичәргәме яисә үзегезнең Шекспирыгыздан ваз кичәргәме?» Бу, әлбәттә, чит бер сөаль булыр иде. Әмма без шулай дип җавап кайтарырга мәҗбүр булганлыгыбызны сизәр идек: «Һиндстандагы мөстәмләкәләребез безнең кулда калырлармы, юкмы, — әмма без Шекспирсыз бервакытта да булмаячак!»

Тукай төрк-татарның Шекспиры түгел. Без аны кирәгеннән артык күтәрмибез. Ләкин (ул) үзебезнең зур бер кешебез. Аның кадерле исеме үлмәячәк. Ул «...милләт яшәдекчә яшәр, милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар». Чөнки бу халкыбызның иң моңлы баласы, милли хәзинәбезнең иң ярлы вә мохтаҗ чагында, шуңар үзенең бер ятим күңелендән «ярты җырында йөткерә-йөткерә» бер мәгънәви өлеш чыгарып, «иң гади күзләр» өчен дә кыйммәтле булган бер мирас калдырды. Үзенең бик иртә өзелеп киткән ялгыз гомеренең соңгы секундларына чаклы талант көчен аямады.

Кызганыйммы: безнең ярдәм киткән чакта,
Төзәлергә, вәйран булган Кәгъбәмезгә?!

*(«Ислахчыларга»)*

**Сәгадәт Чагатай**

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Бу елның ниндидер бер көнендә илемезнең бик яшьли дөньяны ташлап киткән атаклы шагыйре Габдулла Тукайның 50 яшен тутыру мөнәсәбәте берлә милли матбугатта берничә язу чыкты. Бу илле яшь берлә бергә Габдулла Тукайның шагыйрь булып таныла башлавына 30 ел кадәр вакыт кичеп китүене дә вә бу еллар эчендә Тукай әсәрләренең халкымыз арасында елдан-ел таралуыны, шуның берлә бергә Тукай да үсә баруыны да хәтерләвемез кирәк.

Үз илемездә аз гына бер хөрлек булса, бу илле яшьлек Тукай хөрмәт ителер, бу хакта күп язулар, тәнкыйтьләр, тәкъризләр язылыр иде. Ләкин хәзерге дәверебез, әдәбият дәвере булудан артыграк, көннән-көн сәяси дәвер була барганга, мөһаҗир мохитендә вә мөһаҗир хәятында Тукайны коры хәтерләү, аның хакында язылган иске сүзләрне тәкрарлаудан гыйбарәт булып каладыр. Әлбәттә, бу күп җәһәттән ноксан исә дә, Габдулла Тукайның «Зур Тукай» булуына катгыян зарар китерми; аның шигырьләре вә боларның эчендәге фикерләре һичбер мәгънәсен дә, киңлеген дә югалтмыйдыр.

Бик күбебезнең күңелендә Габдулла Тукай саф күңелле, киң көрешле милләтче бер егет, бик күп мәүзугълар үзәгендә яза башлаган, фәкать мәрхәмәтсез үлем якасына тотылып, шул эшләрне дәвам иттерә алмаган бер шагыйрь булып торадыр. Аның башлаган мәүзугъларын, мәсәлән, халык әдәбиятын тикшереп, аны язма әдәбияты хәленә кую, мәгънәви юллар күрсәтү берлә әхлак кагыйдәләрен тикшерү, тәрбия, вәгазь-нәсихәтне халык арасында җәю, халык аңларлык бер тел берлә яңалыкка үсүгә димләү кеби тирән мәүзугъларны дәвам иттерү, аларны тәнкыйть итү һәм җитмәгән җирләрен тутыру вазифалары күз алдыбызда торадыр.

Ләкин мәүзугъларның киңлеген, тирәнлеген хәтердә тотып, илебезнең бүгенге көндәге мәгънәви вә икътисади авырлык вә тарлык эчендә яшәвен, мөһаҗир хәятының да мең дә бер мәшәкать берлә көнне көнгә ялгавын онытмыйча, кыйммәтле Тукаебызның бик яхшы шигырьләрен укып, зәгыйфьләрен өскә чыгармыйча тору иң тугрысы кеби күренә. Габдулла Тукай — бик яшьли үлгән бер егет. Аның шәхси тормышының никадәр авырлык эчендә кичкән булуы, аның тәрҗемәи хәлен укучылар һәм белүчеләр тарафыннан гына түгел, кайбер үзе хакында язылган шигырьләрне генә дә уку җитәдер. Шул соңсыз авыр шәхес тормышына аның дәверендәге мохитне, аның мәхдүдлеген дә онытмау яхшы булмас. Габдулла Тукай искелек берлә көрәш бик каты барган вакытта, яңалык вә уяну башланган чакта кыска шагыйрьлек дәверен яшидер. Ул шул дәверне атлап кичкән башка шагыйрь вә мөхәррирләремезгә охшамый, ул, шул дәвернең начарлыгының корбаны булып, үзенең бик сөйгән халкыннан аерыладыр. Тукайның соңсыз кыйммәте дә уяну дәвере берлә искелек хөкем сөргән дәвернең әхвале рухиясен, яхшылыгын вә начарлыгын ачык тел берлә язып китүендә вә шуның авырлыгы басынкылыгында кайбер вакытта бәдбинлеккә төшеп:

Җегетләр! Бездә көч юк, — ахры, булмас, —

*(«Яшьләр»)*

диюләре Тукайның шул дәверне никадәр тирән һәм эчтән яшәвен генә күрсәтәдер. Аның шул рухсыз вә бәдбин язуларында:

...бетте көч, сынды кылыч... —

*(«Кыйтга»)*

дип үзе хакында ачы сүзләр язып калдыруы Тукай берлә шул дәвер капанган. Тукай шуның корбаны, һәм ул шул тирән шигырьләре берлә өмидсезлек, тарлыкны, тәгассебне, урта халык арасындагы бушлыкны җиңүче бер фидаи булып торадыр. Тукай үзе яшәгән вакыттагы дәвернең күп авырлыгын үзе берлә бергә алып китте, аларны җиңгән бик күп (үз дәверенә күрә) вәгазь-нәсихәт, һөҗү-көлке, Аллаһка, милләткә ышану куәте калдырып китте. Аның рухсыз, бәдбин, тар һәм хәтта «башы — мәче, койрыгы — былбыл» булган, пешмәгән шигырьләре дә шул дәвернең көзгесе итеп каралырга кирәк. Тукайның үлүенә 23 ел булган шикелле, аның үлемендән соңгы 23 ел эчендә безнең төшенчә вә көрешләремездә 23 еллык аерма бар. Әгәр безгә Тукайның шул кыска гомере эчендә язып, нәсихәт итеп калдырган кайбер тар фикерле шигырьләре авыр тәэсир итсә, Тукай хәзерге хөрмәтен казана алмас иде. Әгәр шул шигырьләр хакыйкатән дә безнең олугымызны-кечебезне үстерүче, мөсбәт һәм мәнфи яктан үзлеген онытмаучы мәгънәви азык булмасалар иде, аның күңел суындыргыч шигырьләре безгә начар тәэсир итте һәм итә, дия алыр идек. Без

аларны атладык. Аның бары иң яхшы шигырьләрен чүпләп, шуларны милли дога урынында йөртәбез, башкаларын Тукайга һәм аның дәверенә гаид, үземезнең хаталарымызны күрсәтә торган вә авыр тормышымызның баскынлыгы астында әйтелә торган ачы фөрьядлар дип беләмез.

Тукай безнең каршымызда һичбер вакыт бер яшь егет булуын югалтканы юк. Бер яшь кеше, никадәр истигъдадлы булмасын, күп еллар яшәгән, күп дәверләр кичергән олуг бер кеше түгел. Шуңа күрә Тукайның кайбер фикерләре, бик җанлы булуга карамастан, тәҗрибәсез һәм соңгы ноктасын күрә алмаган булуы бик ихтимал. Ләкин безнең Тукаемыз гына түгел, бөтен халкымыз үсү дәверендә булганга, аның бәгъзе бер оешмаган нәрсәләрен яшь, үсү, алга үрләү вакытын кичерүче халык булуымызга багларга кирәк. Без хәзергә кадәр, никадәр зур адымлар аткан булмыйк, бөтен, тулы җитешкән бер милләт булып өлгергәнемез юк. Без шуңа омтыларак һәр көнне адымнарны иләрләтәмез һәм бер җитешкән милләт ирешәчәк баскычларны да ирешәчәкмез. Баскычларның югарысына ирешә барган саен, бәлки, Тукайның «мәче»лекләре безгә ямьсез күренер, ләкин без аны һәрвакыт зур авырлык берлә шул баскычларга менүне җиңеләйтә башлаучы, безне матур тел, ачык каләм берлә бер тиргәп, бер вәгазьләп, бер безнең нечкә тойгыларымызга тукынып, хисләремезне арттырган кеше, «Кечкенә Апушымыз» һәм «Зур Тукаемыз» итеп күрәчәкмез.

Тукайның тәрбияче, нәсихәт вә вәгазь берлә кешелеккә димләве вә үзенең арасындагы бушлыкларга каты мөтәәссир булып, былбыл шикелле сайраганда, мәче төсле мияулап куюы да аның бары үзенең тоткан тәрбиячелегенең яшьлеген төшенүен генә күрсәтәдер. Тукай балалар өчен язып калдырган бик матур шигырьләре берлә үзенең бала сөючән рухын, үзенең халкының балалык дәверен кичерүен вә халык өчен бала тәрбияләү киләчәк өчен иң нык нигез булуын күрсәтеп торадыр. Бу да, фикеремчә, Тукайның иң беренче зур кыйммәтле сыйфатларындан берседер.

Ихтимал, Тукай илле яшендә булу мөнәсәбәте берлә бик күп җирләрдә Тукайны хөрмәтли алмыйбыз. Тукайның кем икәнен тулы көенчә аңлый алмадык, дип уйлаучы һәм йөрәге тетрәүчеләр булыр. Бу самими Тукайны сөючеләргә җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүмат бирелә алмауны кызгансак да, Тукайның шәхсиятен хөрмәтләүдән, аның самимилегендән, милләтчелегендән бетмәс-төкәнмәс куәт алырга мөмкин булуын хәтерләтеп, яшьли үлгән Тукайны яшәтү, даимән аның берлә бергә булу өчен шигырьләрен тагын да күбрәк укуны тәүсыя итү иң тугрысы булыр.

**Рокыя Мөхәммәдиш**

## ТУКАЙНЫ ИСКӘ АЛГАНДА

Безнең халыкның милли үзлеге белән әсәрәтенең ачылыгы Тукай иҗатында җанланганга, шагыйрьнең вафат булган ае апрель безнең халык өчен башка айлардан аерылып тора. Апрель керү белән халкыбызның карты-яше үзен әллә нинди бер бурыч алдында кебек хис итә башлый. Бу хис халыкның бөек шагыйренә каршы булган шөкеране вә мәхәббәте.

Тукай иҗатын тикшерү бер шагыйрьне тикшерү генә түгел, халкыбызның күңел тормышын, 15 апрельдә Тукай истәлекләре ясап, шагыйрьнең тормышы, иҗаты белән танышканда, иң төп нокта итеп аны чолгаган мохитне, аны тудырган халыкны, ул яшәгән әсир Идел буен алу кирәк булачак. Чөнки бер шагыйрьнең дә, бер язучының да иҗаты мохиттән тыш, тирә-якның тәэсиреннән тыш ясалмый. Үзләренең эчке халәте рухияләреннән тышка чыга алмаган шагыйрь һәм язучылар, өслүбләренең матурлыгына, телләренең садәлегенә карамастан, халык күңелендә урын таба алмаган кебек, халык белән бергә халык яшәгән кадәре үк яши дә алмыйлар.

Тукай кебек халыкның күңелен тибрәтә белүче, иҗатларында халык күңеленең парчаларын җанландыра алучы шагыйрьләр исә халык яшәдекчә яшиләр, халыкның милли-мәдәни зиһнияте күтәрелгән саен күтәрелә баралар.

Тукай көннәре, Тукай истәлекләре мөһаҗәрәтебезнең тормышында елдан-ел тирәнрәк урын алып киләләр. Милләтчелек, милли барлык хисе куәтләнгән саен, Идел буеның кыйммәтле шагыйре Тукайның әһәмияте күтәрелә бара. Тукай арабыздан киткәнгә, чирек гасыр якынлашкан вакытта, Тукайның милли хәзинәбезгә бүләк иткән кыйммәтле энҗеләреннән инде әллә никадәр милли байлык хасил ителгән булыр иде. Ләкин илдә әле, халкыбызның милли барлыгын көзгедән күрсәткәндәй, шагыйрьнең кыйммәтен үлчәргә вакыт юк. Аның урынына анда төрк-татар халкына һичбер төрле мөнәсәбәте, милли-мәдәниятебезнең инкишафы өчен һичбер төрле багланышы булмаган Пушкин юбилейлары уздырыла, әллә нинди кызыл русларның безнең өчен ике тиен бер акчалык кыйммәте булмаган истәлекләре ясала. Бүгенге көнне Татарстан җөмһүрияте исемен ташучы илебез чар хөкүмәте кул астындагы тоткарлыгыннан әле дә котыла алганы юк. Тукай үлгәннән соң аның бер еллык истәлек мәҗлесләрен ясарга ирек бирмәгән чар жан-

дармасы төсле большевик хөкүмәте дә Тукайның егерме еллыгын мөмкин кадәре тавышсыз-тынсызрак уздырырга тырышты. Тукайның милли хискә, халыкка, мәхәббәткә манчылган иҗаты русның карасын да, кызылын да бер үк сәясәт кулланырга кушты. Гомеренә бер генә мәртәбә дә сәясәт белән очрашмаган Тукайны чар хөкүмәте күзендә ихтилялый ясаса, большевик күзенә аны антиреволюционер итеп күрсәтте. Бер үк Тукай ике төстәге, ләкин шул ук рус өчен зур бер дошман булып күренде.

Тукай истәлекләре, Тукай кичәләре ясап, Тукайны читтә яшәүче яшь буын белән таныштырырга тырышканда, Тукай вә аның иҗатын өйрәтә торган материалларга шактый фәкыйрь булсак та, кара һәм кызыл русның Тукайны халкыбызның күзендә әһәмиятсезләндерергә омтылу да бара. Шулары гына да безгә Тукайны халыкка милләтнең әсирлегенә эчтән янучы шагыйрь икәнлеген күрсәтергә җитәчәк.

Тукайның гомере бик кыска булса да, аның көчле истигъдады зур бер байлык калдырды. Шулай да әле аның иҗаты хакында әйтеләсе сүзләр, йөртеләсе фикерләр бетмәгән. Тукайны тикшерү, аның иҗатын өйрәнүнең чикләре әле чикләнмәгән. Тукай вә аның иҗатын иң тулы һәм иң иҗади рәвештә тикшерүче тәнкыйтьче Җамал Вәлиди карашын нигез итеп ала алабыз. Ләкин шуның белән Тукай әсәрләре арасында яшерен мәгънә эзләве, аның шигырьләреннән Тукай яшәгән заманны аңлау имкяне әле Тукай шигърияттен сөючеләр өчен ябылмаган.

Тукай иҗаты ул яшәгән дәвер өчен генә булмый, халкыбызның бөтен барлыгына баглы булган Тукай шигъриятенең чиксез байлыклары арасында эзләнү елдан-ел үсәчәк. Тукайны искә алу уңае белән язылган тәнкыйтьләрне, аның бөек истигъдадына каршы хөрмәтеннән язылган мактау сүзләрен укыганда, шактый гына төрле фикерләргә, төрле каршылыкларга очрыйбыз. Тукайның шигырьләрен укып булса да, Тукайның Идел буе төрк-татарының иң зур шагыйре, төрк-татарының матурлыгын шигырь вәзеннәренә иң оста итеп сала белүче икәнен аңлыйбыз. Илебезнең һавасын иснәп, суын эчеп үсмәсәк тә, Тукай шигырьләре аркылы үзебезнең илебезгә баглы итеп хис иткәнгә, халкыбызның күңелендә Тукай иҗаты никадәр урын тотканын төшенә алабыз. Чөнки Тукай иҗаты — туган илебезнең күренеше, халкыбыз тормышының көзгесе, аның шигырьләрендәге төрлелек, аның күңелен дулкынландырырга, шигырь вәзеннәренә түгелергә сәбәбе булган халкыбызның әсирлеге вә шуңардан туган халкыбызның ачы тормыш шартлары.

Тукай иҗатын тикшергәндә, халкыбызның тормыш шартларының тоткарлыгында, Тукай иҗатының сәбәпләрен эзләгәндә генә Тукай яшәгән, Тукай иҗатының үскән-гөрләгән көне, безнең халыкның аз гына сулыш ала, алга атлый башлаган көннәре иде. Шулай да дошманның изү-кысу ачысы халыкның күңеленнән китмәгән, халык өмет белән өметсезлек арасында яши иде. Тукай кебек сизгер күңелле шагыйрьнең халыкның бу халәте рухиясен күңеленә якын алуы табигый иде. Шунлыктан аның шигырьләре, бер яктан, башлыклар, икенче яктан, өметсезлеккә чыгып, татарның бөтен барлыгына кул селкерлек дәрәҗәгә җитәрлек иде. Тукайның өметсезлеге халыкның көче барлыгына ышанмаудан түгел, әсарәт богауларының ныклыгы алдында җиңелүдән иде. Чөнки 1905 елның кояшы белән чәчәк атарга бөреләнгән Тукай, аннан соңгы елларның катылыгын, суыклыгын күреп, өметсезлеккә төшкән иде. Шунлыктан Тукай шигырьләренең күз яше белән көлү арасында булуы да табигый. Ул бер өметләнеп иреккә аша, бер тәмам җиргә иңә, тәмам бетә.

Халкыбызның язмышы Тукай язмышы белән бер булганга, безнең өчен Тукай вә аның иҗаты үзлегебез кебек үк кыйммәтле. Тукай — халыкның үз баласы, аның иҗаты да безнең халыкның үз милли байлыгы, Тукайның кадере дә безнең халыкның кадере вә дәрәҗәсе күтәрелүенә, үз иркенә үзе хуҗа булуына баглыдыр. Бүгенге көнне рус большевигының боерыгыннан тыш һичбер нәрсә эшләргә имкяне булмаган халкыбызның Тукай көннәрен ясый алмавы гына безнең халыкның күңеленнән Тукай шигырьләренең рухын ала алмаячактыр. Большевикларның Тукай иҗатына ялган ноктаи назардан каратып, аны танырга, яңа юллар ачтыру белән Тукайның саф иҗатына тап төшмәгән кебек, большевикларның әмере аркасында гына милләт сөюенең мисалы булган Тукай да халык күзендә үзенең әһәмиятен югалтмаячактыр.

**Хөсәен Габдүш**

## ТУКАЙ — ИЛ УГЛЫ

Җырлап торам, торган җирем тар булса да...

*Г.Тукай*

Исемен Идел буе төркләре тарихында мәңгеләштереп вә аны гасырлар аркылы киләчәккә җиткергән бәхетле халык хезмәтчеләре җөмләсеннән шагыйрь Габдулла Тукайны арабыздан югалту көнен һәр ел билгеләп узу белән бер бөек Кушлавыч ятименең исемен танучы вә хезмәтен аңлаучылар күбәймәгәндер.

Көз көне башлангыч мәктәпнең беренче кат бусагасын атлап, кулына милли әлифбасын алып, яз башына (апрельгә) чаклы инде «төрки» танып өлгереп, Тукай кичәсенә шагыйрьнең «Туган тел»ен сәхнәгә

чыгып сөйли алырлык гөнаһсыз яшь баланың безнең каршыбызда киләчәктә халкыбызга хезмәт итәрлек бер кеше булып чыгуына өмид бирә, безне шатландыра, сөендерә...

Әгәр милләтнең хәятына каршы бу өмидле сабыйдан киләчәктә халыкка файдалы чын бер инсан килеп чыга икән, ул үзенең бу бәхете белән дини-милли мәктәптә аны кеше итү өчен роль уйнаган гамәлләр арасында, бер дә шиксез, Тукай шигырьләре аркылы иң беренче кат нәфасәт вә матурлыктан рухан авыз итеп, олуг бер мәхәббәт, милләткә вә әдәбиятына булган мәхәббәткә сәвекъ белән кушылуын сизенгән минутларына бурычлыдыр.

Тукай сүзе шундый бер бәрәкәтле орлык ки, ул һәрбер күңелдә үзенә кирәкле зәминне, мәгънәви туфракны таба ала. Күңел бер мәртәбә иң матур теле, музыкасына бирелдеме, ул инде бу татлы әсирлектән котыла алмый вә, әлбәттә, котылырга да теләми. Тәнкыйтьче Габдрахман Сәгъди Тукайның «Күңел» исемле шигыре хакында шул сүзләрне яза: «Шагыйрь, шаһид мөхтәрәм Габдулла әфәнде Тукайның ошбу шигыре күңелебезне бөек урыннарга ашыручы гали хисләр вә бәлән фикерләр белән тулы булып, хиссият вә әфкяре галия өчен аның беренче гүзәл мисалларыннандыр. Зан итәмен ки, Габдулла әфәнденең намене оныттырмас һәм шагыйрьлекне иман итүчән ялгыз шушы шигыре генә дә җитәчәктер». Бу сүзләр, бәлки, арттырып та әйтелмәгәннәрдер, тәнкыйтьченең «Кавагыйде әдәбия»сеннән күчерелгән бу җөмләләр шул ук китапның мөбаләга бабы өчен матур бер мисал да булырлар иде. Бу урында исә әлеге сүзләр шагыйрьнең күңелләргә тәэсиренең көчен күрсәтү өчен китерелделәр.

Юкса без Тукайның бер генә шигыре берлә канәгатьләнү түгел, киресенчә, аның «Күк сыеры»ның да язылып бетмәвенә тәәссеф, комсызлык белән аның тормышыбызның һәрбер тармагы белән баглы булган шигырьләрен үлчәргә, өйрәнергә теләүчеләрдәнбез.

Кем соң ул Тукай?

Бу һәрвакыт безнең башыбызга килеп тора торган бер сөаль. Моңа һәркайсыбызның бик дөрест кенә, «шәп» кенә канатлы бер гыйбарә белән җавап бирәсебез килә. Гүя шул «канатлы» сүзне тотып алып, бу сөальгә каршы җавап итеп куя алсак, күңелең тынычланачак та. Аннан соң инде тагын да рәхәтләнебрәк, тагын да иркенләбрәк Тукай шигырендә, аның яратыш зәмзәмендә рухан йөзәчәксең.

Һәм шундый бер халәте рухияне үткәрми килү, чынлап та, ихтыяҗ бик кирәксенү дәрәҗәсенә барып җиткән икән. Мин моны әле күптән түгел генә Украина халкын уятучы Тарас Шевченкога багышланган бер шигырьдән алынган өземтә тәэсирендә бигрәк ачык тойдым.

Җәбһәдәшләребез украинлыларның бөек шагыйре Шевченко белән танышлыгым бар дип мактана алмыйм. Әмма шулай да аны үзебезнең Тукаебыз кебек бер зур кеше икәнлеген әйтеп куючылардан берсемен. Кыскасы, әсәрләрен укымасам да, аның кемлеген белә идем. Шунлыктан да түбәндә күчереләчәк, аңа багышланган шигырь өземтәсен укып чыгу миңа, менә дөрест әйткән, дигән бер уй бирде. Бу юлларның көчле тәэсире берничә көн дәвам итте. Зәгыйфь кенә тәрҗемә итеп булса да, укучыларга аны күрсәтеп китмәкче булам:

Шагыйрь түгел — чөнки бу гына әрнеткеч дәрәҗәдә аз* ,
Хатыйп түгел — чөнки бу тавышына боргы гына.
Һәрхәлдә инде түгел «Кобзар Тарас».
Ул шул кем белән янып кителде, гөрләп кителде.
Дөрестә киләчәк «асау» халык төркемнәренең гыйсъяны,
Бер ялкыны ки кебек өстендә ирде җәһаләт.

Мин Тукай белән Шевченко арасында янәшәлек уздыру теләгендә түгелмен. Әгәр сүз җае килгәндә мондый бер чагыштыру кирәк була икән, исегезгә төшереп узыйк: Мөхтәрәм Җәгъфәр Сәед Әхмәднең үзенең «Кырым» исемле китабында Гаспралы Исмәгыйль бәкне татар Шевченкосы дип атый. Безнең бу урында Украина шагыйренә багышланган юллар өстенә тукталып торуы бездән максат, шул баягы «Тукай кем?» сөаленең шагыйрь хакында сүз чыккан саен башыбызга [...]** килмичә җитди рәвештә зиһенебезне биләп торуын рәсмиләндеребрәк күрсәтүдер.

Бу сөальгә кирәк Җамал Вәлиди, кирәк шул ук Габдрахман Сәгъди вә башка күп кенә игътибарлы каләм ияләреннән бирелгән җаваплар күп.

Вәлидичә: «Тукай татар тарихында мәңге онытылмаслык бер исем! Минемчә, — ди ул, — «Тукай кем?» сөаленә иң мөнәсәбәт җавап вә шулай ук Тукайга иң кыска тәгъриф татарга иң матур сүзләр сөйләүче» дигән җөмлә булачак».

Сәгъдичә: «Тукай беренче романтик халык шагыйре иде. Ул бөтен вакыйгаларны тиз сизүчән, вакытында тасвир итүчән иде. Җәмгыять эчендә туган фикер, хис-зәвыкларны бик тиз аулап, карты, яше аңларлык сәнгатьчә бик матур шигырь теленә күчерә белүче, татарлар арасында дини, милли тойгыларны яңа замана киеменә төреп бирүчеләрдән беренче Тукай иде».

Тукай — татарның иң көчле сентименталист-романтик йөрәк шагыйре...

Бу рәвешчә, Тукайны аңлата торган сүзләрне бик китерергә мөмкин. Әмма күңелне һаман кытыклап торган «бу гына җитми» дигән кебек бер китеклек, канәгатьсезлек һаман да дәвам итеп тора шул.

Үземчә бу рухи халәтемне коры бер бәйләнчек уй һөҗүменнән генә килә дип әйтә алмыйм. Мондый бер ихтыяҗны, шөбһәсез, укучыларның күбесе башларыннан уздыралардыр. Җамал Вәлиди бик хаклы рәвештә әйтә: «Телебезнең кадере күтәрелгән саен, Тукай күтәрелә барачак. Милли аңыбыз, милли хисебез арткан саен, Тукай аңлана барачактыр». [...]* милли хисебез вә аңыбызның үсеп, чәчәкләнеп, җирләшеп китәр көннәре әле алда. Безнең башыбызга «Тукай кем?» дигән сөальнең дә килеп торуы, үзенә җавап соравы бик табигыйдер. Үзеннән-үзе күз алдына килә:

Әнә киң ил... Аның җәйләүләре**,
«Фирдәүс»нең гөлле сахрасы
Фәҗигъ өннәр биреп еглый. Ләкин
Ул җәйләүнең тормыш сәхнәсе.
Сахрасында җәннәт нуры балкып,
Ләкин анда яңгызы зарлану.
Киң илдә дә шундый җәйләүләрдә
Тормышыннан сызлап тазлану.

Шул киң ил эчендә Тукай күкрәген киереп җырлый алмады. Юк, менә Тукайның сүзләре:

Җырлап торам, торган җирем тар булса да...

*(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)*

Дөрест, безләр бәхетсез [...]*** «Киң ил тарлыкта әле. Ул өннәр биреп еглый»... Ул көтә...

Ил көтә... ярга басып****,
Ярдәм көтмәсен ил көтә;
Ул төшермәскә тели,
Сынган канатын селкетә.

Ач-ялангач адәмнәр
Тезгән бәхетсез ил көтә.

Идел буе иркенләнгәч, төрк-татар халкының мәдәни вә мәгънәви тормышы, аның милли үзлеге таләп иткәнчә, үзенең тарихи эзенә төшкәч, мәгънәви офыкларыбызның киңлегендә, Ходай кушса, бөтен рухани тулылыгы вә бөтенлеге белән аңлашыр, беленер, үзенең дәрәҗәсенә күрә танылыр.

Шагыйрь Габдулла Мөхәммәдгариф углы Тукай — бөек ил углы.

**Гаяз Исхакый**

## ТУКАЙНЫҢ ВАФАТЫНА 25 ЕЛ ТУЛУ МӨНӘСӘБӘТЕ ИЛӘ

Үзләренең шәхси кабилиятләре берлә бер-берсенә охшау-охшамауларына карамастан, шагыйрьләр үзләренең багланган мәктәпләре игътибары берлә икегә бүленәләр. Бер төрлесе, үзен-үзе тирә-юненнән аерып алып, үзен чорнаган мохиттән рухан аерым була ала торган, үзенең төшенчәләре, хиссиятләре эчендә генә тәҗәрред итә ала торган, вә бу вакытта гына шигырь ярата ала торган шагыйрьләрдер. Икенчесе, үзен тирә-юньнең, мохитнең бер өлеше итеп хис итеп, шуның бөтен күңел алышуларына, үзенең йөрәк тибүе берлә катышып, аның шатлыгына сөенеп, аның кайгысына янып, шул шатлык-кайгыдан дәрт алып кына шигырь ятучыларырдыр. Беренчеләре үзләренең шәхси рухының тирәнлеге, сайлыгы, кабилиятенең көченә карап зәмин — заман берлә багланмаган вә һәрберсе аерым бер шәхсиятнең төсе, исе килә торган индивидуаль шигырьләр мәйданга ташлыйдыр.

Бик күп вакытта мөҗәррәд мәүзугъларда яисә бөтен адәмчелек өчен уртак булган мәүзугъларда язып, язу теле игътибарга алынмаганда, безгә бәйнәлмиләл шигырьләр бирәдер. Икенчеләре туган халкы, аның тирә-юне, яшәгән мохитенең шул вакытта кичергән уйлары, хисләренең тәрҗеманы булып, шул халыкның шатлыгын, кайгысын, өмиден сөйләүче, үз мохитенең иҗтимагый омтылышларын төсләндереп яшәүче, җәмәгать эшләренең һичберсе яныннан күз йомып, колагын тыгып үтә алмаучы җәмәгатьче шагыйрьләрдер. Бу төрлесе, үзенең көче, кабилиятенең зурлыгы-кечкенәлеге, тирәнлеге-сайлыгына карап, яшәгән мохитенең термометры ролен уйнап килеп, үзенең шул термометр дәрәҗәсенең нечкәлек-тупаслыгына карап, халыкның күзеннән кан-яшь агуын, йөрәк тибүен җырлап торадыр. Бездә Сәгыйть Рәми беренче

групптан булса, Габдулла Тукай менә соңгы төстәге шагыйрьдер. Үз мохитенең шатлыгын, кайгысын, дәрден шигырь төсенә сугучы бер тел остасыдыр. Аның яшәгән, язган дәвере бездә милләтчелекнең иң кайнаган, милли теләкләрнең берсе өстенә берсе үсеп, тирә-якны тутырган вакыт булганга, ул шул теләкләргә, шул омтылышларга бер шигырь төсе бирүче, чуалчык фикерләрдән туган агымнарга тугры юл күрсәтергә теләүче хезмәтчесе — милли шагыйредер. Шагыйрьлегенең әүвәлге дәверендә үк ул, үзенә үзе шул хакта сөаль биреп, шул сөальгә үзе үк тә җавап бирәдер:

Тик милләткә хезмәткә мәхәббәт миндә бар!
Минчә монда ямь дә бар, ләззәт тә бар һәм тәм дә бар! —

*(«Ләззәт вә тәм нәрсәдә?»)*

ди. Гомере буена менә шул милләткә хезмәт аның бөтен иҗатында Тимер Казык йолдызы булып, аның кыйбласы булып барадыр. Бөтен кыска гомере буенча ул шул милли юлдан һичбер тайпылмаенча, кабергә кадәр милләт җырын җырлап, милләт кайгысын көйләп, милләт көлкесеннән көлеп, үзенең иҗатын шул милләтчелек калыбына сугып киләдер. Ялгыш кына да, каләме шуып китеп тә ике юллык кына бер шигырьне дә шул алган юлына хилаф төстә язмыйдыр, яза да алмыйдыр. Менә шул җәмәгатьчелеге аны бик тиз көндә ул вакытның иң зур ихтыяҗлары булган тәрбияви шигырьләр язарга аннан таләп итәдер. Ул, милли вазифа башындагы гаскәр кеби, берсе артыннан берсе балалар өчен, кыйраәт китаплары өчен йә тәрҗемә, йә оригиналь бик күп шигырьләр, әфсанәләр, хикәяләр мәйданга китерәдер. Ул бу бүлек шигырьләрен үзенең ана теленә һимнә язу берлә башлыйдыр. Аны иң кечкенә балалар аңларлык дәрәҗәдә садә итеп эшләп, безгә телемезнең кадере-хөрмәте хакында моңарчы тиңе күрелмәгән һимнә багышлыйдыр:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

*(«Туган тел»)*

Милли хис вә милли гакыл бергә кушылып эшләнгән бу шигырь парчасы Тукайның тәрбияви шигырьләренең иң кыйммәтлеседер. Моның аркасындадыр ки, бу шигырь бөтен мәктәпләремездә милли һимнә төсен ала алмыштыр, вә бу шигыре Тукайны мәңгегә безнең балаларның иң сөйгән бер җырчысы итеп куймыштыр. Ул дәвер безнең мәктәпләребезне яңа юлда миллиләштерү, мәктәпләребезнең эченә үзебезнең милли мәгънәвиятебезне җирләштерү булганга, бу юлда бик күп дәреслекләр, кыйраәт китаплары хәзерләнеп ятып, төрле төстәге садәчә язылган тәрбияви шигырьләргә ихтыяҗ бик зур хис ителеп, һәрбер китапчы Г.Тукайга шигырьләр сорап мөрәҗәгать итеп торганга, бу вазифаны үти алучы иң муафыйк бер кеше булып чыккандыр. Бик күп чагында мәүзугъ эзләп торырга да вакыт булмаенча, рус әдәбиятында язылган шигырьләр, әфсанәләрнең мәүзугъларын алып, аларны үзебезнең калыпка салгандыр. Шулай итеп, Тукайның мәҗмугасында очрый торган Пушкиннан, Лермонтовтан, фәләннән кеби бәгъзе шигырьләр җирләшкәндер. Бу шигырьләрне эшләүдә Тукай бер тиенгә бер тиен тәрҗемә итмәү берлә генә калмаенча, боларны вәзен ягыннан да, аңлаешы ягыннан да тәмамән милли төскә куеп, аларны үзгәрткәндер. Вә аларда укучының милли зәүкын кытыршыландыра торган бернәрсә дә калдырмагандыр.

Ул вакытыбыз үзебезнең мәдәни истикъляллебезне кору дәверебез булып, руслыктан мөмкин кадәр озаклаштырырга омтылу чагыбыз булганга, Тукайның бу төстәге шигырьләр язуы охшап бетмәгән даирәләр дә аз булмагандыр. Бу даирәләр бу кадәр күп рус исемнәре берлә Тукай шигыренең бәйләнүен, Тукайның ул вакыттагы милли шагыйрьлек исеменә мөнасиб күрмәгәннәрдер. Мәҗмугалар, гәзитләр, аерым рисаләләр аша гына Тукайның иҗатларын сөргендә тәгъкыйб итеп ятучы, бу сәтырларны язучы да, 1912 елларда Фатих Әмирхан аша Тукайга, шул хакта сак булуын тәнбиһ итеп мәктүбләр язган, нәсихәтләр биргәндер. Моның кеби язучылар бер генә, ике генә булмаган кеби, Тукайның дуслары үзен хөрмәт иткән кешеләре тарафыннан булганга, Тукай да боларны әһәмиятсез калдырмаган. Соңгы дәверендә чын мәгънәсендә мөстәкыйльлек юлына кергәндер.

Икенче яктан, Тукайның болай бик тиз рәвештә халык шагыйре булып өлгерүе кайбер тар күңелле даирәләрдә аңарга каршы көнләшү уе уяткандыр. Бу хәрәкәтнең башында булган мөхәррир Галимҗан Ибраһимов аны ул заманның беренче группка кергән шагыйрьләре Сәгыйть Рәми, хосусән Дәрдемәнд берлә чагыштырып, Тукайны шагыйрьлек тәхетеннән төшерергә маташкан. Аның йиренә үзе бай, үзе нашир, үзе шагыйрь Дәрдемәндне мендерергә тырышкандыр. Шул вакытларда рус әдәбияты, рус шигыре астында тәрбия ителеп, милли мәсьәләләргә феодализмның калдыклары дип карый торган, милли әдәбиятка марксизм ноктасыннан диган булып, милләтсезләнү бакышы берлә карарга өйрәнгән яшьләр группы, башларында Хөсәен Ямаш булдыгы хәлдә, Тукайны кечеләндерергә, Тукайны дәрәҗәсеннән төшерергә бер кампания ачалар, вә аны гади бер тәрҗемәче, гади бер такмакчы итеп күрсәтергә теләп, Сәгыйть Рәмине күкләргә күтәрәләр. Ләкин бу групп үзләренең шул тәнкыйтьләрен язарга ул вакытның шактый бай

милли матбугатында урын да таба алмыйлар. Тукайның дәрәҗәсе, хөрмәте Тукайга каршы чыккан бу агымның язуларына милли матбугатның ишекләрен тәмам каплый. Бу яшьләр рус гәзитләрендә русча итеп тәнкыйтьләр берлә чыгалар. Русча укый, русча белә торган мохиттә генә аз-маз үзләренә иярченнәр таба алалар. Ләкин халкыбызның киң укучы катлавында һичбер эз калдыра алмыйлар. Тукай бу агымнарга каршы нә моназарә берлә чыга, нә дә аңарга көндәш булып чыгарырга теләгән Дәрдемәнд, хосусән Сәгыйть Рәмигә каршы үзенең мөнәсәбәтен боза. Ул Сәгыйтькә дус кала, Дәрдемәндкә каршы хөрмәтен киметми. Ләкин үзенең тәнкыйтьчеләренә берничә шигырь берлә бик оста җавап бирә. Ул берсендә:

Куркмый яңгырдан, әгәр булса табигый, чын чәчәк,
Чөнки ул яхшы белә: яңгыр аны яхшыртачак.

Ошбуның күк, куркыталмый чын талантны интикад,
Нык үзенә игътимады һәм сүзенә — игътикад.

Тик китә кайчакта кәефең, хакимең булса ишәк,
Бер татарга ят, мәхәббәтсез күсәк һәм килмешәк! —

*(«Интикадка мөтәгалликъ»)*

ди.

Моның берлә бу тәнкыйтьләрнең мәгънәсен безнең татар тормышында ят булган килмешәк фикерләр берлә кылынганын укучыга белдереп, үзенең элекке алган юлында дәвам итә. Галимҗан Ибраһимовның тәнкыйтьләренә каршы ул тагы катгыйрак итеп, тагы кабарак шигырьләр кулланып җавап бирә, үзенең «Мөнтәкыйдкә» дигән шигырендә:

Җил тегермәнен күрә дә: «Аһ, суы юк!» — дип куя,
Су тегермәнен күрә дә: «Пар, буы юк!» — дип куя.

Ул тота ат койрыгын да: «Бу — озын сач!» — дип куя,
«Тик нигә башта түгел, тәнкыйтькә мохтаҗ!» — дип куя.

Ул күрә куй койрыгын да: «Нинди шешкән!» — дип куя,
«Рус табибка бу татарлар нинди дошман!» — дип куя.

Һәм дә моның берлә ул Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәми кебек шагыйрьләр — бик аз итеп су килә торган инешкә корылган су тегермәннәре — һавада бушлык вакытында аз-маз тартып, шигырь чыгарып торган кеби, илнең өстеннән әле төн яктан, әле көн яктан, әле сулдан, әле уңнан исә торган каты җилгә каршы корылган җил тегермәне дә (Тукай үзе дә) ашлык тартып шигырь чыгарып торадыр. Болар арасында берберсенә каршы көндәшлек юк. Тормышта су тегермәне үз урынында, җил тегермәне үз урынында булган кеби, халык шагыйре үз йирендә, индивидуалист шагыйрь үз йирендәдер. Аның койрыгының урыны артында булып, ялы алдында булса, анда тәнкыйть итәрлек нәрсә юктыр, бу табигый хәлдер, димәкче була. Безнең халыкның милли хайваны булган куйның койрык мае ул шеш түгелдер. Ата-бабаларымыз мең елдан бирле авызын-борынын майландырган, анаң-әбиеңнең мең елдан бирле пәрәмәче, сумсасы, бәлеше, чәкчәге, катламасы, боткасының иң кирәкле матдәсе булган куй маедыр. Аны куллану урысның балык маен белмәгәнлектән килеп чыккан бер хасталык түгелдер. Милли тормышыбызның, милли хуҗалыгыбызның агымыннан килеп чыккан, милли ихтыяҗыбызны тутыручы бер нигъмәтебездер. «Мөхәммәдия», «Бакырган»нардан өлге алып, шигырь язып, халыкның моңы-көене җырлау рус әдәбиятын, тарихын белмәүдән килгән наданлык түгелдер. Бу көнебезне үткән көннәребезгә баглау, тәрәкъкыятебездәге табигый үсүне саклау гынадыр дигән сүзләрдер. Тукайның бу җавабы ул заманның укучысын да гакыл берлә, гыйлем берлә үлчәп, аңлап түгел, хис берлә сизеп, зур мәкъбүлияткә кичәдер. Вә «Мөнтәкыйдкә» дигән шигырен һәрбер вакытта сөйләтәдер, җырлатадыр. Ләкин бу җаваплар бу көн дә гыйльмән дөрест вә тугрыдыр, вә киләчәктә дә бу җаваплар тугры булып калачаклардыр.

Тукай, шул тәнкыйтьләргә карап, үзе дигәнчә, үзенә ышанычын, үзенең халыкчы шагыйрь булу игътикадын сындырып, беренче групп шагыйрьләр мәсләгенә күчәргә теләсә, күчә алыр идеме? Ул Сәгыйть Рәми кеби бер «Мин» шигырен тугдыра алыр идеме? Югарыда сөйләп киткәнчә, «сәнгать — сәнгать өчендер» мәсләгенә кереп китеп, чын бер шагыйрь булыр өчен беренче шарт — үзенең бөтен тормышы, тән авырлыгыннан ычкынып, күкләрдә оча алу, йолдызлар берлә узыша алырлык рухан тәҗәрред итә ала белүдер. Үз милләтенең үксез тормышына үзенең ятимлеге берлә, җүде берлә багланган Тукай, татарның бу көнгә кадәр бар, бер булып килүеннән беренче рольне уйнаган, меллалыгы, остабикәсе берлә, каны-җаны берлә берләшеп беткән мелла малае Тукай, «Мөхәммәдия»нең мисраглары, «Сөбәтел-гаҗизин», «Бәдәвам», «Бакырган»ның моңнары-зарлары, нәсихәтләре, шатландырулары, өмидләндерүләре, оҗмахлары, тәмуглары берлә рухының кырык катында кырык төрле җепләр берлә чәбәләнеп беткән Тукай, тагы

бүгенге кайнаган Казанның матбугатына, көлке мәҗмугаларына, милли театрларына, милли җырлары кичәләренә, куй майлы пәрәмәчле, пилмәнле дуслар мәҗлесләренә, Печән базарының үзенә, махсус исенә, сасысына баш-аягы берлә чумган Тукай фанна фиш шигъри булып тәҗәрред итә алыр идеме? Аркасына мең төрле җеп берлә тагылган шул вакытның милли йөге, меңәр потлык милли мәсьәләләре аны күкләрдә очып, Зөһрә йолдызның нуры берлә җылытып, бер кызның күзенең тирәнлеген язарга имкян бирә алыр идеме? Юк. Тукай әгәр дә бу юлга чыгарга теләгән булса иде, ул, тутый кошның йөрүенә ияррергә теләгән саескан кеби, үз йөрүен дә онытачак, тутый йөрүен дә кулда итә алмаячак иде. Бәрәкәт боерсын, Тукайны бу ялгыш тәнкыйтьчеләр бу хата юлларга бора алмадылар. Тукай үз юлыннан баручы, милләт кайгысын кайгыртучы халык шагыйре булып калды. Ләкин Тукай үзлеген идракъ итеп йитмәгән, руслашуны тәрәккъый итү дип аңлаган мохитнең зарарлы һөҗүменнән үзен-үзе үзенең игътикады, иманының ныклыгы, халкын сөюенең тирәнлеге берлә коткарып алдырырга өлгерә алмады. Ул икенче бер дошманның һөҗүменә мәгъруз калды. Аның үксез тормышының мирасы булган үпкә хасталыгы аңарга һөҗүмен куәтләтте. Әллә нинди күзгә күренмәгән үпкә хәшәрәте аның тәнен кимерүгә тотынды. Болар аның тәнен кимерү берлә генә калмадылар, аның рухына да һөҗүм иттеләр. «Таза тәндә таза җан» дигәнчә, аның хаста тәне җанын да хасталыкка өстерәде.

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам.

Бөкре түгел, төзәлергә кабер көтмим... —

*(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)*

дип башлаган батыр шагыйрьнең җырларына яңа аһәң керә, аны моңлык кабалый башлый. Бу халәт аның шигъри куәтен зәгыйфьләндермәсә дә, билгакес, аның бу шәхси дәрте, бу кайгысы, аның сазын тагы нечкә кылларында уйнатып, аның шигырьләрен тирәнәйтсә дә, аңарда киләчәк өчен бер курку ята. Аңарда шәхси өмидләр сына башлый. Ул:

Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы, —

*(«Өзелгән өмид»)*

дип зарланып куя. Моның артыннан өмиде азаюы үзенең рухына начар тәэсир итеп, ул тагы:

Теләү бетте хәзер миндә теләк соңра теләкләрне;
Кире суттем хәзер күп эшкә сызганган беләкләрне.

Бетердем шиңдереп төрле гүзәл чәчкәмне барсын да
Явыз тәкъдир, каты тәкъдир, суык тәкъдирем астында.

Өмидсезмен: фәкать актык дәкыйкамны көтәм инде,
Көтәм: кайчан тавыш-тынсыз гына бер көн бетәм инде? —

*(«Теләү бетте»)*

дип егълап җырлый.

Татарның иң зур шагыйре булып өлгергән Тукайның шул күз яшьләре укучы алдында куркынычлы киләчәктән бер хәбәр кеби каршы алынмый. Аның бу шигырьләре шагыйрьнең күңеле нечкәреп киткәннән килгән күңеленең гади бер сыкрануы кеби генә каршы алына. Хаста Тукайны карату, аның эчен кимерүче авыру берлә чынлап тартыш башлау вакыты җиткәнлеген беркем дә күз алдына китерми. Тукай тирәсендә йөргән төрле-төрле дуслары, мөридләре, иптәшләреннән мөрәккәб тугрысы эшсез бер гөруһ та, киң катлау халык та фаҗиганең тирәнлеген аңламый. Ул тагы көннең гайбәте, көннең мәсьәләсе берлә Тукайның ул шигыренең мәгънәсен оныта. Тукай үзе дә, шуңарда туктамаенча, тагы икенче рухта шигырьләр дә яза. Ләкин вакыт, форсат бар чагында Тукайны кымызга җибәрү, Кырымга озату$_0$, бигрәк тә Тукайны сарыпсыз хәяттан тартып алып, аның шәэненә муафыйк исәнлеге-саулыгы өчен кирәкле тормыш корырга, корышырга тәшәббес эше башланмый. Аның шигырьләре инде китапчыларга, наширләргә меңәрле-меңәрле табышлар китерсә дә, Тукайның Уфа, Әстерханга кадәр сәяхәтенә дә акчасы булмый. Казанның үзендә меңәр-меңәр акчалар су кебек акса да, Идел буе сәүдәгәренең көннән-көн баеп, милли эшләргә бик юмартча кылана торган чаклары булса да, Тукайны Кырымга күндерү, чынлап карату кеби эшләр һәммәсе дә акчасызлык сылтавы берлә туктап кала. Табигый, бу эштә Тукайның үзенең кешедән акча алуга һич тә разый булмавы, үзенең нашир эшен юлга куярлык тормыш тәҗрибәсе булмавы да зур роль уйный. Нәтиҗәдә бөтен төрк-татар дөньясы алдында Тукай, җилдә яна торган шәм кеби, көннән-көн эри, көннән-көн аның ки-

ләчәктә яначак уты кими, көннән-көн актык сәгатьләре якынлаша. Ләкин аны саклау тәдбире иң соңгы вакытка кадәр кичектерелә. Тукайның, алдан хәбәр биргән кеби, берничә ел элек җырлаган, көйләгән:

И мөкаддәс моңлы сазым! уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрыламыз, ахрысы, —

*(«Өзелгән өмид»)*

дип алдан хәбәр бирүе дөрескә чыга.

Габдулла Тукай 2 апрель (иске стиль) Казанның бер хастаханәсендә вафат итә. Вә безгә моңарчы бик зур милли байлык булып килгән шигырьләр мәҗмугасын мирас итеп калдыра...

Бу шигырьләрнең кыйммәте, аларның безнең яшьлегебезгә никадәр хезмәт итүе әлегә үлчәнеп җиткәне, тәкъдир ителеп өлгергәне юктыр. Ләкин Тукайның шигырьләрендәге шул садә, матур теле, аның шарлап ага торган су кеби шигырьләренең табигый юлда, милли төстә агуы безнең яшьлегебезнең үз теленә мәхәббәт куюына сәбәп булды. Безнең халкыбызның туган иленнән читтә яшәүче яшьлегенә, үзенең ана телен саклавына бик зур бер милли корал булды. Шуның өчен Тукайның телебезгә хезмәте — күзгә күренгән иң зур мираслардан берседер. Моны иҗекләп бирү телчеләребезнең җентекләүләрен көтеп торганга, бу хакта сүзне озайтмыйбыз. Тукай вафатының 25 еллыгы көнендә үксез иленең бүген кызыл урыслык хакиме сөргән үксез почмагында ятим яткан кабере алдында тезебезне чүгәбез. Исән вакытында кирәге кадәр кадерен белмәгән, кыйммәтен танымаган милләтенең бүгенге хөрмәтен, сөйгесен газиз рухына сонабыз.

**Сәгадәт Чагатай**

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

*Үлүенә 25 ел булу уңае берлә*

Көзге төн, мин йоклый алмыйм, өй түрендә җил җылый...
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

*Г.Тукай*

Илебезнең иң зур шагыйре Тукайның үлүенә 25 ел тулу көннәрен дә, мәгаттәәссеф, чит илләрдә, төрле ихтыяҗлар эчендә үткәрергә мәҗбүрбез. Халкыбызның җаны мөмәссиле урынын тоткан Тукайны чит ил шәһәрләрендә чынлап искә алу бәгъзән безгә бөтенләй имкянсез күренәдер. Тукайны хөрмәт өчен Берлин, Парис (Париж), Токио вә башкалар муафыйк түгел, «ямьле, нурлы Казан» булса иде дигән фикер бигрәк тә күңелебезне рәнҗетә, рухыбызны боектыра. Ләкин моңа карамастан яшь Тукайның моннан 52 ел элек туган булып, безгә бер дәверебезнең рухын ачып калдырган мирасы мөһаҗирлек хәятыбызда вә илебездәге гыйфрит көйләрендә никадәр зур бер байлык булуын игътираф итмәенчә кичә алмыйбыз. Хәзерге дәверебез Тукайсыз булса, ничек булыр иде икән дигән курку сөале генә дә безне шул бөек мәгънәви байлыктан аера кеби була. Тукай бүген яшебезне, картыбызны үзебездән меңнәрчә чакрым ераклыкта булган илебез берлә шундый оста баглап тора ки, без аңардан да куәтле бер милли багны мөһаҗирлектә күрсәтә алмыйбыз. Илдән читтә торып үскән яшьләр Тукай аркылы илне таныйлар. Мәктәпләр ялгыз Тукай берлә генә дә үзләренең чын мәгънәсендә «милли» мәктәп кушаматларын ташый алалар. Җәмгыять хәятыбызда, кичәләребездә Тукайның йөрәккә кереп утырган берничә шигыре янә дә «милли» аң вә рух бирү өчен җитәдер.

Тукайдан бик күп мәртәбәләр югарыда торган галимнәребез Шиһабеддин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэддин Фәхреддин вә башкалар табигый шәраитләре эчендәге ил вә халык арасында үзләренең югары мәгънәвиятләре берлә Тукайны күләгәдә калдырырлык бөекләребез булса да, хәзерге таланган вә изелгән илебездә вә бүгенге мең бер ихтыяҗ эчендәге дөньяның төрле тарафына таралган мөһаҗир хәятыбызда үзләренең урыннарын Тукайга бирергә мәҗбүрләр. Мәрҗани вә Насыйрины мәгънәви куәт итеп җәмгыять хәятында яшәтә алу өчен куәтле матбугат вә куәтле җәмгыятьләр кирәк булса, Ризаэддин Фәхреддинне яшәтү вә ул уртага аткан мәсьәләләрне тудыру өчен зур мәхәлләләр кирәк янә дә үзенең мөнәүвәрләре кирәк... Шуның өчен дә без аларны «бөек илебезнең бөек мәгънәвияте» арасына һәркемгә аның эченә керү гайре мөмкин сәхифәсенә кертеп, Тукаебызның «Туган тел»ен әҗнәби илләрдә туган балаларның ямьсез тәләффыз берлә көйләвеннән ләззәт алабыз, мәктәпләребезне, өебезне, кичә вә җәмгыятьләребезне Тукай, Тукай, Тукай берлә тутырабыз.

Тукайны безгә шулкадәр нык баглый торган куәт Тукайның милли вөҗданында дип беләбез. Бу милли вөҗдан Тукайда шулкадәр саф, шулкадәр тирән ки, аның тәэсиренә бирелмәү мөмкин түгел. 3 җилдлек

кечкенә генә күләмдәге Тукай мәҗмугасы берсе артыннан берсе беренче шикелле тезелгән, самимият вә милли вөҗдан көзгесе булган шигырьләре берлә һәрбер укучыга бер яңа нәрсә бирү берлә бергә, бербөтенлек вә бер культур бирәдер. Гомумән, бөек шагыйрь вә әдипнең вазифасы укучысын үгрәтү, аңын күтәрү, хатасын күрсәтү, күңелен нечкәртү, мәгънәвиятен җилкендерү булса, Тукай да шул сыйфатларны бөтенесен үзенең укучысында уята. Бәгъзән, ул вазифасы өчен, үзенең саф вөҗданын керсез рәвештә күрсәтүдән генә ләззәт алганга, әдәбият чәрчәвәсенә керми торган шигырь үлчәве ялгышларына да исе китмичә, шигырь яза вә бөтен тышкы шәкелләрдән ваз кичә. Тукайның шигырьләре арасында бозык үлчәү берлә язылган шигырьләр дә күп. Ләкин Тукайның бөтен шигырьләрен укыган кеше өчен моның әһәмияте бик аз. Ул үзе дә, бер дә тәкәллефләнмәенчә:

Уңга, сулга аумыйм, һәнүз алга барам,
Юлда манигъ күрсәм, тибәм дә аударам, —

*(«Бер татар шагыйренең сүзләре»)*

ди.

Тукай тәкәллефсез, самими, саф, динле, мәгърур, бозыклыктан качучы әхлак сахибе, җәмәгатьче шагыйребездер вә безнең халкыбызның намусын, вөҗданын үзенең күңеленең көзгесе булган шигырьләре берлә тәмсил итүчедер. Шуның өчен дә Тукайны «милли шагыйрь» диябез, шуның өчен дә аны укыган саен укыйсыбыз килә, шуның өчен дә аны укыган саен, үзебезне күтәрелгән вә бер баскыч югарыга менгән шикелле хис итәбез. Тукай үз халкының милли вөҗданын ташучы булырга тәмамән икътидарлы булуын күп хисап шигырьләрендә беләбез:

Телим булырга мин инсане гали,
Тели күңлем тәгали биттәвали.

*(«Үз-үземә»)*

Милли вөҗданыбызның мөмәссиле₀ шагыйрь, «инсане гали» булырга теләве берлә, безне дә «инсане гали»леккә омтылырга чакыра. Ул үзе тумыштан «инсане гали» булып туган, ләкин халкыбызның бәхетсезлеге, тарихыбызның караңгылыгы, илебезнең шул иң пакь, иң ару күңелле углына бер яхшы мохит биреп, үзенең кабилиятенә лаек рәвештә инкишаф итәргә имкян бирмәгән. Мәңге яшәячәк булган «Өзелгән өмид», «Туган тел», «Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә», «Шүрәле», «Су анасы» вә бик күп әхлакый шигырьләр янында Тукай фөрьяд берлә «Милләтчеләр», «Чын вә ялган», «Бәгъзе зыялыларымыз», «Күрсәтә», «Яшьләр»не ачы тавыш берлә кычкыра. «Дөньяда торыйммы?» дип киңәшләшкән дустыма»да бу фөрьяд аның күңеленнән бөтен нәфрәте берлә чыга:

Хаклык астка кумелгән шул, өсттә түгел,
Шуның өчен астка табан тарта күңел;
Хаклык берлән мәхшәргәчә бергә булыр өчен,
Син дә, тиз бул, тиз бул, йиргә кумел! —

дигән.

Тукай «Чын вә Ялган»да:

Көчле кулы берлә Ялган Чынны бер суккан, ди дә,
Чын батып киткән, ди, чыкмаска җиһанга мәңгегә! —

ди.

Хаклык сөюче, вөҗдан берлә генә яшәргә ашкынучы, арыган вә авыру Тукай «Дошманнар» шигырендә дөньядан туюын вә үзенең тар мохитендә вә шундагы вак кешеләр дөньясы эчендә торырга куәте юклыгын мәгърур, матур сүзләр берлә:

Зур җаным сөйми җиһанны, чөнки бар дөнья фәна,
Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля, —

ди.

Шул ук елда (1912) «Ваксынмыйм» шигырендә янә үзенең «инсане гали» икәнлеге шөгурында халкыбыз аңа бирә алган рухсыз, эч пошыргыч, тар мохиттән өзелеп, үләр алдындагы теләкләрен әйтә:

Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга мәңгегә,
Мәңгелеккә — мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!
Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;
Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим.

Мәңгелек рухлы, мәңге нурлы вә яшь булырга дөнья аңа ишек ачмагач, ул «үкенеч» берлә янә «инсане гали» фәүкыльгадә бер саф кеше булуын җырлый: «Ак кирәк, дип, пакь кирәк, дип, күпме күз яшь түкмәдем!» — дигәч, үзенең хаталары өчен укучыларыннан гафу сораган кеби: «Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем», — ди (1911). Җир йөзендәге керлектән җирәнгән саф шагыйрь 1912 елда янә «Тәләһһеф»е берлә үзенең пычрак вә ялганнарны яратмавын күрсәтүдән туктамый:

Керләнә өст-өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк;
Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә — мунча, җанга — юк?!

«Кыйтга» берлә шагыйрьнең саф, тәмиз рухы (1 март, 1913) үзенең никадәр арулыкны, вөҗданны сөюендәй соңгы кат ишарә бирә:

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч,— шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.

Тукайның дөньяны пакьләргә теләве, «ак вә пакь»не эзләве — барысы да халкы өчен. «Инсане гали» Тукай тәсадеф, әллә керләнүдән куркуы нәфрәт дәрәҗәсендә зур булгангамы, — беренче шигыре булган «Мужик йокысы»ның соң мисрагларында ук:

Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә,
Бу юлда һәртөрле хурлыкка, зурлыкларга түзмәккә! —

*(«Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр»)*

дип бетерәдер. Бу беренче символ кеби күренгән сүзләрдә Тукай, күз яше түгеп, аклык-пакьлекне халкы өчен эзләнүен сөйли. Милли вөҗдан вә аның әсасе булган пакьлек Тукайда шундый зур сыйфатлардан ки, ул ансыз каләм тота алмаган.

Тукай калдырган иң кыйммәтле парчалар балалар кыйсеме булуы да Тукайның яшьли вөҗдан сафлыгы, бөтен керсезлеге шул пакь күңелләргә генә сөйли ала торган сүзләр берлә булуыннан вә моның эчендә генә Тукай үзен саф вә керсез хис итә алуында, тәмам үзенең бөтен җанын, рухын бирә алуындадыр. Болар Тукайның иң якын дуслары, алар аның төсле керсез, сафлар, алар аның төсле җаннан, чын күңелдән «Туган тел»не сөйлиләр, аның төсле җаннан дога кыла беләләр, аның төсле саф сөя беләләр. Тукай шул балача сафлыгы берлә үзенең халкын сөя. Гасырлардан бирле дәвам итеп килә торган әсирлек чылбырының авырлыгы Тукай шигырьләренең бик күбесендә хис ителә, шулар эченнән еракта калмыйлар. «Көзге җилләр» — бүген дә шагыйранә тасвир гына түгел, җан ачысы берлә һәр елны халкыбызда яшәп торган фаҗигаләрнең иң зурысы. Илебезнең большевик дәверендә «бик зур уңышларга ирешүен» белдереп торган большевик гәзитләре еш-еш кына дәшми-тынмый Тукайның ачлык хакындагы ачы фөрьядын — «Көзге җилләр»не басалар. Һәр сүзе йөрәккә ук берлә аткан шикелле әрнүле сүзләр вә:

Ач үлемнең куркусыннан ил җылый...
...Җан алырга кызганудан анда Газраил җылый... —

мисраглары бүгенге көн өчен, хәзерге дәвер өчен Тукай тарафыннан бер иляһи куәт берлә язылып калдырылган Коръән аятенә охшый... Безгә ят Пушкин, Горький вә башка урыс-улак әдәбият вә нәшрият битләрен тутырып торганда, янә бер кечкенә Тукай мисрагы теге урыс чүпләрен үзенең милли вөҗданы берлә фәрештә канаты шикелле каплап куярга кодрәте бар. Бүгенге дәверне хакыйкатән дә Тукайсыз төшенү имкянсез, Тукайсыз булу халкыбыз өчен тагын да зур бәхетсезлек булыр иде дип уйлаудан тартына алмыйбыз.

Ни күңелле, ни яхшы ки, — Тукаебыз бар! Халык өчен нә бөек юаныч ки, моннан 30–40 ел элек пәйгамбәрләр генә күргән авырлыклар, сәфаләт вә зәхмәтләрне күреп, бала табигатеннән чыгып бетмәгән яшь фидаи егет халыкның мәгънәви хакын таләп итеп, аның вөҗданын уятып калдырган, балаларына туу берлә, ата-ана дине берлә үк миллият рухын бирә торган милли догалар язып калдырган. Үзе турында Тукай:

Минем гомрем караңгы төн. Кояшым һәм аем тугмас;
Шуңар да шөкер итәм мин: бу төнем йолдызлы, йолдызлы.

Озаттылар миңа кул төрле мәлгунь көч, кара көчләр,
Теләп сүндермәгә күңлемдә янган изге йолдызны.

Күзеннән канлы яшь түксен иде барча шәятыйным,
Җиһанда калдырып китсәм икән, йа Рабб, гүзәл эзне! —

*(«Күңел йолдызы»)*

ди.

Мөтәвазигъ Тукай шул «гүзәл эзне» үзенең халкы арасында ничек зур, ничек тәэсирле калдырды. Үзе тасвир итә алмаган кадәр изге йолдызлар мирас итте. Керләнүдән бер бала шикелле курыккан шагыйрь: «Ак кирәк, дип, пакь кирәк, дип, күпме күз яшь түкмәдем!» — дисә, үлүеннән 25 ел узганча аның сөйгән халкы да аның гали рухын, керсезлеген белде, аңлады. Аның изге йолдызы — төнебезнең йолдызы, аның вөҗданы бөтенебезнең омтыла торган вөҗданы булды.

«Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим...» — диюче Тукай бүген милли вөҗданыбызның кояшы булды. Аның яшәгән хәяты, үзе әйткәнчә, кояшсыз вә айсыз булса да, ул үзенең иленә вә халкына иң зур теләкләрдә булынып, аңа үзенең саулыгын вә бөтен эчке барлыгын биреп калдырды. Үзен үлем, бары үлем генә хәстәлек вә хәят җәфасыннан котылдыра кеби: «И үлем! Мин синдә бер хәсрәт вә бер шатлык күрәм», — дип, үлем якынлашуын шатлык берлә көтте...

Бүген Тукайның үлүенә 25 ел булуын хатирәләгәндә, Тукайның шәхси авыр хәятын искә дә алмаенча, ул никадәр зәхмәт чиксә дә, «безнеке» булуы берлә генә ифтихар итәмез. Бүген инде аның хәятын озайта алмаганыбыз шикелле, аның фаҗигале тормышын да тарих сәхифәсе, бәхетсез тарихыбызның канлы ачы сәхифәләре эченә генә кертәбез. Һәм үзе берлә бергә: «Тик мин үлгәчтен караңыз, типмәсеннәр нәгъшемә» дигәне кеби: «Типмәсеннәр аның мөкатдәс мирасына!» — дибез вә хәзер(ге) елыбызда яктылык урынына караңгылык күндереп тора торган «бу кояш сүнсен» дә йиренә Тукай сөйгән халкыбызны яктырта торган икенче кояш чыксын!» — дибез.

**Хөсәен Габдүш**

## ТУКАЙСЫЗ, ТУКАЙ БЕРЛӘ

Тукайсыз 25 ел гомеребез узып китте. «Тукайсыз» дидек, әлбәттә, шагыйрьнең арабыздан җисмән аерылып китүенә чирек гасырлык вакыт үтүне аңлау тиештер. Юкса мәгънәви Тукай, аның калдырган сүзләре, «җандай күрелгән искеләрнең җырлары» кеби, бер генә көн дә исебездән чыгып тормады. Әдәби тәнкыйтьчеләребездән Җамал Вәлидинең уйлаганы дөрес килеп тора: «Телебезнең кадере күтәрелгән саен, Тукай күтәрелә бара, милли аңыбыз, милли хисебез арткан саен, Тукай аңлана бара».

Безләр милли аңыбызның әфкярләрен киңәйтү, милли тойгыларыбызны үстерү эшен кунакчыл чит илләр туфрагында алып бару мәҗбүриятендә калдык. «Казан төркләре» китабының кереш сүзләре арасында укыйбыз: «Милли истикъляль угырында чалышан милләтнең бер «милли мисакы» булынмак лязим булдыгы кеби, өлкәсе вә кәндесенең тарих вә ганганәтә мөстәнәд тугры исемнәре дә булмак икътиза итәр, ки ул мәгънәдәр исемнәр ил вә йортта мөккаддәс «уран» — девиз булуын белсеннәр.

Мөһаҗәрәттә һичбер нәрсәсез ярлылыкка төшеп калганда, без үзебезнең милли төсебезне саклап калу өчен әнә шул мөкаддәс «уран»лардан илһамланып, көч җыеп тормактабыз. Күчмәлектә, илебездән читтә яшәгәндә, милли бәхетебезнең чишмәсе рух вә мәгънәвият аланыннан чыга дип аңлаганбыз. Тукай — тоткан юлыбызда кадерле бер маяктыр. Үзебез өчен кадере зур булганы кеби әҗнәбиләрдән берсенең гыйбарәсе буенча, Тукай «экспорт» өчен үлчәүле бер исемдер.

Украиналы бер җәмәгатьче Тарас Шевченконы шагыйрь-уятучы итеп таныганы хәлдә, дөньяга мәгълүм халыкларның милли даһилары һичберсе Шевченко украиналылар вә Украина өчен эшләгән эшне эшли алмады, ди. Дөрес, ди ул, Гомер, Вергилий, Сервантес әсәрләре дөнья мәдәнияте өчен Шевченконыкына караганда әһәмиятлерәк урын тоталардыр. Әмма һичбер язучы халыкның күңеленә вә аңы ачылуга «Кобзар» мөхәррире биргән тәэсирне бирә алмады.

Безнең Тукай, башка милләтләрнең шагыйрьләре берлә чагыштырганда, кайсына күбрәк охшагандыр, алар катарында нинди урынны ала торгандыр, бу бер караганда кызыклы гына бер эш булса да, безнең өчен иң кирәкле булганы — шагыйрьнең үз халкыбызның күтәрелешендә уйнаган ролен ачыграк сызып куюү, үсеп килүче буыныбызга шуны яхшырак аңлатудыр. Украинаны уятучы хакында язылган мактаулы җөмләләрне исә без «сәнгать — сәнгать өчен» дип язмаган шагыйрьләрнең үз халыкларының тормышында бөек тәэсирле өндәр булып китүләренә бер-бер үрнәк булсын өчен өземтә итеп алдык.

Тукай да тик бер матурлык өчен генә язмады. Киресенчә булганда, ул да, «Кораб»лы Дәрдемәнд, «Таң вакыты» һәм «Перчатка»лы Сәгыйть Рәми кеби, бик азлар өчен генә мәгълүм вә аңланган бер шагыйрь булып кына калыр иде. Язмыш Тукайны, гомумән, олуг кешеләрнең җиңел укылмый торган тәрҗемәи хәлләрендә сирәк очратырлык ятимлек вә үгилек күперләреннән уздырып, аны алмашыну көннәребезнең төрле чакларына таныктк итте. Иҗтимагый хәятыбызны дулкынлаткан хәдисәләрнең күбесе аның шигырьләренә йогынты бирә барды. Үзенең дә шул хәдисәләрнең тәэсиренә бирелеп киткәләгән вакытлары булды. Дөресрәге, шагыйрь үзенең эзләнү дәверен кичерде. Шунлыктан җәмгыятебезнең төрле мәсләкләргә таратып, тармакларының һәркайсына Тукайны үзенеке итеп, аны үзенә таба «тарткалауга» мөмкинлек бар. Бу хәл күрсәтә ки, Тукайның яратыш гәргисе бик киңдер. Менә шул киң гәргисе өстендә шагыйребезнең тылсымлы каләме берлә чигелгән бизәкләрнең иң матуры, безнең зәвыгыбызга иң туры килеп торганы, шөбһәсез, милли төсләр берлә чигелгәнедер. Милләтебез өчен сөекле булган шигырьләрен халык йөрәгеннән «кабызып» алгандыр:

Әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

*(«Мәхәббәт»)*

* * *

Тукай тугрысында сүз йөрткәндә, аның бала күңелендә тоткан урынын да сызып китмичә булмый. Төрк-татар баласы әлифбадан соң, иң матур бер әйбер итеп, үзенә мәктәпкә керүдән элек таныш булган Тукай шигырен укый. Шуның берлә әдәбият кичәләрендә, халык каршына басып, укуда осталыгы вә кыюлыгына имтихан тота. Беренче алкышларны ишетеп, үзенең бу эше яхшы бер эш икәнлекне вә моның да Тукай шигыре аркылы килеп чыкканлыгын аңлап ала. Бу милли тәрбиябез эшендә Тукай кичәләре аркылы салып килә торган иҗаби бер факттыр. Мәктәпләребездә ана телебезне өйрәтүдә Тукай шигырьләренең алган урыны зурдыр.

Кечкенәдән башлап зурыбызга чаклы Тукай телен йөрәктән яратабыз. «Дөньяда никадәре кешеләр бар, — ди Җамал Вәлиди. — Татар телен фәкать Тукай шигыре хөрмәтенә сөйләр». Шул ук тәнкыйтьчебезнең сүзләре: «Исмәгыйль бәк җәнапларының бөтен төрк галәменә салдыгыны «тел! тел! тел!» авазы безнең кеби ачка үләргә торган кешенең «икмәк! икмәк! икмәк!» дигән авазы илә бәрабәрдер. Исмәгыйль бәк, безнең рухани ачлыгыбызны кәшеф итеп, телсез яшәргә мөмкин булмаячакны аңлатты. Бу аның зур һәм онытылмаслык хезмәте. Ләкин ул безгә рухыбызга бик муафыйк булып җитмәгән бер гыда ясап тәкъдим итте. Без аннан вакытында файдаландык. Ләкин соңыннан аның безгә кыймммәткә төшкәнлеген, безнең өчен ләззәтле вә туклыклы булмаганын сиздек. Идел буенда шундый бер мөсагадә һава вә мөнбит туфрак булып торганда, ашлыкны Кырымнан китерергә авырсындык».

Җ.Вәлиди «Тукай тугрысында матбугат» исемле мәкаләсендә: «Тукай үзен бик тиз танытты, — ди. — Тукайга иң элек дикъкать итүче вә аның шигырьләрен җөпләп каршы алучы «Вакыт» газетасы булса кирәк. Шуның артыннан ул «Тәрҗеман»да да алкышланган иде. «Тәрҗеман» соңга таба Тукайга ноктаи назарын үзгәртте. Тукайның мәхәлли шивә берлә язуын яратмыйча язды (ялгышмасам, 1909 елда күзге саннарының берсендә иде)*. Хәлбуки бездә Тукайның татарчалашуы бик табигый вә матлуб бер тәкямел саналган иде...» Җ.Вәлидинең Тукайны татар телен авыр көннәрдә коткаручыларның беренчеләреннән итеп югары күтәрү; үзенең дә шагыйрьнең элек госманлы тәэсирендә язган шигырьләренә караганда, саф үзебезчә язылган «Шүрәле» кеби әсәрләрен яратуыбызны вә шуның берлә бергә Тукайның мондый телдә язуына «Тәрҗеман»ның сәлби яктан$_0$ каравын исәпкә алганда, төреклек мәфкүрәсенең өндәрләреннән Гаспралы Исмәгыйль бәкнең безнең өчен кыйммәтле булган «телдә, фикердә, эштә берлек» шигаре бу тарихи шигарьнең беренче өземтәсе алдында нинди бер вазгыятьтә калабыз?

Әһле булмаганлыгыбыздан мәсьәләгә тирән кереп китә алмыйбыз. Ләкин шул ук вакытта, Тукай хакында фикер йөрткәндә, менә шушы ноктага килеп кагылдыңмы, тел очында гына торган сүзеңне әйтеп китәсе килә. Аны бер «бөтен» итеп калдырасы килми.

Мөхтәрәм Җәгъфәр Сәед Әхмәт бәк каләме берлә язылган «Гаспралы Исмәгыйль бәк» дигән кыйммәтле китапта «Төркиядә садәлек җәрәяны» һәм «Большевиклар дәверендә тел мәсьәләсе» исемле ике мәкалә бар. Бу мәсьәлә хакында мәгълүматын арттырырга теләүче өчен аларның күздән кичерелгән булулары матлубтыр. Мөәллифнең Җамал Вәлидинең тел мәсьәләсенә карашын җентекләгән урыннары бик әһәмиятледер.

Инде милли әдәбиятыбыз үзебездән вә үзебездән булмаган күптөрле сәбәпләр берлә бик татарчалашып китте, вә моны үзебез дә тәкямелдән санап торабыз икән, ачык әйтергә тиешбез ки, моның берлә без Гаспралы бабабызның сүзен «тыңламаган» булып күренәбез вә аның күтәргән шигаре алдында «уңайсызланып» тормактабыз. Шуның берлә бергә үзебезне җуандырырлык хәлләр дә бардыр ки, уртак бер әдәби тел ясату өчен бөтен төрк-татар дөньясының мәгариф хадимләреннән мөрәккәб даими мәгариф әнҗеманы вә матбугат бюросы корылганга тарих ихтыяр иткәнгә чаклы саф «әткәм-әнкәмнең» телендә язылып торучы милли әдәбият вә матбугатыбыз «фикердә, эштә берлек» әсасларына каршы килмәдә вә киләчәктә дә, киресенчә, шагыйрь вә язучыларыбызның шул фикерләрне җәмгыятебез эчендә киңрәк таратырга хезмәт итеп яткан көннәредер.

Бөек Исмәгыйль бәк әйтә: «...шагыйрьләр иң гүзәл сөйләүчеләрдер, иң тирән хис итүчеләрдер, иң кыйммәтле күз яшьләре түгүчеләрдер. Иманлы сөйлиләр, хисләре нидер, күз яшьләре ни өчендер? Шагыйрьнең бер зурысы гына түгел, урта кул хәллесе дә сирәк була, ул бер милли байлыктыр ки, истигъдады вә сәмави чаткылары юк җирләргә чәчелеп, таралуга һичбер төрле ризалык бирелмәсен»*.

Тукай үз шигырьләрен зөлеф берлә сөнбелләргә генә багышлап язмады вә яза да алмаячак иде, чөнки, Җәгъфәр Сәед Әхмәт бәкнең Гаяз бәк әдәби юбилеесына багышлап язган мәкаләсендә әйтелеп үткәнчә, Шималь төркләре әдәбиятының Истанбулдагы кеби «сәнгать — сәнгать өчен» модасын бик танымамыш булмасында иҗтимагый, сәяси һәрни бик күп сәбәпләр бардыр. Боларның иң алдында халыкка таянмак, халыкны хәрәкәткә китермәк әндишәсе тора»*.

* * *

Әйдә халыкка хезмәткә:
Хезмәт эчендә йөзмәккә.
Бу юлда һәртөрле хурлыкка,
Зурлыкларга түзмәккә, —

*(«Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр»)*

дип, шагыйрь тирән хисен әйтте.

Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен, —

*(«Милли моңнар»)*

дип, кыйммәтле күз яшьләрен түкте.

— Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән, —
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.

Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр, һәм мин җылый башлыйм:
Яңакларны мөкатдәс күз яшемлә энҗели башлыйм.

*(«Тәәссер»)*

Табигать аркылы тереклекнең уртак үтмешен күрде:

Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби,
Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.
Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре,
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен сауләтләре.
Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе.

*(«Шүрәле»)*

**Рокыя Мөхәммәдиш**

## ИЛСЕЗЛЕКТӘ ТУКАЙ БЕЛӘН

Шадыман ул мәркадеңдә ! Без онытмыйбыз сине!
Белмәсәк вакытыңда кадрең, инде котлыйбыз сине.

Бу елның 15 апрелендә илебезнең онытылмас шагыйре Габдулла Тукайның вафатына егерме биш ел тулды. Бу мөнәсәбәт белән Тукай бик сөйгән, ачы тәкъдире өчен бик көенгән Идел-Урал төрклеге сөекле шагыйре хакында сүз сөйләде, фикер йөртте, хәтта матбугатына да шагыйрьгә багышлап язмалар белән чыкты.

Бу чирек гасырлык истәлек белән Идел буе үзенең күптән югалткан иркенә кавыша алган булса иде, шагыйрьне тагы да зуррак итеп хөрмәтләр, тулырак итеп мәрхүм шагыйрьнең кыйммәтле мирасын барлар иде. Ләкин Тукай дөньядан аерылганнан соң кичкән дәвер Идел-Урал төрклеген тыныч яр якасына китереп туктатмады, Идел буе да, аның бүгенге көнне дөньяның төрле почмакларына сибелгән балалары да әле һаман да сәяси дәвер, тартыш дәвере кичерәләр. Шуның өчен илсезлектә Тукайны искә алу, Тукай иҗатының әдәби кыйммәтеннән битәр, аны иленең кол булуыннан күңеле сыкранган бер милләтче, бер кортылыш көрәшчесе сыйфатында күрергә, аның әсәрләрендә шул нокталарны эзләргә вә шулардагы яшерен мәгънәне аңларга чакыра.

Тукай Идел-Уралның иң хисси, иң моң баласы булуы белән бергә бик хассас күңеленең дулкыннарын кәгазьгә дә бөек бер истигъдад белән төшерә белгән шагыйре булганлыктан, илсезлектә, илебезне өйрәнү омтылышыбызда Тукай шигырьләре безгә бик зур мәнбәгъдер.

Халкына бөтен күңеле белән баглы булып, бөтен яратышын милли барлыгына, үзлегенә генә нигезләгән Тукай, сөйгән халкы хакында фикер йөрткәндә, менә болай дип башлап китә:

«...халык зур ул, көчле ул, дәрдле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул; *ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри.* Ләкин бу хәл вакытлы гына килгән бер авыру кеби гарзый бер хәлдер...»

(«*Халык әдәбияты*»)

Аерым билгеләп киткәнебез бу юлларның фикере Тукайның бик күп шигырьләрендә хаким сөргәнгә, бүгенге барышыбызның тәэсирендә Тукай истәлегендә шагыйрьнең «Мәҗмугаи асаре»н актарабыз. Ул вакытларда хөрлек өчен көрәш бик сакланып, яшеренеп кенә алып барылганга, көрәшнең ингыйкясы Тукайда да шигырь юллары арасында яшеренә. Ләкин тәнкыйтьчебез Җамал Вәлиди әйткәнчә, «Тукай мәгънәне, фикерне бик ачык әйтә, ул сүз астына төрелми, сәнгать артына яшеренми...» Шуның өчен Тукай ши-

гырьләре, мисраглары арасында халкыбызның иреккә омтылуының борылышларын, өмид вә өмидсезлекнең берсен берсе алмаштыруын күрә алабыз. Ул заманның ил тартышындагы караш вә фикерләрен аңлый беләбез. Чөнки халык күңеле — шагыйрь күңеле...

Тукай илнең хөрлеккә йөрешенең иң беренче адымы итеп милли мәдәниятнең тәрәкъкыйсын күрә:

Бармак берлән каткан җирне казып булмый,
Әлифбасыз (алфавитсыз) язып булмый;
Шуның төслүк, мәктәпләрне төзәтмичә,
«Тәрәкъкый!» дип кычкырырга базып булмый.

*(«Ислахчыларга»)*

Яки шунда ук:

Кызганыйкмы безнең ярдәм киткән чакта
Төзәлергә вәйран булган кәгъбәмезгә?! —
дип яза.

Безнең халыкның гасырлар буе ирек өчен көрәшеп килүе, Тукай әйткәнчә, «вәйран булган кәгъбәбезне төзәтү» шуңа киткән ярдәмне кызганмаудан гыйбарәт. Көрәштә өстен чыгуыбызның бөтен нигезе дә шунда яшеренә.

Чар Русиясенең баскынлыгына япон-рус сугышында японнарның җиңеп чыгуларына чик куелганнан соң мәйданга килгән 1905 ел вә аның безнең халыкка биргән өмиде, шул көннәрнең кояшы нурландыра, истигъдады көннән-көн арта барганга, Тукай, халыкның канатлануына, ирек бирелүгә сөенеп:

Без Бишенче елны беркөнне уяндык таң белән,
Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге нам белән,—

(«*Аң*»)

ди.

«Эшкә дәгъвәт итүче» бу «кемдер» — ирек кояшының ерак, ләкин рәхимле нурлары, рус истибдады символы каракошның канаты сынуы иде. Шул уяну нәтиҗәсендә матбугат дөньябызда әллә никадәре җанлылык, эшлеклелек мәйданга килде вә илнең баласы Тукай да, халкының шул барышына горурланып:

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вактын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын, —

*(«Үз-үземә»)*

дип куя.

Вә шул ук рух белән:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.

Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? —
Хаклыбыз уртак Ватанда шактый ук! —

(«*Олугъ юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре*»)

дигән мисраглар белән халкының иреккә, үзенә-үзе хуҗа булырга тулы хокукы барлыгын бик матур итеп әйтеп бирә.

Тукай иленең барышы шатлык, сөенеч, өмид биргән елларда өлкәнең мәркәзе Казанга омтыла. Моң белән тулган күңел атларның чабуы уңаена, алга, киләчәккә оча...

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

*(«Пар ат»)*

* * *

1905 елда чыккан кояш хөр Казан иле күгендә бик кыска гына вакыт яктырды. Рус хөкүмәте каты реакция юлына төште. Бөек милли һәяҗан белән эшкә омтылган зыялы укучы катлавыбыз да куәтле тәзйикъ аркасында бәдбинлек, өмидсезлек хөкем сөрә башлады. Әле күптән түгел генә «татар бит мин» дип горурланган Тукай да:

Тотып милләт ливасын юлга чыктык:
«Бу куллар мәңге, — дип, — җиргә салынмас».

Җыгылдык без икөч чакрым да китми, —
Җегетләр! Бездә көч юк, — ахры, булмас! —

*(«Яшьләр»)*

дип күңелсезләнеп куя вә үзенең сизгер күңеле белән милләтебезнең хата юлларга кереп китүенә күп вакытта үз милли кыйбласын аңлап җитмәве сәбәп булуын аңлап:

Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,
Күз һаман булды эренле, йөз дә саф һәм пакь түгел.
Шул сәбәпле дустны, дошманны дөрест фәркъ итмичә,
Күп саташтырдык рәзил шәйтанны чын инсан белән.

*(«Аң»)*

Туган илебезнең иреге өчен чит мәмләкәтләрдә көрәшүебездә дә «дөресне, дошманны фәрекъ итмичә» газап чигәбез. Бик күп хаталарыбызны төзәтер өчен бик кадерле вакытыбызны, матди, мәгънәви көчебезне әрәмгә сарыф итәбез. Тукай дәверендә дә, бүгенге барышыбызда да безнең халыкның иң зур чире әнә шунда. Бөек Тукайның егерме биш еллык истәлеген күңел теләгән кадәре зур итеп уздыра алмавыбызның, илсезлегебезнең дә ачы сәбәбе әнә шунда. Илсезлектә Тукай белән бер, кортылыш көрәшенең баскычларын күз алдыннан кичергәндә, бу көрәшебезнең уңышсызлыкка очраган вакытларында өмидсезләнсәк тә, бөек халкыбызның бөек углы Габдулла Мөхәммәдгариф углы Тукай чирек гасырлык аерылышу мосафәсендә бер ялкынланып яткан, бер өмидсезләнеп сүнә башлаган моңы белән безгә кыйммәтле васыятен ирештерә.

Чөнки:

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

*(«Татар яшьләре»)*

**Хөсәен Габдүш**

## ТУКАЙ ҺӘМ ЯШЬЛӘР

*(Өзек фикерләр)*

Моннан 25 ел элек төрк-татар иле үзенең бөек угылларыннан берсен югалтып хәсрәт тотты. Халыкның тормышында күңелдән күңелгә хәбәрнең бик тиз йөреп, һичбер төрле димләү вә өндәүсез рухан берләшү бөтенлеге сирәк була. Ул илнең апрель кайгысын халкыбыз йөрәктән бер булып, бербөтен тормыш җанлы милли барлык булып яшәде. Бер халыкның башкалардан аерым бер милләт булучылыгында, аның язмышы өлешләгән шатлык вә кайгысының уртаклыгы зур үлчәүле бер урын тота. Чирек гасыр ул уртак зур югалту кайгысын самимәнә йөрәгендә тойган төрк-татар баласының зиһененә бу уңае белән милли әмәл, милли өлгебезне ясаучы гонсырлар, катнаш бер аң үзенең орлыгын салды. Бөек ятимнең арабыздан бик яшьли китүе милли кайгыбызны үкенечле көчәйтте, арттырды. Истигъдад чәчәкләре игелекле ату тулылыгы чагында зәгыйфь тән сәламәтлеге какшап беткән иде инде. Идел-Урал иленең зур шагыйре Габдулла Мөхәммәдгариф углы Тукай җисмән арабызда яшәүдән туктады... Чик тыш аяулы бер үлем иде...

Булды иленә йолдыз,
Тик сүнде тиз;
Яралмаган икән күбрәккә!

* * *

Бу көн шагыйрьнең 25 еллык истәлеге уңаенда «Тукай һәм яшьләр» дигән бер мәүзугъны алу белән, аянычка каршы, аның яралы ягына тукталу ирексезлегендә каласың. Башлангыч мәктәпләребездә генә дини-милли тәрбия алып чыккан төрк-татар баласы, аннан чыккач барлы-юклы белемен оныта барганы кебек, мәктәп көрсиләрендә утырганда күңеленә алган Тукай әсәрләрен дә исеннән чыгара барып, аларның кайберләренең генә исемнәрен хәтерендә тотар-тотмас бер хәлдә кала. Күпчелеккә карата бу хәл, тәәссефкә каршы, шулайдыр.

Милли мәктәп диварлары эчендә үткәрелгән 3–4 ел агымында шагыйрьнең «Мәҗмугаи асаре» белән якыннан танышып өлгерү хакында сүз булырга да урыны юк. Укучы әле анда шагыйрьнең сарыф-нәху китапларында үрнәк буларак китерелгән юлларын җентекләр дәрәҗәсенә дә килеп җитә алмый. Яшьләр түгәрәкләре әгъзалары арасында, сәхнәдә күрсәтелүче театр әсәрләребезне уйнаучыларга әйтеп тору вази-

фасын алудан «мин укый белмим» дигән сүзләр белән баш тарткалаулар күз алдыбыздагы хәлләрдән икән. Кая ул син Тукай шигырьләрен яхшы төшенеп укый алу да, алардан ләззәтләнү һәм рухлану!

Күренеш шул төстә булганда, яшьләребезгә милли шигырь, әдәбият вә матбугатыбыз җан азыгы булып төшә алырмы?

Дөрес, 25 ел элек бездән Тукай җисмән аерылып киткәннән бирле, без мәгънәви Тукай белән һәрвакыт берлектәбез. Хәтта урыны-урыны килгән саен, шул вакыт эчендә Тукайны аңлавыбыз күтәрелә бара, аны кирәксенүебез дә артып тора дигән кебек фикерләрне дә әйткәләп куябыз.

Мондый нисби рәвештә генә булган иҗаби хәлне сызып китәр җае бар икән, аны да мөһаҗәрәт бусагасын атлап чыкканда, милли әдәбиятыбыздан азмы-күпме хәбәре булганнар вә шуларга якын торганнарыбыз хисабына салып куярга кирәк, чагыштырмалы гына булган бу мәгънә чыгышлы хәл, ягъни Тукайны онытмаучылык, аның яратышын яхшырак аңлый баручылары белән мөһаҗәрәтебезнең яшьләреннән өлкәнрәк булган катлавыбыз милләтчелек орлыкларын вакытында үз күңеленә тирәнрәк сеңдереп калуына бурычлыдыр.

Яшьләребезне милли әдәбиятыбызны яраттыру вә аңа якынрак китерү юлында торучы киртәләрне ничек соң сындырып ташларга?

Чит илләрдә төрле милләт фәрдләре белән аралашып, төрле агымнар йогынтысына бирелеп яшәү мәҗбүриятендә калганда, ана телебезнең пакьлеген [...]* вә үз туфрагында көн иткән вакытта гына караганда бик читенлек белән үтәлеп баручы уртак бер милли бурычтыр.

«Милли байрак»ны ник укымыйсыз?» — дип яшьләребезнең берсеннән сораган вакытымда: «Укып аңлый алмыйм», — дигән җавапны алдым.

Җавап бирүче әле милли матбугатыбызда да язгалап куючы бер яшь иде. Аннан шундый сүзләрне ишетеп торганда, милли мәктәп көрсиләреннән аерылгач та, кулына каләм тотып, ата-анасы кушканда «хәтем мәҗлесенә» чакырып бер-ике юллык дәгъвәтнамә дә язмый торган башка бер яшебез инде ни дип җавап бирәчәк.

Менә шунлыктан да күп «ана»ларның бу тугрыда кайгыга калып торулары, «аһ» итүләре...

Дөрес, милли матбугатыбызда очрый торган «сәфаләте изафә», «могаһәдә», «рәсме гәчид», «һәзым итү» кебек вә Тукай шигырьләрендәге гарәби һәм фарсы сүз вә гыйбарәләрне бер укуда гына аңлап алу мөһаҗәрәттә үсүче яшьләребез өчен генә түгел, электән үк гыйльме кани булганнарның да күбесе өчен читендер. Монысы гына әле әллә нәрсә түгел, туган телебезгә күңел бирүне түбәннән җимерә торган сәлиси бер хәл бар, ул да, аянычка каршы, ата-аналарыбызның кайберләре арасында «татарча укып ни чыга?» дигән бер бозык карашның урын алып, шуның балалар, яшьләр дөньясында куертылып торуыдыр. Әҗнәби телләрне өстән-өстән генә түгел, бик яхшылап өйрәнүнең кирәклеге хакында ике фикернең булу ихтималы юктыр. Аларны өйрәтүдән «икмәк ашау» мөмкинлеге күз алдыбызда. Ләкин шуның белән безгә үз телеңне оныту, онытуны кимчелектән санамау, йомшак әйткәндә, бик түбәнлектер.

Ана телеңне, матди файда күзәтеп, «икмәк ашар» өчен түгел, уртак милли мәнфәгатебез өчен кирәк булганлыктан өйрән; кулыңнан бер эш килмәгән чагында да, туган телеңдә дөрест вә матур итеп сөйлияза белүнең үзе генә милли юлыбызда бер хезмәт булыр.

Әҗнәби телләрне өйрәнүдә, хәтта иероглифны истә тота алуда уңышлык күрсәтеп тә, үз телеңдә укырга һәм язарга «оныттым» дияргә уйламаган бер яшь өчен, ул ничек кенә мәшгуль булмасын, көненә ике бит күчереп язу һәм ярты гына сәгать булса да ана телендә кычкырып уку юлы белән генә дә йөзен акларга мөмкинлек бар. Тукай көннәрендә безне уйга калдырып торучы хәлләрдән берсе әнә шулдыр.

Якынрак Тукай белән туган телгә! Укы Тукай шигырьләрен: ана телеңә мәхәббәт уяныр! Туган телеңнең матурлыгын табарсың! Тукай белән милли шагыйрь һәм әдипләрне өйрән!

Авызыңа шулар догасын ал!

Сакауланган исәң!*

* * *

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ЕГЕРМЕ БИШ ЕЛЛЫГЫ

Бу 1938 елның 15 апрелендә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына егерме биш ел тулды.

Ерак Шәрык дини, милли мәркәзенең юлбашчылыгында, Ерак Шәрыкнең төрле илләрендә яшәүче халкыбыз тарафыннан бу көн махсус «истәлек мәрасимнәре», Тукай кичәләре белән сызылып узылды. Бөтен Идел-Урал мөһаҗәрәте елдагы Тукай хатирәсе көннәреннән тирәнрәк бер хәзерлек белән иленең бөек шагыйренең истәлеген каршылады. Милли-мәдәни учакларыннан, тарихи барлыгының җанлы шаһитларыннан аерым булып яшәвенә карамастан, кулыннан килгәнчә милли әдәбияты күгенең Зөһрә йолдызы

— Тукайны яшьлегенең күзе алдыннан уздырды. Аның шигырьләрен тәкрарлап, бөек шагыйрьнең кыйммәтле әсәрләрендә яшәрткән телебезнең матур музыкасын илдән еракта тагы бер мәртәбә яңгыратты.

Мөһаҗәрәт, бигрәк тә үзенең дини, милли барлыгын дошман һөҗүменнән саклар өчен, чит илләрне ихтыяр иткән милләтнең бер өлеше, үзенең хариҗдагы милли иҗтимагый хәятын милләтнең барлыгына, аның ганганәви хатирәләренә генә нигезләп алып киләдер. Мөһаҗәрәт канун буларак яңа тәэсирләргә акрынрак бирелә, милләтнең үзлегенә булган баглылык куәтен еллар узуы белән бергә җуймый, чит илләрдәге милли-мәдәни инкишафында милли кыйбладан читкә тайпылмый; мөһаҗәрәт өчен иң куркынычлы әхвәл — яңа юлларга кереп китү, милләт үзлегенең үзәгеннән ераклашу булганга, безнең мөһаҗәрәтебезнең һәр уңайда иске милли-мәдәни барлыгыбызга йөз тотуы, илсез тормышта шуңардан илһам алуы милли иҗтимагый хәятның иң иҗаби тарафыдыр.

Әле генә уздырылган егерме биш еллык Тукай кичәләрендә мөһаҗәрәтебезнең шул хосусиятенә тагы бер мәртәбә шаһит булдык.

Бөтен мөһаҗәрәтебез Тукай кичәләренең ганганәви барышында берләшеп, Тукай вә аның иҗаты хакындагы карашын тагы бер мәртәбә тәкрарлады. Үзенең матди вә мәгънәви көченә нисбәтән иленең бөек шагыйрен искә алды, әфәләм төрле «акыл сату» белән шөгыльләнеп, Тукай иҗаты хакында яңа «караш» мәйданга атмады. Бик садә генә итеп сөекле шагыйренә булган хөрмәт вә мәхәббәтен генә күрсәтергә тырышты.

Бөек шагыйрьнең дөнья белән саубуллашуына чирек гасыр вакыт узып китте. Бу вакыт эчендә түгел ки, Тукай кичәләрендә шагыйрьнең бер-ике шигырен укып чыгу, тәрҗемәи хәлен сөйләп бирү, шагыйрьнең бу бөеклеге хакында истәлекләр язарга вакыт иде. Ләкин үксез шагыйрьнең бәхетсез, әсир милләте, ул яшәгән вакытта әсарәтнең ачы җимешләре булган караңгылык пәрдәләре аркылы үзенең арасында нинди бер нур балкыганын күрә алмаячагы төсле, ул үлгәннән соң узып киткән егерме биш елдан соң да аның исемен мәңгеләштерерлек бер эш тә эшли алганы юк. Тукайның җеназасы көтелмәгән рәвештә зур уздырылуыннан, халыкның милли барлык хисе бөек бер һәяҗан хәленә килүеннән куркып калган кара рус түрәләре шагыйрьнең вафатына бер ел тулу уңае белән истәлек тупланышлары ясарга рөхсәт бирмәгәннәр. Шигырьдән, шигъриятеннән башканы белмәгән Тукайны революционер дип атап, халыкны куркытмакчы, шагыйрьдән ераклаштырмакчы булганнар иде. Кызыл руслык исә, Тукайга динче, милләтче, контрреволюционер тамгасын сугып, аны зурлаудан, аның әсәрләреннән ләззәтләнүдән халыкны тыярга тырышты. Чар Русиясе заманында үзенең шагыйрен үзе теләгәнчә искә ала алмаган Идел буе шагыйренең вафатына егерме биш ел тулганда да аның бөеклеге шәрәфенә мөнасиб дәрәҗәдә берәр милли-мәдәни барлык мәйданга китерүдән мәхрүм. Әгәр дә инде кызыл Мәскәү, халкыбызның үзлегенә баглылыгын җиңеп чыга алмыйча Тукайның егерме биш еллыгын тавышсыз-тынсыз гына уздыртудан гаҗиз калып, Тукайга багышлап берәр нәрсә мәйданга китерергә ирек бирсә дә, милләтебезнең саф минлегеннән туган кыйммәтле бер барлык булу ихтималы юк. Чөнки, ничек кенә булса да, рус большевигы безнең халкыбызның рухына багланышы булмаган, бигрәк тә Тукай шигъриятенә һичбер мөнәсәбәте булмаган бер яңалык китерергә тырышачак. Шуның өчен Тукайның бу бөеклегенә мөнасиб чын мәгънәсендә зур бер истәлек, кыйммәтле бер һәйкәл халкыбызның иреге, туфрагыбызның хөрлеге белән генә булачак. Илебезнең әсарәте бетерелмичә, аның кыйммәтләренә, байлыкларына тиешенчә бәһа куеп хөрмәт ителү имкяне булмаячак. Шуның өчен мөһаҗәрәтебез тарафыннан бик кечкенә генә күләмдә ясала торган, ләкин хәзинәсендәге бөтен байлыгын ирекле рәвештә уртага салып уздырылган бу истәлекләр илебездә кызыл камчы, большевик коткысы астында ясала торган «бик зур» истәлекләрдән, мәгънә җәһәтеннән һәрхәлдә бөегрәк урын тотадыр. Мөһаҗәрәт Тукайга гаид материалга бик фәкыйрь булса да, аның кулында сакланып калган кадәресе генә дә шагыйрьнең тормышына, аның иҗатына багышланган табигый, саф материаллардыр. Кызыл коткы тарафыннан әллә нинди буяуларга буялмаган тугры мәгълүматтыр. Болар белән Тукайны тикшерү, аның иҗатын өйрәнүнең юллары ябылмаган булса да, әсассез тикшерүләр халкыбызның миллимәдәни барлыгына хилаф эзләнүләргә караганда, бу материаллар шагыйрьне дөрест тану өчен хас вәсикалардыр.

Шунлыктан Тукайның вафатына егерме биш ел тулуга багышланган истәлекләребез, шагыйребезгә булган мәхәббәт вә хөрмәткә самими рәвештә нигезләнгәнгә, кызыл руслар карамагындагы шау-шулардан кыйммәтлерәктер. Киләчәк өчен дә Тукай иҗатының үз йөзе саклануы карашыннан әһәмиятлерәктер.

Ерак Шәрык мәркәзе тарафыннан егерме биш еллык истәлеккә багышлап нәшер ителәчәк «Тукай рисаләсе» шул ук әсасләргә таянып чыгарылачактыр. Тукайның иҗади рухына оемый торган фикер вә карашларны мәйданга ташларга иҗтиһад итмәячәктер. Бу рисаләне чыгарудан максат илдән читтә яши торган яшьлеккә Тукайны таныту, мөһаҗәрәттә илнең кадерле шагыйренең хатирәсен тапсыз-керсез саклау булганга, мәркәз бу эшкә мөһаҗәрәтебезнең киңрәк катлавын катыштырырга карар иткәндер. Вә рисалә-

нең чыгуын апрель аеннан кичектереп булса да, шул юл белән күбрәк вә әсаслерәк материал туплауны тиешле тапкандыр.

Мәркәзнең бу тәшәббесе мөһаҗәрәт тарихыбызда якты сәхифә булып киләчәктә дә бер кыйммәтле материал булганы төсле, бу рисаләнең нәшер итү мәсарифын күтәрүче хөрмәтле мәркәз әгъзалары Хөсәен Биглиц һәм Сабир Җиһаншаһ әфәнделәрнең хезмәтләре шиксез зурдыр.

Мөһаҗәрәтебезнең өстенә йөкләнгән милли-вөҗдани бурычлар арасында иң зурысы милләтебезнең кыйммәтле барлыкларын керсез хәлдә саклап калу вә бу саклауны тарихи вәсика хәленә китерү булганга, Ерак Шәрыктәге илдәшләребезнең бөек шагыйребезгә багышланган бөтен эш вә тәшәббесләре милли-вөҗдани бурычларыбызны үтәү, яшь буыныбызны илгә, илнең милли-мәдәни барлыкларына баглауга каратылгандыр.

Кадерле шагыйребезнең вафатына егерме биш ел тулу уңае белән гәзитебезнең бу санын аның кыйммәтле хатирәсенә багышлап, кызыл рус тарафыннан вәйран булган кабере алдында тезебезне чүгәбез вә мәрхүмнең газиз рухына самими тәкъдир вә мәхәббәтебезне сонабыз.

**Рокыя Мөхәммәдиш**

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

*Вафатына 26 ел тулу уңае белән*

Халкының күңелендә шундый зур урын ала беләләр ки, кайсыбер шагыйрь һәм язучылар елларның узуына, тормыш юлларының үзгәрүенә карамастан онытылмыйлар, бары шундыйлары халыкның милли барлыгына тәмсил итәрлек дәрәҗәдә тарихка керәләр; дөнья милләтләренең бер-берләрен тануда, берберләренең мәдәният байлыкларын өйрәнүдә васита булалар, дөнья әдәбияты шундый берничә бөек исемгә мәлик ки, мәгълүм милләтнең әдәби байлыкларының мөмәссилләре булып гәүдәләнәләр.

Яшьли дөньядан киткән Габдулла Тукай да дөнья әдәбиятының бөекләре арасында шундый хөрмәтле урынны билидер. Идел-Уралның халык шагыйре Тукай «сәнгать — сәнгать өчен» мәгънәсендәге бер шагыйрь булмаганлыктан, бәни бәшәр үлчәвендәге хис җырчылары, матурлык кыллары белән чагыштырыла алмаса да, Тукай Идел-Урал төрк-татар шигъриятенең мөмәссиле сыйфатында дөнья шагыйрьләре белән буй үлчәшә аладыр. Тукайның бөтен бәни бәшәрне үзенә биләрлек уртак моңга хуҗа булмавы аны дөнья милләтләренең бөек шагыйрьләреннән мәгънә җәһәтеннән дә, моң, вәзен игътибары белән дә аслан кечерәйтмидер. Тукай — халык шагыйре. Халык дәрте, халык моңын үзендә гәүдәләндерүче бөек бер җырчы булганга, ул милләтләр арасы ярышларына халкы белән бергә чыга. Шуның өчен Тукайның вафатына бүген 26 ел тулган булса да, Идел буе төрклеге милли горур белән иленең моңлы баласы — Тукайны искә ала. Тукай төсле шагыйрьләрнең бөтен кыйммәте дә шунда. Алар халык катлауларын бергә туплаучы куәт ролен уйныйлар. Чөнки алар халыкның төрле тормышындагы, дөньяга төрле караштагы сыйныфларны берләштерә алырлык аһәң тараталар.

26 ел моннан элек «ярты җырында» өзелгән Тукайны мәңгелек йортына озатыр өчен Казанның голәмасы, сәүдәгәре, һөнәрчесе, кара эшчесе бергә тупланган иде. 1902 елда Идел буеның әдәби теле ясалуга, милли аңы уянуга, гарби культураны үзләштерү сукмакларына кертеп җибәрүгә сәбәпче булган Габделкаюм Насыйриның вафаты исә Казан өчен бөтенләй сизелмичә калган иде. Тукайның җеназасы милли аңыбызның күтәрелүен күрсәтүче көчле бер нөмаеш төсен алды. Тоткын илнең хәсрәте, шәхси ятимлек, тормышының караңгылыгы эчендә җитешкән шагыйрьнең тавышы киселүе Казанны уятты. Тоткынлыгы аркасында кадерле углын тиешенчә тәрбия итә алмавын алдына китереп куйганга, халыкның дошманга булган ачуы арта төшүенә сәбәпче булды.

1913 елның 2 апрелендә (яңача 15 апрель) Казанның йөрәген әрнеткән бу югалту әле бүген дә Идел-Урал төркенең күңелендә әрнү, сызлану белән ашланган. Тукай моңы да аның йөрәгендә. Тукайны тудырган, Тукай истигъдадын моң белән өреткән Идел буе Тукай тәгъриф иткәндәгедән дә таррак дәверен кичерә. Шул тарлыкны күтәрә алмыйча чит җирләргә таралган Идел-Уралның угыл вә кызлары әле дә, Иделнең агымын күрүгә, туган иленең һавасын киң иттереп күкрәкләренә тутыру омтылышы белән яналар.

Шуның өчен туган ил бүген дә Тукайны искә ала. Идел-Уралның мөһаҗир балалары, илнең кыйммәтле шәүләсе булган Тукай моңына таянып, Ватанны күз уңыннан уздыралар.

Шунлыктан 15 апрель илне мөһаҗәрәттәге балаларына баглаучы боҗра төсен алды. Мөһаҗир Идел-Урал төрке, 15 апрельдә тупланышлар ясап, кичәләр куеп, Тукайны искә алуны үзенә милли бурыч итеп алды. Хазир илдә аңа ул теләгәнчә сулыш алырга да ирек бирми башлаган кызыл хакимияткә каршы кө-

рәшендә 15 апрельне корал итеп ала. Милли шагыйрен искә алдырмаска Идел өстен каплаган, Уралны авырлыгы белән баскан коммунизм албастысының да көче җитмәгәнгә, тоткын Идел-Урал, иске көннәренең хатирәсендә пакь итәр өчен, 15 апрель көненә сарыла.

«Милләтләргә ирек, милли мәдәниятләргә инкишаф» бирә ич Мәскәү. Гайре рус тоткыннарын азлыклары өчен бу уйдырма корал ителгән вакытта Мәскәү Тукай көне тупланышлары ясалуга табигый буларак каршылык күрсәтми. Чөнки халыктан бу ирекне дә тартып алырга база алмый. Халык — көч бит ул, Тукай мәрхүм әйтмешли.

Дүрт гасыр буена Идел-Урал байлыклары белән карынын туйдырып килгән ерткыч Мәскәү дә моны бик яхшы төшенә. Шул төшенчә тоткын илгә вакыт-вакыт милли берлек нурларында хәл җыярга ирек бирдертә. Шунлыктан илебезне большевик килеп басканча мөкаддәс булган бер милли барлыгыбыз бүген мәйданга чыгарылмаса да, Тукай рухы яз саен Идел буенда хөкем сөрә.

Кышкы салкыннарның золымыннан баш күтәрә алмаган табигать яз нурларында гына үзенә көч җыйган төсле, Идел-Урал төрк-татар милли барлыгы да апрель уртасында күкрәк тутырып сулыш ала. Рус большевигы халык шагыйре Габдулла Мөхәммәдгариф углы Тукайның каберен оныттырлык итеп таптап, җир белән тигезли алмый. Ел саен басыла торган Тукай истәлекләре дә большевик ялчылары авызы аркылы шагыйрьнең чын йөзен халыктан яшерер өчен төрле такмазалар саттырса да, Тукайны пролетар җырчысы итеп ясап бетерә алмый. Халкыбызның рухына руслаштыру өчен кулланылмаган тәдбирләрне калдырмаган Мәскәү Тукайның «чын безнеңчә» булган шигырьләрен руслык рухы белән пычратудан гаҗиз кала. Халкыбызның саф үзлеге озын елларның золымы белән пычрата алмаганы төсле, халык йөрәгенә күмелгән Тукайның саф моңы да большевик коткыларына бирешми. Тукайның җир астына күмелүенә еллар өстәлә барган саен, Тукай моңының халкыбызга булган тәэсире күтәрелә бара.

Әсир халкыбызның утта янмый, суда батмый торган корычтай нык милли үзлеге төсле, Тукай моңы да, 26 еллык аерылышуны атлап чыгып, Идел буенда бүген хөкемен йөртә вә 20 елдан бирле күкрәгендә ил кайгысын ташучы Идел-Урал мөҗаһәрәте рухын бүген ил кочагына кайтара. Илсез үскән яшьлек тә Тукай моңы тәэсирендә, берничә сәгатькә генә булса да, бүген ил белән мәшгуль була. Вә бөтен милләт белән бергә халык шагыйренә үзенең тугры тамгасын куеп, үзе арасында күтәрелгән шагыйрь сүзләре белән Тукайның кыйммәтен вә аның халык күңелендәге урынын үлчи:

Кайнап чыккан мәгърур ут диңгезен*
Йөзеп чыктың илнең юлында.
Кара тормыш золмәт арасында,
Йолдыз кордың изге юлыңда...

Канлы көннәр үтәр... Еллар китәр,
Илнең бәхте беркөн ачылыр.
Бер кайгыда сине, бер шатлыкта
Илкәй сине мәңге сагыныр!

**Мәдинә Салиәхмәт**

## ТУКАЙНЫҢ МӘГЪНӘВИЯТЕ ӘТРАФЫНА

*Габдулла Тукайның 30 еллык истәлегенә багышлап*

Мәңгелеккә юнәлгән еллар кайгылы шагыйребез Г.Тукайны бездән ераклаштыру хәрәкәтенең дәвамында икән. Калдырган бөек мирасының мәгънәвияте, парлак йолдыз кеби, милли күгебезнең йөзендә елдан-ел нурлана баруын күрмәктәбез.

Тукайның хәяттагы заманның балалык, бәлки, яшьлек күзе белән күргән бүген яшьле кыйсемебез өчен «тахаттыр канаты»нда очарлык бер заман кисәге аркада ятмактадыр вә бу кисәктә милли хәятыбызның бөек үзгәрешләрен, тарихи үзгәрешләрен эченә алгандыр. Бу инкишаф дәверебезнең башы бөек ислахчыбыз Ш.Мәрҗанинең беренчеләп гареб мәдәниятенә йөз чөерүе белән башланган булса, Тукай дәверендә, заманның таләбе буенча, бу ике бөек мәдәниятнең, ягъни мөселман Шәрык вә Европа-гареб мәдәниятләренең кара-каршы килеп чарышкан заманнары булды. Аркасында меңнәрчә ел тарихы булган вә ничә-ничә мәдәниятләрне тудырган һәм шул заманга кадәр Шәркый мәдәнияте исеме белән мәгъруф бөек мәдәниятне коручыларының бере булган вә шул мәдәниятләрнең бөтен мөсбәт вә мәнфи куәтләрен үзендә татыган төрек халыкларының бер кыйсеме без Идел-Урал төркләре өчен бу җиңеллек белән уздырыла торган бер инсийәт түгел иде.

Мәгълүм ки, мәдәниятләре сай булган халыклар бу адымны күп җиңел атлыйлар. Үзенең иске тормышын бер якка селкетеп ташлап җибәрә дә соңга башы-аягы белән икенчеләре төзегән мәдәниятка кереп тә китәләр.

Югарыда әйтелгәнчә, безнең кебек мәдәниятка салмак караган бер милләт өчен бу бөтенләй икенче тарызда уздырыла торган үзгәрешләрдер. Чөнки башкалар узган мәдәниятка хәзер үк килергә безнең халык үзенең узганын онытып керә дә алмый, сыеша да алмый. Ул фәкать заманнары яшәгән җирдә зиһниятләрне халкыбызның үсүенә, инкишафына киртә салган тормышыбызның мәнфи тарафларны ыргытып, шуларның җиренә, халкыбызның яратылышына уйгын вә тарихи, табигый юлыннан саптырмый, алга сәвекъ итә торган мөсбәт тарафларын аралап, барлап, алар да мөгасырлаша гынадыр. Әлбәттә, бу ифрат мәсьүлиятле бер замандыр.

Халкын алга сәвекъ итүне үзенә вазифа итеп алган, халкын чиксез сөю белән сөйгән инсаннар гына үзләренең зәкяләре, тирән тойгылары вә урыны белән сәвекъ табигый куәтләре белән бу тәһликәләрдән коткара алалар.

Хәмед булсын, инкишаф дәверебез мондый сыйфатлы затлардан мәхрүм булмады, вә бүген үзебезнең кемлегебезне шөгур белән аңлыйбыз икән, милли мәфкүрәбез булсын, мөһаҗәрәт күләмендә генә гәүдәләнде икән, без шул заманнарга чиксез бурычлыбыз. Чөнки алар гасырларның, мең елларның чытырманлыгы аша фәкать үз күкрәкләре белән юл ачып, вакыты белән, ихтимал, абынып, сөртенеп, зур зәхмәтләр чигеп булса да, ләкин халкын адаштырмыйча, тугры хакыйкый милли юлга чыгарып җибәрүчеләр.

Барысыннан да бигрәк инкишаф дәверендә җанлылык күрсәткән сахәдә әдәбият сахәсе булды. Шул сәбәпле анда кыйммәт бирелә, тәкъдир ителә торган әһелләре дә байтактыр. Бу шәхесләрнең иң бөекләре сайгылы әдибебез Гаяз әфәнде Исхакый белән бу ел үлүенә 30 ел тулган шагыйребез Г.Тукайдыр.

* * *

Халкыбызның бөек иманы, пакь вөҗданы вә әхлагын үзендә таныткан шагыйребез Тукайның шәхесен калдырган әсәрләре аша күрергә [...]* тырышканда, бөек төрк мөтәфәккире Зыя Күк Алыпның үлеменнән соң аны характерыбыз иткән мәрхүм Ага углы Әхмәднең мәкаләсе** кылт итеп хәтергә төшә.

Бу мәкаләдә ошбуларны укыйбыз: «Зыяи рухы вә димагый хосусиятләре илә мөкәммәл бер төрк әнмүзәҗе иде. Төрк тарихында бер «атсыз» тип бардыр. Бу тип төрк халык массаларында «кәл углан» намыны ташыган бер каһармандыр. Бу каһарманны төрк халкы чук сөядер, бөтен мохит вә милләтне аның әтрафына туплар. Чөнки төрк бөтен мәгънәви хосусиятләр үзләрендә туплыйдыр. Ул вәзгыйлар мәүҗүддер, мәүгудледер. Ул агыр дөшенер, агыр сөйләр, агыр хәрәкәт итәләр. Ул нөмаишыннан чигенийүр күрсәтереш, сәвелмәз. Ул мәтин хезмәткәрдер. Үзе бер, сүзе бердер. Башкаларны [...]*** чигенийүр. Хәятыны вә талгыны кәнди кабилиятләренә мәдъюн булмактан хушланыр канәгатькәр вә фидакарьдер», — ди.

Әгәр карый торган күзләр белән түгел, күрә торган күзләр белән Тукай шәхесенә багылса вә гади укучы гына булып калмый, төшенеп укучы буларак аның әсәрләре укылса, шагыйрьнең шәхесендә югарыда Зыя Күк Алыпка каратып әйтелгән сыйфатларның шиксез күбесен, ихтимал, барысын да тоячакбыз. Чөнки Тукайны сөйдергән нәрсә аның татарча матур аһәңле ишетелгән шигырьләре генә булмыйча, шигырьләренә өртелгән, шулар аша күренгән зур җаныдыр да.

Ихтимал, «агыр дөшенер, агыр сөйләр вә агыр хәрәкәт итәр» дигән сүзләр шат табигатьле һөҗү вә шака сөйгән җанлы Тукайга бик үк тугры килми кебек тоелса да, замандашлары, яшьтәшләре башкалардан алган яңалыклары белән җилкенеп йөргән заманда Тукайның тотрыклыгы киртә сикерми, ифратка бизәлмәве вә бигрәк тә дошманнарның һөҗүменә нисбәтән шулкадәр оста, үткен, үтергеч бер каләм иясе булып та аларга берничә генә шигырь белән җавап бирүе аның суык канлылыгы вә «авыр сөйләүче» булуына дәлилдер.

* * *

Үзләренең истигъдадлары белән гаммәдән өстен торган шәхесләр әтрафында ике бер-берсенә зыйдд фикерләр, төшенчәләр булуы ихтираслары уйнавы мәгълүмдер. Шулар белән мөхибләр, дошманнар җәбһәсе төзеләдер. Тукай исеме әтрафында гайне күренештер. Тукайның мөхибләрен тикшермичә аны кимсеткән, борчыган бөһтан гайбәтләре белән рәнҗеткән дошманнарын кем дип атыйк?

Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләренә фетнә вә комачаулар япкан мөтәгассыйб руханилармы алар яки бөек Каюм Насыйрины аңламый, аны көлкегә алган, фәкать соңгы яшь шагыйрь Тукайның үткен каләме белән «Яңа Кисекбаш»та тасвир ителеп, үзе көлкегә калган мөтәгассыйб иске фикерле халкыбызмы? Юк, болар түгел. Тукайны зәһәрләгән кыйсемдә чит культурын танып, шуның белән үзе зәһәрләнгән әзасындадыр.

Тукайга дошманнар япкан Галимҗан Ибраһимовлар, Фатыйх Сәйфиләр шул чит авыруга мөбталя булган шәхесләр түгелме иде? Рус революцион фикерләре белән җилкенеп йөреп, шуларны русчалап халкы-

быз арасына кертергә йөргән болар булса, ул заманда әдәбиятта бик модада булган «җенси мәсьәлә» хакында язучы Куприн, Ацыбашевларның әсәрләрен укып, шуларча «җенси мәсьәлә»не әдәбиятыбызга кертергә йөрүче дәхи Галимҗан Ибраһимлардыр.

Алар ук Тукайдан соң килгән большевик дәүләтчелеге заманында большевиклар артыннан ияреп «җенси» әдәбият урынына «сыйнфый» әдәбият тудырырга йөрүчеләр иде.

Заман, күп узмаса да, үзенең хөкемен Тукайга да, Тукайның мохалифләренә дә куйды. Тукайны нинди хаким көчләр вә нинди мәгънәви мәнбәгъләр бәсләп милләтенә биргән вәгъдәсен үтәргә тырышканы күренгән кебек, Тукай мохалифләренең дә нинди көчләргә табынып, таянып йөрүләре аркасында юкка чыгулары да мәгълүмдер.

Сүз уңае белән Тукайга нисбәтән булган дошманлыкның ни дәрәҗәдә булуын күрсәткән бер вакыйганы язып үтәргә телим.

1916 елда Уфа әтрафындагы җәйлек өйләрдә тәгътыйль вакытны уздырганда, Казаннан Уфага килеп урнашкан Фатыйх Сәйфи дә шул ук җирдә истирахәттә иде. Аның белән бергә моңлы тавыш белән милли көйләребезне оста итеп җырлаган, Галимҗан Ибраһим, Сәгыйть Сүнчәләйләрнең мөштәрәк дуслары «А» ханым да бергә иде.

Торышы да кан алган күзләр белән дә хәзер дуларга торган атка охшаган Сәйфинең сөйләвен аңлау шактый читен иде. Чөнки авызыннан әллә нинди бер лыбырдау ноктасы чыгара иде.

Бер айлы кичне Кара Иделгә караган биек тау башына җыелган яшьләр янында Сәйфиләр дә булып, «А» ханымның матур җырлары тыңланды. Арада яшь җилкен арасында бик үк килешеп бетмәгән «Актүш бикәй кыз» да җырланды. Ахырда китәр якка «А» ханым Тукайның «Әй мөкатдәс моңлы сазым»ны сузып җибәрде. Шул арада, гакылдан язган кеше кебек, Сәйфи: «Җырлама шул кабахәтнең сүзләрен», — дип яман аваз белән бакырды. Соңгарак кеше аңлый алмаган бертуктаусыз лыбырдау китте...

Тукайга үлгәннән соң да дошманлыклары кимемәгән мохалиф җәбһәсенең бер мөмәссиле булган Сәйфинең Тукайны сөйгән яшьләр каршындагы кабахәт итмәкен мөмкин...

Эшләре шул: болгасыннар әйдә зәмзәм чишмәсен!

*«...гә» («Ядкяр»)*

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ МӘГЪНӘВИЯТЕ ӘТРАФЫННАН

Тәсадефән кулыма ябанчы бер телдә язылган XII гасырдагы азәрбайҗан шагыйре Ниязи хакында язылган бер китап килеп керде.

Халкын шигырьләре аша тәрбияләүгә гомерен сарыф иткән шагыйрь бер җирдә ошбу сүз әйтә:

Кальбтән чыккан фәкать кальбләргә ирешәчәк.
Шул сәбәпле җырлау тиеш бугазыннан кан киткәнче.

Сигез йөз елдан соң:

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен, —

*(«Сәрләүхәсез»)*

ди халыкның бәхете өчен җан атудан йөрәгенә кан саудырган Идел-Урал төркләре шагыйре Габдулла Тукай.

Заман вә зәмин аермасына карамастан, ике төрк шагыйренең бер әмәл өчен тоткан бер үк тел шаян дикъкатьтер.

Ниязидан:
Диңгез кеби бул син —
Разый үз байлыгыңнан.
Бул агач — тик яфрак аттыр
Син үз-үзеңнән.

Бу ике мисраг әйтерсең лә халыктан үзен аслан аермаган, халыкның мәгънәви байлыгыннан илһам алган Тукай өчен язылган.

* * *

Мәрхүм галимебез Ризаэтдин бине Фәхретдин каләме белән «Шура»да* язылган бер язуны хәтерлим. Гали мәктәбендә укучы бер туташыбыз хәзрәткә язган хосусый хатында «Ни өчен без үзебезнең иске әдәбиятыбызга әһәмият бирмибез? Ни өчен шундый әсәрләргә** хак куймыйбыз?» дигән икән. Бу сөаль

рәхмәтленең хушына шулкадәр киткән ки, куаныч елмаю белән нурланган йөзе әйтерсең лә язулары аша күренеп тора.

Үзенең белге күзе илә могасыйрларыннан күпне күрә алган галимебезгә бу соргый шулкадәр тәэсир иткән икән, Тукайның бәгъзән иске әдәбиятыннан үрнәк алуын мохалифләре аның иҗатын юкка чыгару максаты белән гафу итмәслек бер кимчелек кеби күрүләре дәхи мәгълүмдер.

Тукайның шигырьләрендә бу әсәрләрнең ингыйкясе күренмәсә, үзе гайре табигый бер эш булыр иде. Чөнки Тукайдан ул яшәгән халкыбызга болар азыгы булып килгәннәрдер. Тукай заманында алар тудырган һава әле дә таралып бетмәгән булуыдыр.

Тукай мөхибләре вә дошманнарының бер уртак сыйфатлары булса, ул да Тукайны хәятта заманында булган кеби, үлгәннән соң да рус язучылары, шагыйрьләре, бигрәк тә Пушкин белән чагыштыруларыдыр.

Тукайны бердәнбер җентеклəүчебез буларак танылган саягылы Җамал Вәлиди дә бу мөддәттән калмаган. 25 яшьлек Тукайны 60–80 яшьләрдә тәкәммелгә ирешкән Толстой белән чагыштыра вә микъяс фәркы Тукай галәйһенә була.

Тукайны, шиксез, бу үлчәүләр борчыган булырга тиеш һәм шулай ук, мөвәкъкатьо булса да, рус мәддахларының сүзе аңа да сирмәт иткән. Чөнки болай булмаганда, шигырьләрнең башында бик үк хушыбызга китмәгән «хәзрәти Пушкин»нар, фәләннәр куелмас иде. Бу олуглар, әлбәттә, Тукайның хәле галиҗәнаплыгын күрсәтәләр, фәкать бу җирдә күңелне тынычландыра торган икенче бер як бар, ул да булса Тукайдагы ифрат дәрәҗәсендә куәтле сәвекъ, табигый сизгерлеге, бу да исә үзен милләте каршында мәсьүл санаудан килгән сыйфаттыр. Фикеремне аңлатыр өчен P.Kaleryның* шушы сүзләрен китерәм:

«Кулайча тәкълид ителә беләчәк, тәкълид ителгәндә, кулайча әфкяр ителә беләчәк шәйләрдән качынмалыдыр».

* * *

Тукайда мөстәкыйль бер дөнья күреше нәзариясе һәм мөстәкыйль фәлсәфә булмаганлыгын язалар, ихтимал, шулайдыр да, Тукай ислам дине фәлсәфәсен бар тирәнлеге, бар бөеклеге белән аңлаучыларның берседер.

Шулай ук, ихтимал, бу фәлсәфәне ул төрек халкының дөнья күреше нәзариясе белән дә төшенәдер. Чөнки без төрек, гарәп, чинлы, һиндлы вә башкалар барыбыз да бер ислам динендә булсак та, аны төшенүдә үзебезнең милли хосусыйларыбызның рольләре аз булуы тиешле төсле түгел. Ник Тукайның дини мәүзугътагы шигырьләре исә, Кәляме Шәрифтән алынып, иң куәтле әсәрләре буларак таныладыр?

Тукайның 25 еллыгында мәрхүм Шәмгуни хәзрәт аларны әһле буларак тикшерә дә башлаган иде. Тукайның дини мәүзугътагы шигырьләре белән гасырлар буе ислам диненә һөҗүмдә булган вә «Мөхәммәд ялгыз Мәдинәгә таянган биәхлак бер дин» тудырды, дип ялган нәзарияләр тудыручы христиан галәменә җавап буларак кулланасым килә* :

Бәхре вәхдәт асты өсткә килде шунда, кайнады,
Бетте, мәхү улды зәмин, һәм дә замана калмады.

Калмады сурәт, бары тәбдил ителде мәгънәгә;
Әүрелеп мәгънәгә, дөнья сәҗдә кыйлды Мәүлагао.

Күрде Алланы пәйгамбәр, сәҗдә кыйлды, баш иде;
Ушбу җир булды бөтен мәсҗедләрнең дә мәсҗеде.

Булды саф-саф, кыйлдылар сәҗдә мәляикләр бары;
Җәмгулып һәрбер нәби, Муса вә Гайса җаннары.
Булды заһир, белмәделәр җир йөзе мөнкирләре:
Монда габдият, гыйбадәтнең илаһи серләре.

*(«Мигъраҗ»)*

* * *

Бәни бәшәр философларның гакылын ишгаль иткән үлем мәүзугы Тукайның гакылын да ишгаль иткәне күренә. Бу мәүзугъны эченә алган шигырьләре бөек кыйммәтне хаиз шигырьләрдер.

Әдип Фатих Әмирханга дусларча шат йөз белән соңгы хушлашу сүзен әйтергә килгән шагыйрь, әлбәттә, үлемнең бөек серләрен төшенгәндер вә шуңа күрә:

Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга мәңгегә,
Мәңгелеккә — мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьгә! —

*(«Ваксынмыйм»)*

дигәндер.

Инсан нинди генә бөек әмәлләр белән гомер буена янмасын, шәхси тормышындагы бәхетсезлек аны чиксез ачындыра вә шул вакытта бердәнбер нәселе вә шәфкать учагы сүнми, суынмый торган ана мәхәббәтедер.

Ана мәхәббәтен бик аз күргән шагыйрь бу мәүзугъта да үзенең тирән тойгылыгын күрсәткән. Күп сүз сарыф итми. Мин сәнгатькәрчә язылган сәтырларны яраткан шагыйрь каләме генә түгел, бер [...]* кулы да булышкан икән кеби тоела:

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, —
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

*(«Өзелгән өмид»)*

* * *

Тукай ни гаилә тәрбиясе, ни монтазам мәктәп вә ни үзеннән өлкән мөнәвир кыйсеменең юл күрсәтүен күрмәгәндер. Ләкин үзен-үзе эшләтү, һәр фикерен җентекләп рухан кәмаләткә ирешү хәрәкәте өзлексез дәвам иткәнлеге шигырьләре аша күренәдер. Үләр елны язылган шигырьләрендә күп уйларның йөгәнен дә чыгарырга муафыйк булганда, гадәттә шагыйрьләрнең әсәрендә асыл фикер бер-ике юл эченә алынып, башкалары бу фикернең аңлашуына ярдәмчелек кенә итсәләр, Тукайның асыл фикере тупланган мисрагларны читләр каршына чыгарсак, йөзебезгә аклык кына китерәчәктер. Җөмләдән бере Тукайның зур хөрмәт вә милли горур илә тулы Шиһаб хәзрәткә каратып язылган шигыредер. Аурупа халкында без төрк халыклары хакында бик нык урнашкан бер караш тарызы бардыр. Ул да: «Бу халыклар инсан вә шәхесләр җитештермәделәр вә аларга хак та бирә алмадылар. Алар каршында фәкать [...]* бар...»,— имеш.

Тукайның һөҗү белән «безне юкка яманлыйлар» дигән сүзен без җитди рәвештә «безне юкка яманлыйсыз» димибез. Инсан шәхесе хакында менә нәрсә әйткән төрк шагыйре Тукай:

Инсан дигән бер шәрәфле бер мәхлукта ул
Бар дип белә хаким гакыл вә хөр гакыл.

*(«Шиһаб хәзрәт»)*

Бөек төрк өлкәсенең бер кыйсеме булган Ватаныбыз Идел-Урал иде. [...]** кавышканнан соң сөрмә урынына йөртеләчәк туфраклар безне бу бөекләребезнең һәйкәлләре белән сүзләгән вакытларда диючә, бөек, мәһабәт сынлы Шиһап хәзрәтнең һәйкәленә бөек шәхесне бөекләргә тасвир иткән бу ике юл иң яраклы язу булыр кебек тоела.

* * *

Тукайны киләчәк буын бездән артык таныр дигән канәгатьтәбез. Хәзергә исә яшь буынга Тукайны танытучы безләрбез. Ана кочагындамы, мәктәп көрсисендәме булсын, балаларыбызга Тукайны сөйдерү нияте белән иң әүвәл аның кызганыч тулы тәрҗемәи хәлен сөйлибез вә шул сәбәптән балаларыбыз күңеленә шагыйрьне мескен бер Тукай буларак гомергә урнаштырабыз. Бу ысул, ягъни кызгану аша сөйдерү, шагыйрьнең бөек шәхесен кимсетү булып чыкмыймы? «Тукай хәятта булса, шул рәвештәге танышуны эстәр идеме?» дигән сөаль башка килә.

Тукайның рәсемнәрен күздән кичерсәк, аның үлем түшәгендәге соңгы рәсемендә дә һич мескенлек әсәрен тапмабыз.

Киресенчә, фикернең куәтле сарае кебек күзгә беренче бәрелгән бөек һәйбәтле маңгае, карамый күрә торган зәка тулы күзләре тәкәллефсез, ләкин олуглык күрсәткән тормышын күрәбез. Инде балалар белән шигырьләре аша уйнаган, көлгән, хикәяләр сөйләгән садә вә шат Тукайда кайдан мескенлек табасың... Зуррак кыйсем балаларга Тукайны кара бәхетен җиңгән бер каһарман кеби күрсәтергә әллә күпме үрнәкләр бар. Балаларга бөек гайрәт калдырган шагыйрь мескен була аламы?

Төрк дөньясы гаҗәп зур үзгәрешләр белән күпме заманны уздырадыр.

Әгәр безнең көннәрдә Тукай яшәсә үлмәс. Ататөрекнең тел-хәреф инкыйлабларын күрү белән ачылган тарих пәрдәсе аша үзенең мөҗәлля бер тарихка малик булырлык икәнлеген өйрәнсә, Тукай, бер мөҗәлля шәһвәт өстенә куныл: «Мин татар шагыйремен», — диеп калыр идеме икән? Юк, Тукайның бар яратылышы, омтылышы, фикере, йөреше төрк дөньясын дулкынлаткан яңа фикерләрне иң беренче эләктереп алучыларның, гамәлгә ашыручыларның бере буларак зан итеꞌлә.

Тукайның 25 елында Сәгадәт ханым тарафыннан матбугат битенә атылган берничәләп фикер: «Алар (ягъни Исмәгыйль баба Гаспралы белән Тукай) мөхәкъкак берләшәчәкләр, фикеренә кушылып берләшәчәкләр, чөнки алар бер үк бөек төрк милләтенең балаларыдыр бит», — дибез.

Безне упкыннардан, очырымлардан коткарып, яхшы киләчәккә юл ачкан Идел буе төркләреннән бөек Габдулла Тукай мәңгелекнең үзенә чумган!

**Надир Дәүләт**

## КАЗАН ТӨРКЛӘРЕ ҺӘМ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

(28.IV.1886–15.IV.1913)

Бөек халык шагыйребез Габдулла Тукайның тәрҗемәи хәлен өйрәнгән вакытта тормыш хәрәкәтенең бәхетсез милләт кадере белән охшашлыгын күрәбез. 28 апрель 1886 да Казан губерниясе Кушлавыч авылында дөньяга килгән Габдулланың атасы авыл имамы Мөхәммәдгариф, анасы Мәмдүдә иде. Яшьтән ятим калган Тукай төрле кулларда күп сагышлы көннәр кичерде. Ниһаять, 1905 елда Җаекта (Уральск) «Фикер» гәзитендә беренче шигыре басылды. «Әлгасрелҗәдид», «Нур»да да шигырьләре дөнья күрү белән шөһрәте тарала башлады. XIX гасыр ахырларында тарала башлаган һәм, 1905 ел революциясенең Русиягә китергән хөррият һавасы татарларга да матбугат иреге бирде һәм ысулы җәдид хәрәкәте белән мәмләкәттә реформа эшләрен тизләтте. Шуның нәтиҗәсендә авырлык күреп эшләгән гәзитләр, мәҗмугалар халык арасында мөнәсәбәт күренер иде. Тукайның да бу атмосфера шатлыгыннан демократик һава белән сугарылган шигырьләре көнендә халык арасына тарала. Аның шигырьләре таралганча да яратылган, сөелгәнгә хәтерләргә сеңгән иде. Элек заманнарда госманлы тәэсире белән язылган шигырьләрен, соңрак халкы шивәсе булган татарча иҗат итте. Шуның белән Тукай тагын яхшы аңлаешлырак булып, язганнары милли мәсьәләләрне күтәрде, юмор-сатира, дидактик шигырьләр — һәммәсе зиһеннәргә кереп урнашты. Шөһрәте көн үткән саен киң таралып һәм «Халык шагыйре» исемен казанган шагыйрьгә менә шуңа күрә көнләшүләр дә бар иде. Фәкать аңа каршы булган явыз көчләр ерак арада калырга мәҗбүр һәм нәтиҗәдә шунда эределәр дә. Тукай 15 апрель, 1913 тә Казанда үлгән вакытта 28 яшендә 7–8 еллык шагыйрь иде. Бу 7–8 елда аның иҗатында шактый киртәләр булган, шуңа карамастан Тукайның, киресенчә, шөһрәте арткан һәм халкын яратучы булып өлгергән. Хәтта бүген Тукай теле чит илләрдә яшәүче татарларда булсын, совет Русиясендә яшәгән татарларда булсын, тагын һәр яктан бөек, мәртәбәле. Сөембикә манарасы (Хан мәсҗиде) казанлыларда нинди бәйсезлек көрәш символы булса, Тукай да татар халкында бер әдәби символ.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында Тукай бүләкләре билгеләнде һәм 1970 елда бу премия җырчы Илһам Шакировка бирелде (Казан утлары, 1970, 7 сан). Аеруча әдәби вә сәяси журналларда төрле заманнарда Тукай турында мәкаләләр басылды, төрле җирләрдә аның исеме бирелде. Татарстан һәм Башкортстаннан, кызганыч ки, мәгълүмат алу мөмкинлеге булмады. Тукай өчен ясалган эшләрнең кирәклеге монда беленмәде. Рус ориенталистлары нәшрияты «Мир Ислама»дагы мәкалә (1913, җилд 2, сан 3), Мәскәүдә Көнчыгышны өйрәнүче Лазарев институтында нәшер ителгән (1914, 43 сан) Н.Ашмарин, С.Якуб, Акчурин (Йосыф Акчурин) тәрҗемәи хәлләре белән басылган шагыйрьнең «Мәхәббәт», «Өзелгән өмид», «Шүрәле», «Толстой сүзләре», «Эштән чыгарылган татар кызына», «Теләнче» исемле шигырьләре Англиядә чыккан Russian Reviewда (1914, III, № 1) басылган шагыйрьнең иң мәшһүр шигырьләреннән «Пар ат» һәм Вильямның мәкаләсе, 1920 елда Ташкентта Волинин һәм Казанда Р.Радимов тәрҗемәләре белән Тукайның шигырьләренең басмалары искә алынып, чит тикшеренүчеләрнең игътибарын азмы-күпме үзенә җәлеп итте. Моннан башка тагын Тукай шигырьләре башкорт, үзбәк, казакъ, каракалпак, кыргыз, азәрбайҗан, төрекмән, уйгыр, төрек телләренә тәрҗемә ителгән һәм бу телләрдә шагыйрьнең тормышы һәм әсәрләрен өйрәнү уку программаларына да кертелгән. Япониядә, Маҗарстанда да Тукай шигырьләре басылган. Аеруча итальян шагыйре C.Cermonetto Тукай өчен шигырьләр язган. Француз Луи Арагонө «Совет әдәбияты»нда Тукайны таныткан.

Төркиядә Габдулла Тукай хакындагы басмаларда профессор, доктор Фуад Көпрүлү, аның үлеме уңае белән язылган мәкаләсендә («Төрек йорты», 1913, сәхифә 499–515) «ялгыз «Тасвир-и Әфкар» белән «Ислам дөньясы» Тукайга берничә багана багышлады» дип дәгъва итеп һәм халкының аңа булган ихтирамының билгесе булган тантаналы шәкелдә ясалган шагыйрьне соңгы юлга озату, тәрҗемәи хәле, әдәби йөзе әйтелгән иде. Соңгы ун ел эчендә исә тагын казанлыларның көче белән Тукайны аңлатуны башлаган һәм «Төрек культур» җыентыгында Габдулла Баттал Таймасның «Казанлы шагыйрь Габдулла Тукай өчен» (№

9, 40–48 б.), Рәшит Рәхмәти Аратның «Габдулла Тукай» (№ 19, 68–76 б.), Әхмәт Тимернең «Габдулла Тукай» (үлеменә 52 ел тулу уңае белән) (III, 469–473 б.), Һ.Зөлфикарның «Габдулла Тукай» (VI, 374–386 б.) исемле мәкаләләре чыкты. Соңгы мәкалә дә җитди тикшеренү һәм нәтиҗәле хезмәт булып лаеклы урын алды.

Тукай турында ясалачак эзләнүләр, алар югарыда телгә алынган мәкаләдәге чыганаклардан башка Төркия китапханәсендә (Истанбул) булган «Яңа кыйраәт» (Казан, 1910, 56 б., билгесе № 3185), «Балалар көлкесе» (Казан, 1911, 26 б., билгесе № 5131), «Алтын әтәч» (Казан, 1908, 10 б., билгесе № 4860), «Көлкеле сәхифәләр» (Казан, 1910, 16 б., билгесе № 4861), «Энҗе бөртекләре» (Казан, 1910, 72 б., билгесе № 4917), «Мәҗмугаи асарь» (Казан, 1919, билгесе № 309) әсәрләрен карадылар. Тукай иҗатын өйрәнүче буларак Ибраһим Нуруллин «XX йөз башы татар әдәбияты» (Казан, 1966, 128–191 б.) исемле хезмәтендә аңлатканча, библиографик чыганаклар, 1943 елга кадәр булганнары, тәнкыйтьче өчен берьяклы тикшерү булып кабул ителгән. Моннан ары буларак, бигрәк тә Тукайның гәзитләрдәге эшчәнлеге өйрәнелгәне өчен Александр Беннигсен һәм Ch. Lemercier–Quelquejay`,n la Preess et le Mouvement National chez les Musu lmans de Russie avant», 1920 (Paris, 1964); сәяси һәм шәхси тормышы өчен А.Б.Таймасның «Казан төркләре» (Әнкара, 1968); Сергей А.Зенковскийның «Pan-Turkism and Islam in Russia (Cambridge, Massachusetts, 1960); И.Воробьев-С.М.Хисаметдиновларның «Татары Среднего Поволжья и Приуралья (Москва, 1967); G. Mende`nin «Der nationale Kampf der Russlands turken» (Берлин, 1937); Бензингның Алманиядә чыккан мәкаләләре һ.б. киңәш ителә.

Габдулла Тукайны бөтен казанлылар һәр җирдә мәхәббәт һәм ярату белән искә алалар. Тукайны белмәгәннәр, аның шигырьләреннән бер-икесен белмәгән татар юклыгы мөмкин булмаган эштер. Чөнки Тукай, милли әдәбиятыбызның һәм халкыбызның символы буларак, бишектән кабергә кадәр төрле очракларны каршыбызга чыгарды. Болар багар бакмас аның шигырьләрендә чагылды.

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу, —

*(«Бишек җыры»)*

бишек җыры белән тирбәтер.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы, —

*(«Туган тел»)*

белән ана телен яратырга чакырыр.

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген! —

*(«Бәйрәм бүген»)*

шигырь юллары белән бәйрәм сөенечен өйрәтер.

Әй бәхетле, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала,
Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага* , —

*(«Таян Аллага»)*

дигән сүзләре белән шуңа ышанычны арттырыр. Мәмләкәт ятатучы тагын аның шигырьләре белән үсәр. Миллиятенең газап чигүчесе аның шигырьләреннән алган шигырь юлларын һәрдаим мәсәл урынында кулланыр. «Кара, Тукай ни әйткән?» дип, аннан мисаллар алып, тормышында файдаланыр. Чит илләрдә яшәүче татар-төркләренең җәмгыятьләре Тукайның үлеме һәм туган көннәрен раслаган апрель айларында Тукай кичәләре уздыралар. Бу кичәләр еш кына аңа багышлап язылган «Тукай маршы» белән башлана, бер яшь бала аның балалар өчен, яшьләрдән берәү исә җитди шигырен укый, тәрҗемәи хәлен сөйлиләр, аңа багышланган яңа шигырьләр укыйлар. Хәтта милли уеннар, җырлар, театрлар төзеп, кичә бер Казан милли кичәсе хәлен ала. Тукай кичәләре безнең арабызда традицион бер күренеш һәм һәр ел игътибарсыз үтмичә ясалган кичәгә зур көч куелыр иде. Моннан ары буларак чит өлкәләрдә яшәүчеләр Казан төркләре һәртөрле нәшриятларында, шөбһәсез, Тукайга бер урын бирелер, һәм аның өчен шәхси язмалар да мөмкинлекләр нисбәтендә ясалды. Мәсәлән, «Токио Матбага-и Исламия»се 1933 елда (Тукайның үлеменә 20 ел тулу уңае белән) «Габдулла Тукай «Мәҗмугаи асаре» исемле шигырьләрен төзеп, 4 җилд (I — шигырьләр, 209 б.; II — балалар өлеше, 114–16–VIII б.; III — көлке һәм сатира өлеше, 89–II б.; IV — нәсер өлеше 104–I б.), Мукденда Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татар мөселманнарының дини милли мәркәзе мәгариф бүлеге 1938 елда (Тукайның үлүенә 25 ел тулу уңае белән) «Габдулла Тукай» исеме эчендә 20 мәкалә һәм шигырь төзеп, 98 битлек бер әсәр нәшер иттеләр. Финляндиядә дә Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәреслеге» (137 б.), Һельсинкида 1953 елда төрк халык мәктәбен саклау нигезе тарафыннан һәм

аеруча тагын Һельсинкида 1969 елда Хөсәен Садыйк тарафыннан тупланган «Габдулла Тукай шигырьләре» (102 б.) басылды. «Милли байрак», «Яңа милли юл»да да Тукай хакында шигырьләр һәм мәкаләләр дөнья күрде.

Габдулла Тукай фикерләренең яңалыгы мәмләкәттә булган кебек, шөбһәсез, бик күп бәйләнешләр яшьләр арасында таралган. Истанбулдагы җәмгыятебезнең беренче төзелешендә «Тукай яшьлек клубы» исеме алуы моның бер мисалы. Яшьләр, бу исемне үзләренә алып, матди мөмкинчелекләре булмау сәбәпле, 1965 елның мартыннан 1968 елның июленә кадәр 24 сан «Тукай бюллетене» исемле кечкенә бер басма чыгаруга ирештеләр. Һәм һәр санында Тукай шигырьләренә урын бирелеп, исемен әсәрләре белән бергә яшәтергә теләделәр. Аеруча җәмгыять милли кичәләренә «Тукай бәйрәме» исеме биреп, һәр очракта Төркиядә аны танытуга шактый көч куелды. Әнкарада да 1965 елда кечкенә бер Тукай брошюрасы чыгарылды (әзерләүчеләр Г.Акыш, С.Арысланбәк, Н.Бинарк), һәм 1965 елның 22 маенда Наилә Бинарк язган «Тукайның тормышы» исемле әсәре «Казан культур һәм ярдәмләшмә җәмгыяте» тарафыннан сәхнәгә куелды. Төркиядән читтә дә Тукай өчен төрле җыелышлар һәм кечкенә җыентык басмалар ясалганлыгын беләбез, һәм хәтта Финляндиядә дә бер Тукай җәмгыятенең барлыгыннан хәбәребез бар.

Бөтен бу үрнәкләр Тукайның татарлар арасында никадәр мөһим роль уйнаганлыгын, яратылганлыгын, хөрмәтләнгәнлеген күрсәтүгә җитәрлек дәлилләр иде. Табигый ки, Тукай өчен ясалган бу эшчәнлекләр аның татарларга милли рух, яңа караш тәрбияләве өчен милләтнең танылганлыгының, хөрмәт хисләренең реакциясе буларак аңлатылды. Иҗтимагый яралары, гади кебек күренгән көнлек вакыйгалары, бәйсезлек тойгылары саф һәм җиңел аңлаешлы теле яхшы файдаланылганга күрә, Тукайны милләтенең йөзек кашы итте. Үз дәвере шагыйрьләреннән Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәми, Дәрдемәнд, Зариф Бәшири, Нәҗип Думави, Миргазиз Укмасый, Зыя Ярмәкиләрдән аерылып торуы, бәлки, халыкка тагын да якын, һәр сыйныфка, һәр яшькә мөрәҗәгать итүе өчен иде. Тукай — көн үткән саен күңелләребездә урнашачак, мисраглары зиһеннәребездә тагы куәтле яңгыраячак бер шагыйребез. Үзеннән соң һәрзаман танылачак, рухы шат булсын!

**Әхмәт Тимер**

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

*Үлеменә 60 ел тулу уңае белән*

Казанлы шагыйрь Габдулла Тукай 27 еллык кыска гомере эчендә әдәбият мәйданында бик күп әсәр иҗат итеп һәм, аерым Казан мохитендә генә түгел, башка төрк өлкәләрендә дә танылган бөек шагыйребездер. Аның хисле һәм милли шигырьләре халкының һәр сыйныфына йогынты иткән, яратылган һәм тәэсирен күрсәткәндер. Габдулла Тукай бу тирәлектә бигрәк тә яшьлек шагыйре буларак аерылып тора иде.

Габдулла Тукай хакында хәзергә кадәр бик күп хезмәтләр язылган, бик күп сүзләр сөйләнгән, әлбәттә, моннан соң да язылачак һәм сөйләнәчәктер, милли гореф-гадәтләрнең яшәеше аеруча бу елларда сакланадыр. Бу сылтау белән бигрәк тә туган һәм үлгән көннәрендә бөек кешеләребезне искә алу, аларның тормышларын һәм милләт өчен эшләнгән эшләрен сөйләтү безнең вазифаларыбыздан түгел.

Габдулла Тукайның 27 еллык тормышы хакында белгәннәребез шулардыр.

1886 елда туган Габдулла Тукайның 5 айлык бәби вакытында атасы һәм ике яшендә анасы да үлә. Моннан соң әнисе ягыннан әбисе тәрбиясендә кала, соңрак, кулдан-кулга йөреп, кабат бабасына кайтарыла. Кабат берничә ел кулдан-кулга йөргәннән соң, 1895 елда, 9 яшендә атасының кардәше янына Җаек шәһәренә китерерләр.

Габдулла Тукай, биредә иске ысул мәдрәсәдә укуын дәвам итеп, ул замана мәдрәсә гыйлемен тәхсил иткән. Мәдрәсәдә иң тырыш, зирәк укучы буларак танып. Мәдрәсә хуҗасы Мотыйгулла хәзрәткә килгән «Тәрҗеман», «Шәрекъ» һәм «Траблус» гәзитләрен да игътибар белән күзәтеп бара.

Бу вакытларда Мотыйгулла хәзрәтнең улы Камил Мотыйгый Мисырдан укып кайта. Габдулла Тукай аның белән якыннан бер дуслык корып, берсен берсе түйдыра-түйдыра күрешерләр, сөйләшерләр иде. Госманлы төрек һәм гарәп әдәбияты хакында куәтле белгән кеше һәм әйбәт тавышлы бер җырчы булган Камил Мотыйгыйдан Тукай күп файда алыр, аннан алып кайткан төрекчә һәм гарәпчә мәҗмуга һәм гәзитләрне укыр һәм аннан җырларын тыңлар.

Камил Мотыйгый 1905 елда «Фикер» гәзитен чыгара башлаганнан соң, Габдулла Тукай гәзит нәшриятында хәреф җыючы буларак эшли башлый, берникадәр вакыттан соң корректор була. Габдулла Тукай баштагы шигырьләрен бу заманнарда язгандыр.

«Фикер» гәзите ябылганнан соң, 1906 елдан аның ярдәмендә «Әлгасрелҗәдид» мәҗмугасы басыла башлый һәм Тукай да бу мәҗмуганың дәвамлы авторларыннан берсе була. Бу мәҗмуганың 12 санында тәртип белән аның 12 шигыре басылган. Габдулла Тукайның бу вакытка кадәр язган шигырьләре, гомумән, язганнары төрек теле тәэсирендә булып, яңа гына җирле Казан телендә язарга керешә.

Камил Мотыйгый өченче буларак «Уклар» исемендә бер юмористик мәҗмуга бастыра башлап, Габдулла Тукай биредә дә язышучы буларак күренә. Ул биредә сатирик шигырьләре белән шөһрәт казана. Күренә ки, ул заманнар мәҗмуга һәм гәзитләр кыска гомерле булган һәм берсе ябылып, башкалары басыла башлаган. Рус идарәсе вак бер сәбәп белән гәзит һәм мәҗмугаларны ябарга яисә туктатырга бик тырыша. Инде Габдулла Тукай бөтен Идел буенда танылган бер шагыйрь була. Оренбургта чыккан «Вакыт» гәзите үзеннән чакыру җибәрә. Иаширләр, ул вакытка кадәр чыккан шигырьләрен китап хәлендә хәзерләр өчен, Тукайдан аерым хокук сорыйлар.

Габдулла Тукай, 1907 елда 21 яшендә армиягә каралу эше сәбәпле, туган туфрагына кайта һәм бу вакытта берничә көн Казанга да килә. Хасталыгы йөзеннән күренгән Тукай армиядән азат ителеп, тәмам Казанда яшәргә кала.

Казанга килгәч, Габдулла Тукайның өстенә бөек бер тәэсир ташлаган, һәм ул бу очракны мәшһүр «Пар ат» шигыре белән мәңгеләштергән. Казан шәһәре ул заманнарда, бигрәк тә басмачылык эшендә, зур бер эшчәнлек күрсәтәдер. Габдулла Тукай бу шәһәрне дошманга каршы дастанлашкан (кала) булуын хәтерләр һәм милләтнең киләчәктә бу мәркәздән ниләр өмет иткәнен белгертер.

Казанга килгәч, китап хәлендә басылмакта булган шигырь мәҗмугасының корректуралары белән төзәтер һәм яшьләрнең мәдрәсә шәкертләре гәзите булган «Әл-ислах»та эшләр. Фәкать тормыш авырлыгы нәтиҗәсендә акча табу өчен төрле китап ширкәтләрендә китаплар күбәйтеп таратуны да эш итеп алыр.

1908 елда Галиәсгар Камалның «Яшен» исемле юмористик мәҗмугасы чыга башлау белән, 1908 елның башында Габдулла Тукай монда да катнаша. Ләкин бу мәҗмуга да тиз арада ябыла һәм аннан соң, 1910 елда, «Ялт-йолт» журналы чыга башлый₀. Габдулла Тукай тормышының ахырына кадәр бу мәҗмугада һәм 1912 елда Казанда басыла башлаган «Кояш» гәзитендә эшләп килә. Моннан башка җитди шигырьләре «Вакыт» гәзите белән «Шура» һәм «Аң» мәҗмугаларында дөнья күрә.

Авылда юксыллык эчендә үскән Габдулла Тукай Казанга бөек өметләр белән килгән, тормышының соңына кадәр фәкыйрьлектән котыла алмаган. Бу йөздән башка төрк өлкәләренә сәяхәт итүдән һәм шактый мәдәни уңышларыннан да мәхрүм калгандыр. Бу тормыш аның сәламәтлеген дә какшаткан һәм туберкулез хасталыгы акрын-акрын үлемгә алып килгән. 1912 елда иптәшләренең ярдәме белән Троицк шәһәренә дәвалану өчен кымыз эчәргә китә. Фәкать бер тапкыр махсус кылынган бу башлангыч бик файдалы була, ләкин шуңа карамастан бер елдан соң, 1913 елның 15 апрелендә, 27 яшендә әлеге тормыштан күзләрен йомган.

Габдулла Тукай Казан өлкәсенең идеалын җырлаган идеолог бер шагыйрь иде. Ул шигырьләре белән миллиятчелек фикерен ачык бер системада бирергә тырышты. Казан өлкәсеннән аның кадәр дини һәм милли тойгыларны заманча калыпка керткән һәм гүзәлләштереп халыкка җиткерә алучы юктыр. Аннан соң корылган милли көрәш һәм пассив каршылыкларның куәтләшүендә Тукайның тәэсире зур булган. Иң башта аның шигырьләре арадашчылыгы белән иң кечкенә авыллар һәм мәктәп почмакларында милли һәм дини тойгылар ялганып, балаларның күңелләрен актаргандыр.

Идея, хис һәм әдәби күзлектән тикшергәндә, Габдулла Тукайда шул гүзәллекне күрергә мөмкин:

— Тукай Казан өлкәсенең иң куәтле романтик-лирик шагыйредер. Ул бу юнәлешләрдә классик бер шагыйрьдер. Аңлашылганча, лирик шигырьдә күз уңында тотылган төп принцип — самимилекнең гүзәллеге, бу исә Тукайда тулы мәгънәсендә яшидер.

— Тукайның бөтен шигырьләрендә аның шәхси язмышы, ягъни Тукайлыгы ачык бер шәкелдә күренеп тора. Әдәбиятта романтизм агымының төп кагыйдәләренең бере дә будыр.

— Габдулла Тукайның тел өслүбендә аһәң, вәзен һәм кафия кору ясалма түгел, бәлки рухтан һәм күңелдән килгән бер хосусият күрсәтүдәдер.

— Тукайның хыялы да фикере һәм хисе кебек бай һәм хәрәкәтледер. Ул тиз арада тойган нечкә хисле бер шагыйрьдер. Тукайның яшьлегендә кычкырып көлүендә дә күз яше бар, ярсуында мәрхәмәт, ләгънәтендә шәфкать бар.

— Тукай һәрнәрсәдән элек бер хис шагыйре булганы өчен ул фикер җәһәтеннән дә куәтледер. Башка мәшһүр шагыйребездән Дәрдемәнд белән Тукайны бу юнәлешләрдә капма-каршы куйсак та, шуның белән аңлатылыр: Дәрдемәндтә фикерләр хис белән бизәлгән, Тукайда хисләр фикерләр белән бизәлгәндер.

— Тукай Идел буе әдәбиятында һәрхәлдә беренче буларак юмор-сатира шигырьләренең ишеген ача һәм бу юлда күп кенә матур үрнәкләр биреп калдыра.

— Тукай, халык әдәбиятыннан һәм чит телләрдән дә файдаланып, балалар, мәктәп һәм уку китаплары өчен дә тел һәм тасвир күзлегеннән бик күп матур шигырьләр калдыра. Шуның белән беренче мәктәпләрнең үсеп китүендә аның роле зур булган. Балалар һәм мәктәп өчен язылганнары һәммәсе дә диярлек милли һәм дини шигырьләрдер.

Сүзләремнән соң мәгълүм мәрхүм хуҗабыз профессор Рәшит Рәхмәти Аратның Тукайның һәм халкыбызның кадеренә ишарәт иткән кайбер җөмләләрен кабат искә төшерәм: «Габдулла Тукай ата-ана белән бала арасында булган табигый бәйләнеш янында, өлкәннәр һәм яшьләр арасында да асыл формада тәрбиягә бәйләнешләрне куәтләндергән һәм һәр ике төркемнең дә яхшы һәм начар тарафларын ачык һәм кыска бер стильдә белдерә. Шуның белән Габдулла Тукай үзен мәктәп программаларына кертелү белән генә чикләнеп калмый, нигездә, көнлек тормышын тәртипкә китерер өчен дә катыша һәм, шигырьләрен, асылда, бәет формасында яза һәм шигырь юллары бик иртә афоризм хәлендә мәкальләр арасында урын алганнар. Габдулла Тукай әсәрләре җыентык буларак яки аерым кисәкләр хәлендә мәмләкәтенең эчендә һәм тышында кабат-кабат басылып килә һәм һәр төрк эчендә бу әсәрләрнең булуының сәбәбе — менә шул хосусиятедер.

Тукай — үксез калган бер халыкның үксез яшәгән бер шагыйре. Араларында иң мөһим охшашлык — икесенең дә үз язмышларына хаким була белгән өчен бертуктамыйча эшчәнлеге, тышкы ягыннан теләсә нинди бер ярдәм алуның ихтималы булмаганыннан үзе һәм бер үзенә ышанычыннандыр»...

**Хөсәен Габдүш**

## НИДӘН МИН КЕЧКЕНӘ «АПУШ»ТАН БӨЕК «ТУКАЙ» БУЛДЫМ?

Балалык вакыты ятимлек, яшьлек еллары — үксезлек, бөтен гомере бишектән ләхетенә кадәр бәхетсезлек юлы...

Авырлыкта, яртысыннан күбесе черек үпкә авыруында үткән. Без җитешмәгән кебек менә шул күңел тартышуының ачы хакыйкать каршысындабыз. Гаяз Исхакый «Мөгаллимә»сендәге Фатыйманың сүзләре белән әйтсәк: «Хәтерегезгә китерегез! Яшьтән дөнья куйган Габдулла Тукай теләсә нинди бер татар кызыннан татлы бер сүз, елмаю, бер йөз күрмәгән шул татар шагыйренең хәлен, трагедиясен төшенәсең!»

Нечкә күңелле шагыйрь өчен моннан да ачы бер хәл булырмы икән? Дөнья әдәбияты тарихы гомерләрен фәкыйрьлек, ачлык, сагыш белән кичергән күп шагыйрьләрне белә. Әмма күргән һәр хатыннан качкан «яшерен газап», «яшерен ялкын» фаҗигасен чигү кемнең башына килде? Байрон, Лермонтов, Пушкинныкына, кемнекенә? Аның (Тукайның. — *Х.Габдүш искәрмәсе. — З.М.*) безгә үз каләменнән калдырган «Хәтеремдә калганнар»ында һәрбер сүзе менә ул үксезлек чишмәсеннән тамган күз яшедер. Шагыйрьнең лирик шигырьләренең таҗы булган «Җимерелгән өмет»ендәге җылы шигырь юллары әнисенә багышланган:

Һәр* күңелдән кайнар, йомшак синең кабрең ташы, —
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы вә татлысы.

*(«Өзелгән өмид»)*

Тарихчыларыбыздан Г.Батталның (Таймас) «Казан төркләре» исемле кыйммәтле әсәреннән шагыйребез хакында Аурупа матбугатында чыккан бер мәкаләдән алынган сүзләре белән әйтсәк, «Тукайның язмышы үз халкының язмышы белән бер иде».

Тирәннән килгән «авыру» бер аваз, милли татар авазы «күп тарихлардан аккан» Иделнең агымына кушылып агып, Урал тавы итәкләренә бәйләнеп, ниһаять, Себер һәм казак далаларына барып тарала башлады.

«Ишетте, хәйран булып тыңлап торды» бу моңсу тавышны бөек Кушлавыч ятиме.

Тирәндә торды-торды да үзенең сынык, ятим һәм «анасының соң тапкыр үзен үпкәннән бирле мәхәббәт сакчысының һәр ишектән куганы» хәлдә бар күңеленнән килгән моңсу аваз ялкынландырырлык көч белән безнең өч йөз ел буена ничек изелгәнлегебезне сөйләп бирде.

Олы һәм кечеләребез, яшүсмер һәм яшьләребез — һәммәсенең дә аңлаячагы шәкелдә садә, фәкать оста бер телдә аңлатып бирде.

Халык җырчысы — мәкальләр һәм табышмаклар кебек бер ишетелү белән хәтердән чыкмаган сүзләр һәм шигырьләр бөтен гүзәллеге, байлыгы белән хәтердә калырлар.

Тукайның шигырьләрендә беренче тапкыр «ана телебезнең» матур музыкасы колакларыбызны назлап сыйпады. Кыеклатып әйтсә дә, ул өйдән өйгә әледән-әле сәяхәт итеп йөрүче ятим бер авыл баласы,

ялгыз «кечкенә бер Апуш» буларак калмады. Татар халкының онытылмас җәдитчесе (яңалык тарафдары. *— Х.Габдүш искәрмәсе. — З.М.*) Габдулла Мөхәммәдгариф улы «бөек Тукай» булды.

**Надир Дәүләт**

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ШИГЫРЬЛӘРЕННӘН ҮРНӘКЛӘР

Габдулла Тукай Казан төркләре үстергән иң танылган һәм яратылган шагыйрьдер. Яшьләр, картлар һәм балаларны кызыксындырган бик күп шигырьләр язган, халкын шигырьләре белән тәрбияләргә өлеш керткән, яшьлеге һич бетмәгән. Биредә беренче буларак аның шагыйрьлек рухын белдергән бер шигырен тәкъдим итәм.

ШАГЫЙРЬ

Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,
Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да, —
Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас;
Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас.

Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?!
Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны;
Күңлемдә көн һаман аяз — һаман да яз:
Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый.

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик, юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,
Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә;
«Без китәрбез, сез каласыз!» — дип җырлармын,
Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.

Икенче буларак тәкъдим ителәчәк шигырьдә шагыйрьнең тормышыннан ачы тарафлары һәм өметсезлеге никадәр гүзәл эшләнгәнлеге һәм аның шагыйрьлек көчен тагын бер кат күрсәтә.

ӨЗЕЛГӘН ӨМИД

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар төсе;
Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урынында анда тулган айның яктысы.

Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җуләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.

И мөкаддәс моңлы сазым! уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,

Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,
Барсы корган — бер генә юк җанлысы, яфраклысы.

Булмадың, алтын ярым — салкын ярым, син дә минем
Бер тәбәссем берлә дә тормыш юлым яктырткычы!

Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, —
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Карттан сораганнар: «Муеның ни өчен юан?» — «Үз эшемне үземнән күрермен», — дигән. Чираттагы шигырьдә дә гүя югарыдагы сүзләр тәңгәл килә. Кыйммәтле шагыйребез бу шигыре белән безне кешенең тормышта ялгыз үз-үзенә ярдәмче булачагын белдерткән һәм гүзәл бер стиль белән безгә тапшыргандыр.

КЕМНӘН ЯРДӘМ ЭЗЛӘРГӘ?

*(Майковтан тәрҗемә)*

Миңа дустлар, танышлар һәм белешләр
Хисапсыз бирделәр яхшы киңәшләр.

Диделәр: «Без сиңа ярдәм итәрбез,
Бераз сабрит, мәдәткә без җитәрбез!»

Диделәр: «Куркъма син һич без барында,
Кирәк чакта төгәлләрбез барын да!»

Ышанмаслык түгел бит,— яхшы сүзләр;
Бирә тәмле өмидләр, — якты йөзләр.

Ышандым, иҗтиһадны ташладым мин,
Һаман уйнап көләргә башладым мин.

Һәнүз көтмәктә мин,— эшсез ятамын;
Һаман да юкны бушка бушатамын.

Көтәм, ярдәмгә һичбер кемсә килми;
Ахырда калдым ачка көчкә үлми.

Шулай да чыкты бер ихсанлы мөэмин,
Минем гомремне, рәхмәт, итте тәэмин.

Миңа һәр көн бирә ул аш вә нани,
Вә миннәт итми, һич юк имтинани.

Телим аны кочакларга, үбәргә,
Аңа рәхмәт укып, яшьләр түгәргә,
Кочакларга аны шул гайре мөмкин;
Ул ихсанлы кеше кем? — Улмы? Ул — мин.

Бала беренче күзен ачканда, бу дөньяда шагыйрьнең матур бер бишек җырын анасыннан ишетәдер.

БИШЕК ҖЫРЫ

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

«Агач яшь икән — бөгелер», «Үзем үземә карарга теләдем» мәкальләре никадәр урынында сөйләнгән матур сүзләрдер. Шагыйрьнең дә иптәш сайлаганда максатка ярашлы һәм яхшы иптәш янында көтүләрең дә файдалы мөмкинлекләре әйтелгән шигыре.

ИССЕЗ ЧӘЧӘК

*(Русчадан)*

Болынлыкта үсә гади генә, иссез чәчәк, яңлыш
Гүзәл исле чәчәкләр бәйләменә бергә бәйләнмеш.

Ярар, бәйләнгән ул анда, соңыннан нәрсә булган соң? —
Булып киткән үзе хуш исле бик аз бер заманнан соң.

Шуның күк, безне тәүфикълы дуст-ишләр һәм белешләр дә
Өйрәтерләр гүзәл гадәткә һәм дә изге эшләргә.

Бөек шагыйрь мәдәниятнең фән һәм укыту белән сакланачагын һәм наданлыкка да тәрбия белән юл калдырылмаячагын язган иде. Балаларны укырга-язарга үгетләгән бер шигыре шулдыр.

АТА ИЛӘ БАЛА

*(Кара такта янында)*

Яз, газиз угълым: кара тактаны сыз акбур белән!
Һәм кара күңлеңне ялт иттер сызып ак нур белән!

Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше;
Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич кеше булган кеше.

Балаларны милләткә файдалы булып үсүләрен теләгәнлеге, һич шөбһәсез, Тукайның милләтен тирән яратуы белән ачыкланадыр:

БӘХЕТЛЕ БАЛА

Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә,
Мөгаллимне олугъ күрсә, белергә кушканын белсә.

Сабакка калмаса соңга, борылмый барса уң-сулга,
Уенга салмаса ихлас — менә бәхте аның шунда.

Кечеләргә итеп шәфкать, үзеннән зурга юл бирсә,
Бәхетсезләрне кимсетми, егылганнарга кул бирсә!

Габдулла Тукайның мәктәп баласы өчен беренче тойгысын тәшкил иткән һәм бала күңелен сафландырган Аллаһыга инануны теләп язган бик матур бер шигыре шулдыр:

САБЫЙГА

Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз — аларның булганы юктыр гомер.

Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле — шагыйранә ялган ул,

Һич өрәк, албасты булган сахралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк.

Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

Газиз шагыйрьне мәмләкәтебездә әле һаман Казан шивәсеннән тәрҗемә ителгән басмасын күпләп бастыру мөмкин түгелдер. Төрле мәҗмугаларда аның турында языла һәм шигырьләреннән үрнәкләр бирелә. Шөбһәсез, 1905–1913 елларына бәйле бу шигырьләрне Төркия төрекчәсенә әйләндерү бик файдалы булачагы аңлашылса кирәк.
Газиз шагыйребезнең рухы шат булсын, Олы Тәңредән шуны сорыйбыз!

**Шәмсия Апакай**

## МИН КАЗАНДА

Миндә күптәннән бер ял вакытында Казанга бару теләге бар иде. Ниһаять, бу теләгем тормышка ашты. 1975 елның август ае. Мин Казандамын! И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!
Мин беренче тапкыр татарларның мәдәният, әдәбият, сәнгать мәркәзе булган шәһәрдәмен. Казанга кич белән килеп җиттем. Туганнарым Апакайлардан берсенең өендә кунак булдым. Иртә белән иртүк бер урыннан килгән тәэсирле бер татар җырының яңгырашы уяныргa мәҗбүр итте. Бу Казан радиосыннан яңгыраган музыка иде. Казан радиосы көндәлек программаны ярым сәгатьлек татар музыкасы белән башла-

ганын соңрак туганнарым аңлаттылар. Бүлмәм тәрәзәсе почмагыннан йортлар, агачлар арасыннан иң әүвәлдә Сөембикә манарасы күземә күренде. Минем бүлмәм тәрәзәсе нәкъ шул манарага карап тора. Манараны рәсемнәрдән күреп таныдым. Асылын күреп бик дулкынландым, чынлап та Казанда булганымны аңлап сөендем.

Туганнарым белән булган сөйләшүләремнең берендә мәшһүр шагыйрь, бала-чагыбыздан күңелебездә урын алган Габдулла Тукай белән бәйле җирләрне күрергә теләгәнемне сөйләдем. Туганнарым бу теләгемне хуп каршыладылар.

Бу ел сөекле шагыйребезгә 90 яшь тулу мөнәсәбәте белән Казандагы тәэсирләремне сезнең белән уртаклашырга уйлыйм.

Мин Казанда Габдулла Тукай исемендә бик күп урын булмавына гаҗәпләндем. Киров урамыннан үтәбез. Монда Тукайның Уральскидан (Җаек) кайтканнан соң яшәгән «Болгар» һәм «Сарай» кунакханәләре бар. Инде дә аның формаларын саклыйлар. Бу биналарга хатирә такталары куйганнар.

Опера театры янында (Ирек мәйданында) һәм Казанның Үзәк мәйданында шагыйрь гүя үзе аякта торган кебек күренде миңа.

Бер җомга көнне без Каюм Насыйри урамыннан мәчеткә киттек. Халык әле һаман җомга намазына җыела иде. Мәчеттәге картлар белән очрашып, яшь имам белән күрештек. Бохарада җиде ел укыган, якында ике елга Каһирәнең Әл-Әзһәренә китәчәк икән. Мәчеттән туп-туры татар зиратына — Тукай каберенә юнәлдек. Мин аның кабере янында бик дулкынландым. Сөекле шагыйрьгә булган тирән хөрмәтемне аның каберенә тезләнеп укыган догаларым белән белдердем. Шагыйрьнең кабере чиста, тимер рәшәткә белән әйләндерелгән, гөл һәм чәчәкләр белән бизәлгән, баш очындагы мәрмәренә:

И мөкаддәс моңлы сазым,
Уйнадың син ник бик аз... —

дигән шигырь юллары язылган.

Каберлектән кайтканда, Казанның зур, матур урамнарының берсеннән үттек. Бу — Тукай урамы. Урам башында да аның исеменә багышланган кинотеатр игътибарымны җәлеп итте.

Тукай-Кырлай авылына килүем минем өчен тагын да зур бер истәлекле вакыйга булды. Ул көн аеруча матур бер көн булып, кояш та көлемсерәп карый иде, һава саф, күңелебез сөенечле булды. Баштан ук килешүебезчә, кечкенә бер автобуска утырып юлга чыктык. Күп тә үтмәдек, район үзәге Арчага җиттек. Аннан Тукай-Кырлай ерак түгел икән. Киң кырлар, болыннар һәм урманнар яныннан асфальтланган озын юл. Юлның ике тарафында каен һәм акация агачлары тезелгән. Кырлайга кергәндә, башта күрсәтү тактасы бар. Рәт-рәт тезелгән каен урманы уртасына салынган юл безне авылга алып килде.

Иң әүвәл кечкенә Апушны (Габдулла) үз яклавына алган Сәгъди агасының өенә киттек. Ул авыл уртасында. Өй ишеген ачкач, өйалдына, соңрак өйнең эченә үттек. Кечерәк бер авыл өе. Бу өй тарих сәхифәсенә кергән мөһим бина хәзер. Габдулла яшәгән дәвердәге өй әйберләренә, киемнәре, тәрәзә кырыендагы гөлләргә карап хәйран булдым. Авыл халкы өенә тиеш булган әйберләр табылган, китерелгән. Анда ни генә юк: он иләге, киле, чабата ясаганда кулланылган шөшле (бер төр нечкә тимер кисәге), табак-савыт һәм башка бик күп әйберләр, гүя һәммәсе үткән заманнан, Тукайның балалык дәвереннән килгәннәр һәм безгә күп нәрсәләр аңлатырга теләгән кебек хисап бирәләр. Кырлайда яшәүчеләр авылларында зур бер плотина ясаганнар, аның тирә-юненә төрле агачлар утыртканнар, парк ясаганнар. Моннан ерак та түгел Тукай музее.

Музейда шагыйрьнең тормышы, әсәрләре белән бәйләнешле күптөрле кызыклы бай материал тупланган.

Монда Тукай абзасының кызы (ата бер, ана башка) Газизәнең шәхси әйберләре. Тукай әсәрләренең төп нөсхәләре, аның дәверендә чыккан, шагыйрь язышкан гәзит һәм мәҗмугаларының күптөрле саннары, Татарстан рәссамнарының рәсемнәре һәм башка бик күп төрле материаллар тупланган. Тукайның каләмдәшләре, замандашлары белән очраштым мин бу залда. Музейга килгән кешеләр өчен хосусый хатирә дәфтәре бар. Мин дә бу дәфтәргә: «Тукай музеенда халкыбыз өчен бик кыйммәтле бай материаллар күрдем. Боларны күрүем белән үземне бәхетле кешеләрдән саныймын. Америкадан килгән татар ханымы Шәмсия Апакай. Август 23, 1973» диеп, гарәп хәрефләре белән яздым.

Яңа Кырлай авылында яңа биналар калкып чыккан. Бик матур итеп төзелгән мәдәният йортын да карадык. Моннан ерак түгел өч катлы мәктәп салынган.

Менә инде Казанга кайту өчен юлга кузгалдык. Юлдан җәяү кайтабыз. Мин каен агачларына тартылам, йомшак үләннәргә карап тынычланам кебекмен, бу җирләргә йөземне куярга, үләннәр арасыннан сөекле шагыйребез яланаяк чабып йөргән җирләрендә эзләрен күрергә теләдем... Үләннәр арасында аның аяк эзләрен күрмәсәм дә, бөек шагыйрьнең хатирәсе, хезмәте һәм исеменең халкы күңелендә чиксезлеккә кадәр сакланачагына инандым.

Менә шунда М.Фәйзинең Габдулла Тукайга багышлап язган бер шигыре хәтеремә килде:

Рух бирдең син, халкымны терелттең,
Бөек җанын сачты котлы нур.
Рәхәт булсын җаның, рухта исемең
Ихтирам сезгә таудан бөек.

**Надир Дәүләт**

## ТАТАР ДИАСПОРАСЫ ҺӘМ ТУКАЙ

Бай тарихка ия булуларына карамастан, татарларның соңгы йөз елда, аеруча совет чорында, үзләренең үткәннәре белән бәйләнешләре шактый йомшарды. Режим мөмкинлек биргән кадәр милли гореф-гадәтләрен, әдәбиятларын һәм тарихларын өйрәнгән, тикшергән һәм яшь буынга җиткерергә тырышкан татарлар һәм алар хәлендә калган башка милләтләр, этник җыелмалар, үз-үзләрен саклап калыр өчен бик еш кына бер төркем символлар кулланырга мәҗбүр булдылар. Бәйсезлек алганнан соң кыргызларның «Манас» дастанына, үзбәкләрнең (әмир) Тимергә, казакъларның Абай Кунанбаевка, башкортларның профессор Зәки Вәлиди-Туганга, төрекмәннәрнең Мәхтүм Колыйга һ.б. сарылып, бу шәхес һәм дастаннарны гадәттән тыш идеаллаштырулары, алар белән бәйле юбилейларны милли бәйрәм дәрәҗәсенә җиткереп үткәрүләре, алар исемендәге премияләр оештырулары, һәйкәлләр куюлары, асылда, шул — милләтнең аерымлык билгесе булган милли символларга ихтыяҗлары белән аңлатыла ала. Милләт булып формалашу яки бәйсезлек алу чорында ул дәүләтнең яки милләтнең барлыгын күрсәткән байрак, гимн кебек заманча символлардан мәхрүм булган милләтләр исә үзләренә генә хас символларга таяналар. Бу күренеш аңлы рәвештә дә, аңсыз рәвештә дә яшәп килә.

Менә 444 елдан бирле рус хакимияте астында яшәгән һәм чит илләрдә, бигрәк тә Төркиядә «Казан төркләре», «Идел-Урал төркләре» кебек төрле-төрле исемнәр белән аталса да, үзен «татар» дип атап йөрткән төрки милләт үзенә генә бертөрле моң-сагыш белән үзенчәлекле символлар җыелмасы барлыкка китерде. Гәрчә 1992 елдан бирле Татарстан Җөмһүриятенең дәүләт символы буларак «канатлы ак барс» фигуралы тугра һәм яшел, ак, кызыл төсләрдән гыйбарәт булган байрак кулланыла башласа да, боларның халык тарафыннан тулысынча кабул ителүенә шактый озак вакыт кирәк булачак. Башка төрки җөмһүриятләрдәге кебек, Татарстанда да бу төр яңа рәсми милли символларны кабул итү «булды-бетте»гә әйләндерелде. Чынлыкта һәр татар өчен диярлек аңлаешлы милли символлар буларак, беренче урынны Казан Кремлендәге Сөембикә (Хан мәчете) тотса, икенче урында милли шагыйрь Габдулла Тукай (1886–1913) тора дип әйтергә була. 1988 елда башланган бәйсезлек өчен көрәштә «Тукай маршы (гимны)» буларак билгеле «Туган тел» исемле шигыре милли җыелышларда, Төркиядәге «Истикъләл маршы» кебек, аягүрә басып җырлану дәрәҗәсенә җитте. Хәтта ул вакытка кадәр бу шигырьнең тыелган соңгы дүрт юлының да аерым бер горурлык белән җырлануы, белмәгәннәргә өйрәтелүе, режимның күрсәткән золымына һәм кысуларына карата татар халкының бер протесты буларак та аңлашыла ала. Табигый ки, монда шул хакыйкатьне дә ассызыклау урынлы булыр: совет режимы милли шагыйрьне тыймады, киресенчә, аңа атап һәйкәлләр салуга, музейлар ачуга, премияләр бирүгә рөхсәт итте, ләкин аның «Васыятем», «Тәәссер», «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә» кебек дини мотивлы шигырьләрен яки «Туган тел» шигырендәге кебек аерым юлларны бастырмыйча, аларга карата цензура булдырды. Икенче төрле әйткәндә, режим татар халкы өчен сөекле улын тыймады да, әмма аның әлеге темага багышланган шигырьләрен үзе теләмәгән формада аңлашылуы өчен мөмкинлек тә бирмәде.

Диаспорадагы татарларга килгәндә исә, аларны якын һәм ерак диаспора дип икегә бүләргә мөмкин. Беренчесенә Татарстанның читендә элекке СССРның төрле җөмһүрият һәм өлкәләрендә яшәүчеләрне, икенчеләренә исә болардан кала чын мәгънәдәге чит илләрдә яшәүчеләрне кертергә була. Без хәзер тикшерергә теләгән тема — ерак диаспорадагы, ягъни 1950 елларга кадәр башлыча Кытайда, Япониядә, аннан соң Төркия, Финляндия, АКШ кебек дәүләтләрдә яшәгән аз сандагы татарлар һәм аларның Тукайны танып белүләре мәсьәләсе. Югарыда саналган дәүләтләр демократик яки советларга каршы позициядә торганга күрә, анда яшәүчеләр Тукайны үзләре теләгәнчә искә алу (яки искә алмау) ирегенә чын мәгънәсендә ия иде. Бу иректән файдаланып, алар, ниндидер режимның рөхсәт итүен яки итмәвен көтеп тормыйча, Тукайны һәр җәһәттән теләгән кадәр искә алып тордылар. Хәтта чит илләрдә җитешкән яшь нәсел, бәгъзан «татарларның башка шагыйрьләре әллә бер дә юкмы?» дип шөбһәләнеп тә карый башлады. Ватанны сагыну газабы тойган карт буын үз балаларына Тукай шигырьләре аша туган илгә мәхәббәт тәрбияләргә, аның шигъри юллары (мәсәлән, «Туган тел» шигыре) белән ана теленә игътибар уятырга тырышты.

Икенче сүз белән әйткәндә, Тукай милли телне, милли әдәбиятны, Ватан тойгысын, кыскасы, татарлыкның мәдәни кыйммәтләрен чагылдыручы бер исем булып торды.

Тукайның мондый көчкә ия булуын, бәлки, шул рәвешле аңлату дөрес булыр. Сәбәп аның шигырьләренең теле гаять гади, ягъни ана телен бөтен нечкәлекләре белән белмәгән, чит илләрдә, чит мохиттә туган кешеләр дә җиңел аңлый алырлык дәрәҗәдә садә булуында, әсәрләрендә күтәрелгән мәсьәләләрнең халык әкиятләреннән башлап иҗтимагый һәм милли проблемаларга кадәр киңәеп китүендә. Социаль яраларны, мәгънәсез кебек күренгән, ләкин турыдан-туры халыкны кызыксындырган көндәлек вакыйгаларны, азатлык тойгыларын чагылдыруы, кешенең туган теле, тарихы белән горурланырга тиешлеген саф һәм җиңел аңлаешлы телдә аңлатуы үз илендә дә, диаспорадагы татарлар арасында да Тукайны баш таҗы итте. Үз дәвере шагыйрьләре Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Зариф Бәшири, Нәҗип Думави, Укмасый, Зыя Ярмәкиләрдән аерылып торуының бер сәбәбе дә, бәлки, аның һәр иҗтимагый сыйныфка, һәр буынга атап, аерым дәшеп иҗат итүендәдер.

Менә бу үзенчәлекләре ерак диаспорадагы татарларның Г.Тукайны туган һәм үлгән көннәре туры килгән апрель аенда искә алулары өчен сәбәп булды. Кайда гына кечкенә булса да бер татар якташлыгы оешмасын, кайда гына мәдәни фәгалият (чара үткәрү) форсаты тумасын, анда Тукай кичәсе үткәрү традициягә әверелде. Бу милли кичәләрдә Тукайның тормыш юлы сөйләнгәннән соң, аның шигырьләреннән берничәсен үрнәк итеп китерү мәҗбүри. «Туган тел» яисә икенче исеме белән «Тукай маршы» хор белән җырлана. Гомумән, Тукай кичәсе булсын, башка милли кичәләр булсын, бу җырның җырланмый калуы бик сирәк була иде. Чөнки бу марш (гимн) азатлыктан мәхрүм татар халкының бәйсезлеккә омтылышы кебек тоела иде. Бу Тукай кичәләренә өстәмә рәвештә махсус китап-журналлар да нәшер ителә иде. Шул рәвешле диаспорада да Тукайның үлемсез калуы тәэмин ителә иде.

Башта ерак диаспорада яшәгән татарларның Тукайга мөнәсәбәтле эш-гамәлләренә күз салыйк. Иң әүвәл Япониядә Тукайның вафатына 20 ел тулу уңае белән басылган мөһим бер басмага тукталыйк. «Токио Матбага-и Исламия» 1933 елда, ягъни шагыйрь үлеменең 20 еллыгында Тукайның бөтен әсәрләрен эченә алган «Габдуллаһ Тукай. «Мәҗмугаи асаре» исеме белән 4 томлык бер җыентык бастырды. Барлыгы 543 битлек бу җыентык ул чакта татарлар тарафыннан кулланылган гарәп хәрефләре белән нәшер ителде. Бу мөһим юбилей мөнәсәбәте илә, Япониядә яшәгән бик аз санлы татар-башкортның искиткеч зур тырышлыгы белән мәйданга чыккан 4 томлы җыентыкны хәзерләү бер дә җиңел булмый. Моның шулай икәнен Токиода чыккан «Япон мөхбире» исемле журналда басылган язмадан да күрергә була. Япониядәге мөселманнарның дини лидеры ролен үтәгән Габделхәй Корбангалинең әлеге журналда басылган мәкаләсеннән һәм башка хәбәрләрдән Тукайның үлеменә 20 ел тулуны билгеләп үтү өчен зур күләмле чаралар үткәрелүе аңлашыла. Бер елдан соң исә Тукайның нибары бер шигыренең генә басылуын күрәбез.

Ерак Көнчыгышта Тукай белән бәйле, дөресрәге, аның үлеменең 25 еллыгын искә алу өчен басылган икенче бер әсәр исә 20 мәкалә һәм аңа багышланган шигырьләрне эченә алган 98 битле «Габдулла Тукай (1913–1938) (Вафатына 25 ел тулу белән)» исемле җыентык иде. Ул «Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татар мөселманлыгының дини-милли мәркәз мәгариф шәгъбәсе» тарафыннан 1938 елда Мукденда нәшер ителгән. Шул ук вакытта Мукденда 1935–1945 еллар арасында чыккан «Милли байрак» гәзите төрле уңайдан аның шигырьләреннән үрнәкләр биреп бара, Тукай хакында төрле мәкаләләр яки аңа багышланган шигырьләр бастыра. Исхакый мөхәррирлегендә чыккан (башта «Милли юл» буларак) «Яңа милли юл» исемле айлык журналда да Тукайга бик еш урын бирелә.

Ерак диаспорадагы татарларның икенче бер мәркәзе булган Финляндиядә шагыйрьне искә алу кичәләре үткәрелеп килсә дә, беренче басма эше 1953 елда Төрек халык мәктәп химая корумы тарафыннан Һельсинкида Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле әсәрен нәшер итү булды бугай. Һәм 1969 елда Хөсәен Садыйкның*о* «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле 102 битле җыентыгы шулай ук Һельсинкида, элек Кытай һәм Япониядә чыккан җыентыкларның латин хәрефләренә күчермәсе рәвешендә басылды.

Ерак диаспорадагы татарларның иң тыгыз утырган җире булган Төркиягә килгәндә, монда Тукай һәм Тукайны таныту буенча алып барылган эшләр түбәндәгечә. Төрк укучысы беренче тапкыр буларак Тукай исемен «Төрек йурду (йорты)» журналының 1913 елдагы «Габдуллаһ Тукаевның вафаты» исеме астында басылган хәбәрдән белде. Аннан соң журнал «Тукаевның җеназасы» хакында мәгълүмат бирде. Иң әһәмиятлесе, һичшиксез, Фуад Көпрүлүнең Тукай хакында язган мәкаләсе булды. Ләкин Фуад Көпрүлүнең күләмле мәкаләсендә «бары тик «Тасвир-и Әфкяр» белән «Ислам дөньясы»нда гына Тукаевка берничә колонка язма бирелде» дип хәбәр итүе ул вакытларда Төркиядә Габдулла Тукаевның әле танылмавына ишарә иде. «Төрек йурду» ул санында «Төркләрнең яшь халык шагыйре (Габдулла Тукаев) мәрхүм» дип язып, нәкъ бер битлек фотографиясен һәм румынияле Ногман Байбуриның аңа атап язган «Габдуллаһ Тукаев» исемле шигырен бастырды. Биш ел узганнан соң, «Кырым» журналында бик кечкенә генә бер мәкалә

чыкканын беләбез. Ягъни Көпрүлүдән соң Тукайга җитди игътибар күрсәткән кеше булмады. Монда шигырьләренең төрекчәгә тәрҗемә ителмәвенең дә йогынтысы булган, күрәсең. Озак вакытлардан соң җөмһүрият дәверендә яңадан чыга башлаган «Төрек йурду» 1926 елда «Габдуллаһ Тукай. «Мәҗмугаи асаре» дигән баш астында төрек укучысына Казанда аның сайланма әсәрләре басылуын хәбәр итсә дә (IV, № 20, август 1926, 189 б.), бу да тәэсирле булмады. Гаяз Исхакый 1933 елда (ягъни Тукайның 20 еллыгында) «Азәрбайҗан йорт билгесе» журналында Тукай турында тагын язып чыкса да, моның да әллә ни йогынтысы булмавы аңлашыла. Нәтиҗәдә төрек матбугатындагы бу бер-ике мәкаләдән соң ярты гасыр буена Тукай турында һичбер нәрсә басылмавын, тулы бер бушлык хөкем сөрүен күрәбез. Бары 50 елдан соң гына Тукайның үзләре татар нәселле булган тикшеренүче һәм галимнәр тарафыннан көндәлек тормышка кире кайтарылуына шаһит булабыз. Болар — тарихчы Габдуллаһ Баттал Таймас, профессор Рәшид Рәхмәти Арат, профессор Әхмәт Тимер иделәр. Алардан соң өч ел узгач, профессор Хәмзә Зөлфикар шул ук журналда «Габдулла Тукай (1886–1913)» исемле җитди гыйльми бер мәкалә бастырганын күрәбез.

Шул ук елларда, ягъни 1963 елда, Истанбулдагы татар-башкорт яшьләре «Тукай яшьлек клубы»н оештырганнар иде. Бу яшьләр оешмасы 1965 елның мартыннан башлап, 1968 елның сентябрь — ноябренә кадәр барлыгы 24 сан (һәр саны якынча 10–12 битлек) «Тукай бюллетене» чыгарды. Бу бюллетеньнең апрель 1965 ел (№ 2) санында профессор Әхмәт Тимернең «Габдулла Тукай» исемле (3–7 битләр) мәкаләсе басылды. Әлеге бюллетеньнең 4 саныннан алып иң соңгы санына кадәр (1965 елның ноябрь нөсхәсе «Рәшид Рәхмәти Арат хөрмәтенә махсус сан» булып чыкканны исәпкә алмаганда) Надир Дәүләт оештырган «Тукай почмагы»нда Габдулла Тукайның шигырьләреннән шактые татарча оригиналы һәм төрекчә тәрҗемәләре белән басылды.

Шул ук «Тукай бюллетене» 1966 елда Наилә Бинарк тарафыннан иҗат ителгән «Тукайның хәяты» исемле балалар өчен дүрт пәрдәле пьесаны 16–19 саннарында бастырды. Соңрак бу спектакль Әнкарада сәхнәгә дә куелды. Шул араларда Гали Акыш, Сәгыйдә Арысланбәк, Наилә Бинарк тарафыннан хәзерләнгән «Тукай брошюрасы» дигән 8 битлек бер хезмәт дөньяга килде. Бу брошюрада Арысланбәк һәм Бинаркның «Габдулла Тукай», шул ук кешеләр тәрҗемәсендә Тукайның «Туган тел», «Гомер юлына керүчеләргә», «Таз» шигырьләре, Гали Акышның «Бөек төрк-татар шагыйре Габдуллаһ Тукайның халыкчылык вә милләтчелек җәбһәләре» исемле мәкаләсе урнаштырылган иде. Бу нәшрият эшләреннән тыш, «Тукай яшьлек клубы» тарафыннан 1964, 1965, 1966 һәм 1967 елларның апрель аенда «Тукай бәйрәме» дип аталган милли кичәләр оештырылды. Бу милли кичәләрдә, Тукайны искә алу белән бергә, аның шигырьләре укыла, кечкенә спектакльләр күрсәтелә һәм фольклор уеннары уйнала торган иде. 1967 елгы «Тукай бәйрәме»нең башка еллардагыдан аермасы Гаяз Исхакыйның (Иделле) «Җан Баевич» исемле 4 пәрдәлек зур пьесасын Истанбулдагы Чагалоглуда Милли төрек студентлар берлеге сәхнәсендә куюу булды. Бераз соңрак (28 октябрь, 1967 ел) Тукай бәйрәмнәре «Казан төркләре шәнлиги (шатлыгы)» исеме астында дәвам иттерелде. Ләкин бу әле Тукайның онытылмавын тәэмин итә дигән сүз түгел. Чөнки 1968 елда «Тукай яшьлек клубы» яшьлек срогын тутырып, «Казан төркләре культура (мәдәни) һәм ярдәмләшмә җәмгыяте»нә әйләнгәч, мәрхүм Әхмәт Вәли Мәңгәрнең матди булышлыгы белән өч айга бер мәртәбә «Казан» журналы чыгарыла башлады. Бу журнал да Тукайны укучыларга таныту эшеннән ваз кичмәде һәм «Тукай бюллетене»нә караганда да киң күләм укучыларга таралганга күрә, тагын да үтемлерәк булды. «Казан» журналы беренче санында ук Надир Дәүләт тәрҗемәсендәге Тукайның «Сак-Сок бәете» исемле әсәрен бастырып чыгарды. Тукайның тууына 85 елга туры килгән өченче санында исә (март, 1971) «Казан» үз сәхифәләренең күп өлешен Тукайга багышлады.

Татарлар Тукайны һәртөрле уңайдан искә алырга тырышканга күрә, «Казан» журналы да Габдулла Тукайның үлеменә 60 ел тулу уңаеннан 10 нчы санын (1973) тулысы белән аңа багышлады.

Моннан соң да «Казан» журналының 11 нче санында (1974) «Таз», «Теләнче», «Нәсыйхәт», 12 нче санында (1974) «Мөхәрриргә», 14 нче санында (1975) «Театр», 17 нче санында (1976) «Су анасы» белән «Кадер кич» шигырьләренең Наилә Бинарк тәрҗемәсендә нәшер ителүен күрәбез. 17 нче санда шул ук вакытта Сания Ишыкайның шагыйрьгә атап язган «Габдуллаһ Тукайның 90 еллыгы» исемле шигыре дә урнаштырыла. Аннан кала 18 нче санда (1976) Нәркиз Деуш-Гиелингның «Тукайга хөрмәтләр белән» һәм 22 нче санда (1978) Минһаҗның «Даһи Тукайны искә алу» дигән шигырьләре бирелә.

Ләкин 1978 елның 10 ноябрендә журналны матди яктан яшәткән Әхмәт Вәли Мәңгәрнең вафат булуы «Казан» журналының басма хәятына чик куелуга, 1980 елның 12 октябрендәге хәрби переворот исә Истанбулдагы «Казан төркләре культура һәм ярдәмләшмә җәмгыяте»нең ябылуына сәбәп булды. Бу үзгәрешләр Тукайны төрк җәмәгатьчелегенә таныту эшен тагын да кыенлаштырды һәм бу вазифаны чикләнгән мөмкинлекләргә ия булган аерым шәхесләр үз өсләренә алырга мәҗбүр булдылар.

Төркиядән читтәге төрки милләтләрнең әдәбиятларына төрле сәбәпләр аркасында игътибарның артык зур булмавына карамастан, әлеге вазифаны, мөмкинлекләре чикле булса да, фидакарь рәвештә үз өс-

тенә алган «Кардәш әдәбиятлар» журналы 1982 елда Тукай исемен яңадан төрк укучысына җиткерә. Дүрт елдан соң, 1986 елда, ягъни Тукайның тууына 100 ел тулганда исә, бу юллар авторының шагыйрьне халыкка таныткан бер төркем мәкаләләре басылып чыга.

Югарыда күрсәтелгән журналларда чыккан мәкаләләрдән тыш, «Кардәш әдәбиятлар» журналының да 16 нчы санын (1987) Тукайга багышлау татар шагыйренең тагын да киңрәк территориядә танылу билгесе булды.

Тукайның 100 еллык юбилеен шулай билгеләп үтәргә тырышканнан соң, 1988 елда Гали Акышның «Төрек йурду» журналында басылган Тукайны хәтерләргә төшерү фикере белән язылган бик кыска (бер битлек) кечкенә мәкаләсеннән башка, 3–4 ел буена бернинди дә җитди хезмәт чыкканы күренми. Тукайның 100 еллыгына хәзерләнеп тә, университетларның матди мөмкинлекләре булмавы аркасында үз вакытында басылмый калган ике гыйльми эш бары тик 1991 һәм 1993 елларда тар аудитория укучыга барып ирешә. (М.Өнәр һәм Н.Дәүләт хезмәтләре.)

Төркиядә Габдулла Тукай белән бәйле иң зур алга китеш, һич шөбһәсез, Фатма Өзканның кандидатлык диссертациясе (докторлык тезисы) булды. Шул рәвешле, Фуад Көпрүлү, Хәмзә Зөлфикар, Мостафа Өнәрдән соң һәм татар нәселеннән чыкмаган төрек галиме Тукай темасына академик хезмәт яза һәм Төркиянең мәдәни тормышына, «Гомуми төрек әдәбияты»на гаять әһәмиятле өлеш кертә. Әлеге диссертациянең төрек мәдәниятен өйрәнү институты тарафыннан «Габдулла Тукайның шигырьләре. Анализ. Текст. Тәрҗемә» (Әнкара, 1994) исеме белән басылып чыгуы исә аның тагын да киңрәк күләм укучы тарафыннан танылуына сәбәпче була. Бу — бөек казаныш буларак хисапланырга хаклы күренеш. Мостафа Акбаш тарафыннан язылган «Татар шагыйре вә язучысы Габдуллаһ Тукайның әсәрләреннән сәчмәләр (сайланма әсәрләр) вә алардагы тел үзенчәлекләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклау өчен Истанбул университеты Иҗтимагый фәннәр институтының иске төрек теле бүлегенә тапшырылуын да ишеттек.

1991 елда, ике арадагы «тимер пәрдә» юкка чыгып, нибары биш ел вакыт узганнан соң, Төркиядә ике кандидатлык диссертациясе язылу — гаять зур алга китеш. Бу төр академик хезмәтләр белән Төркиядән читтәге төрле төрки кавемнәрнең (халыкларның) әдәбиятларын да фәнни юнәлештә өйрәнү һәм бәяләү мөмкинлеге ачылды. Табигый ки, Төркиядәге бу үсешкә 1991 елда Советлар Берлегенең таркалуы һәм төрк дөньясының яңадан берләшә башлавының зур йогынтысы булды. Аеруча Төркиядә яшәгән һәм, нигездә, артык вәкаләтләре булмаган шәхесләр үз нәсел-нәсәпләре белән бәйле мәгълүматларны эзләргә тырышулары тиешле нәтиҗәне бирмәгәнен дә искә алсак, университетларыбыздагы яшь галимнәребезнең, академикларыбызның һәм иркле (шәхси) тикшеренүчеләрнең мондый темаларга алынулары кардәш халыклар белән элемтәләребезнең ныгуына уңай йогынты ясаячак дип өметләнергә кирәк.

Соңгы елларда яшь галимнәребез арасында Тукай исеме тагын да көчлерәк ишетелә башлады. «Кардәш әдәбиятлар» журналы 1994 елда (28 нче сан) Мостафа Өнәр тәрҗемәсендә Әмди Гәрәйбәйнең «Тукайга» исемле шигырен һәм 1995 елда (32 нче сан) доктор Фатма Өзкан тәрҗемә иткән Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрен бастырып чыгарды. «Төрек культурасы» журналы исә быелгы 395 нче санында (март 1996) Тукайның тууына 100 ел тулу уңае белән тагын Фатма Өзканның «Гомеренең язында вафат иткән бөек бер шагыйрь: Габдуллаһ Тукай» исемле мәкаләсен бастырды.

Кыскасы, үз илендә бик мәшһүр булган татар халык шагыйре Габдулла Тукай әкрен-әкрен Төркиядә дә танылa башлады. Бу исә тугандаш халыкларның якынлыгы аеруча мәдәни чаралар ярдәмендә артачагына инанган безләр өчен бик зур сөенеч. Бу хәлдә Тукай, бары ерак диаспорада яшәгән татарлар өчен генә түгел, ә бәлки Татарстан белән Төркия арасында да мөһим бер мәдәни элемтә юлы салынуга этәргеч булып торыр.

## ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Апрельнең 15ендә Берлинда яшәгән милләттәшләребезне бергә җыйган халык шагыйре Габдулла Тукайны искә алу кичәсе булып үтте. Илдән читтә яшәгән кардәшләребезнең барысын да бер арага җыйган мондый милли кичәләребез һәрвакыт ясалып торса да, бүгенге көндә аларга башка бер аерымлык бар иде. Тукайның моңлы кылы тибрәнми башлаганга 20 ел тулды. Бүгенге җыелыш шул 20 елның истәлегенә багышланган иде. Садә, бик җыйнак эшләнгән бу чәй мәҗлесендә Тукай җырларындагы шикелле үк, шатлык та, кайгы да бер үк авырлыкта тора иде. Шатлык — халыкның үлмәс рухы, сүнмәс уты, сынмас гайрәте, аны нинди генә авырлыкка төшсә дә, тагы тартып чыгара: ул аны бер генә минутка да өметсезлеккә төшерми. Менә монда, читтә, тормышы һәм тормышның шартлары берлә безгә ятрак булган бер халык эчендә дә халкыбызның барысын да бергә җыйган, аларны бер үк теләк әйләнәсенә китергән бер уртак нәрсә бар. Бу — халыкның киләчәге өчен кыйммәтле бер нигез ташы, бу нигезне күрү безнең өчен шат-

лык. Кайгы — шагыйрьнең шигырьләренә моң биргән илнең, халыкның бүгенге хәле авырлыкта, анда рух та, сүз дә, уй да богауланган. Анда шагыйрьнең моңы да куначак урын таба алмый...

Мәҗлесне ачып беренче сүзне алган карт язучы Гаязның Тукайга багышланган җылы сүзләре шул ук вакытта безнең әдәби тормышыбызга да бер караш салу иде. Яңа әдәбиятыбызның чәчәк атарга өлгергән елларындагы төп гаясының халык эченнән чыгуы, аның моңын халык йөрәгеннән алуы һәм алдагы идеалының халыкның киләчәге берлә багланган булуы һәм боларның барысы да шул юлда үскән, һәм шул юлда өлгергән шагыйрьдә тагын да ныграк калыплануы әдәбиятны һәм шагыйрьне халыкның аерылмас өлеше иткән иде.

Илдәге бүгенге хәл яңа әдәбиятыбызның тирәнәюенә киртә куйды. Ул дошманның көчләве астында үзенең эчке мәгънәсен җуйды. Әдәбият халыктан бербөтенлек ясый торган бер бау булганга күрә, дошман моның берлә безнең халыкның барлык нигезенә дә балта чабарга тырыша. Болар барысы да уйларга, уйланырга тиешле булган күренешләр. Бу күренеш бер яктан ничаклы авыр булса, икенче яктан шул ук дәрәҗәдә аның авырлыгын җиңеләйтә торган көчләр тудырырга тиеш. Тормышта бер генә сафта җиңеп, өстен чыгып булмый. Җиңәр өчен бөтен сафта да бер үк көч берлә көрәшергә кирәк.

Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә илдән читтә яшәгән халкыбыз арасында уздырылган эшләр менә бу көрәшнең ялкыны һәркайда бер үк көч берлә янганын күрсәтә. Тышкы күренеш берлә садә генә күренгән бу җыелышларның кыйммәте бөтен йөрәкләрне ялап торган эчке тартыш ялкынының мәңге сүнмәслек бер утка әверелгән булуында.

Тукайның шигырьләре укылды: аның халык җыры урынына йөртелгән шигырьләре, озын көйләрнең моңына кушылып, мәҗлестә булучыларны бер генә кич булса да үз булган бер тормыш берлә яшәтте.

### *Варшауда*

15 апрельдә Варшаудагы укытучылар һәм гыйлем ияләренең катышы берлә шагыйрь Габдулла Тукайны искә алу кичәсе ясалды. Госман бәкнең Тукайның заманы һәм аның әдәбиятыбызда тоткан урыны турында рефераты бик зур дикъкать берлә тыңланды.

### *Һельсинкифорс*

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 20 ел тулу мөнәсәбәте илә 1933 елның 15 апрелендә Һельсинкифорс шәһәрендә торучы милләттәшләребез Тукайны искә алу кичәсе ясадылар. Кичәгә шәһәр һәм аның әйләнә-тирәсендә яшәүче бөтен кардәшләребез килгәннәр иде. Кичә М.Садыйк тарафыннан ачылып, шәкертләрнең күмәкләп җырлана торган җырыннан соң Хәлимә Габдеррәхим Тукайның тәрҗемәи хәлен сөйләде. Аннан соң Ибраһим Гарифулла «Халык шагыйре Тукай», В.А.Хәким «Тукай турында», Кадрия Хәким «Туган авыл», Гайса Бәшәр «Әүвәл төрк», Мөхәммәтсадыйк «Шигырьнең кыйммәте вә аның милли тормышка тәэсире», Әнвәр Җамалетдин «Пар ат»ларын сөйләп һәм укып, мәҗлес төнге 12 гә кадәр дәвам итте. Бу милли тойгыларны күтәргән һәм ил сөйгесен җанландырган кичәне оештыручыларга тәшәккер итеп үтүне бер бурыч саныйбыз.

***Таммерфорста*** яшьләр махсус бер Тукай кичәсе ясады. Шагыйребезнең тормышы һәм шигырьләре турында мәҗлестәгеләрне таныштырып, укучы балалар тарафыннан аның онытылмас шигырьләре укылды.

***Або*** шәһәрендә шагыйрь Габдулла Тукай һәм Исмәгыйль Гаспринскийларга багышланып бер хатирә кичәсе ясалды. Монда бу бөекләребезнең тормышлары сөйләнеп, аларның халкыбыз тормышында калдырылган эзләре һәм әсәрләре турында киң рәвештә таныштырылды. Аларның икесенең дә рухына фатиха укылды.

**Углан**

## МАТБУГАТ ДӨНЬЯСЫНДА

### *Шагыйрь*

Харбинда Габдулла Тукайның үлүенә егерме ел тулу уңае белән аны искә төшерү өчен төзелгән комитет тарафыннан чыгарылган бер көнлек гәзитнең 1933 ел, 15 апрель саны эчендә: 1. «Тукайга» — «Д»; 2. «Тукайга багышлап» — «Сөем»; 3. «Шагыйрьгә» — «Солтан»; 4. «Апрель көеле » — Хөсәен Габдүш; 5. «Зыялыларыбыз һәм аларга карашыбыз» — Кәримә Ишмөхәммәд; 6. «Халык шагыйре Габдулла Тукайны искә

төшерү» — З.Шакир; 7. «Әдәбиятның әхлакый әһәмияте» — Мөнир; 8. «Соңгы көрешү» — Ф.Әмирхан мәкалә вә шигырьләре берлә «Тукай комитеты»ның бу уңай берлә тәкъдим иткән программы бар.

Харбин мөселманнары киңәш һәйәте, милли идарә, мәктәбе «Гыйният» укучылары, ата-ана һәйәте, хатын-кыз оешмасы, яшьләр түгәрәге тарафыннан сайланган вә хосусый чакырылган кешеләрдән гыйбарәт Тукай үлүгә егерме ел тулу көнен тантаналы итеп уздыручы комитет, Тукай исемен мәңгеләштерү өчен, 12 апрельдә булачак тантаналы гомуми мәҗлестә түбәндәге тәкъдимнәрне игълан итәчәк:

1. Тукай исеменә Аурупа яки Азиядә булган югары мәктәпләрнең берендә Ерак Шәрыктагы барлык оешмалар белән берләшеп бер стипендия ачу;

2. Мәхәллә хозурында бер Тукай бүлмәсе ачу;

3. Тукай исеме белән һәр ел аның үлгән көнендә ел буена ана телендә иң оста язылган әдәби әсәргә мөкяфәт бирү өчен фонд төзү;

4. Балаларга махсус Тукай әсәрләреннән кечкенә генә бер рисалә нәшер итү.

Гәзит Тукай, Шиһаб хәзрәт, Фатих Әмирхан, Тукайның туган өе, туган авылы, анасының туган өе, Тукайның сабак укый башлаган өенең рәсемнәре берлә бизәлгән.

## ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ ҺӘМ АНЫҢ УКЫМЫШЛЫЛАРЫНЫҢ ИДЕАЛЫ

«Гыйният» мәктәбендә Харбин төрк-татар яшьләре оешмасының узган шимбә көнге нәүбәттәге чәйле утырышы үзенең тулылыгы вә уңышлылыгы берлә күзгә ташлана иде.

Берлинда басылган һәм һәрбер татарның күңеленә якын милли җырларны эченә алган кечкенә генә китап яшьләр арасында үзләренең җырларына булган кызыксынуны тагын да җанландырып җибәрде.

Әхмәт Виргаз халык җыры турында Тукай фикерләре берлә халыкны таныштырып, татар җырларына һәм аларның үзләренә генә махсус аерымлыкларына озын гына тукталып үтте. Тукай халык җырларын һәрнәрсәдән өстен күрә иде. Шуңа күрә аның үз шигырьләре дә халыкның киң катламына җиңел аңлашыла иде.

Икенче реферат Фатих Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» берлә Кәбир Бәкернең «Бәйрәм хатирәләре» турында булып, Хөсәен Габдүш тарафыннан укылды. Бу ике язучының икесе дә татарның милли уяну дәверендә яшәү һәм эшләү берлә бәхетле булган укымышлылардан иде. Алар икесе дә Аурупа мәдәниятенең яклаучылары иде. Аурупа мәдәнияте алар өчен бер үрнәк иде. Җәмгыятьнең чын тормышы, аның идеалы арасындагы аерма — менә бу югарыдагы ике нәрсәнең мәүзугы. Милли язның беренче көннәрендәге укымышлылар көткән халыкның якты киләчәге — ул вакытлар әле төш кенә күк иде. Сөйләүченең сүзләре ышанычлы-иманлы иде: милли үлчәүдә моннан 20 ел элек булуы мөмкин булмас күк күренгән нәрсәләр бүген халыкның тормышында барлыкка чыкты. Бүгенге яшьләрнең эшләргә тиешле булган эшләре үзләре өчен туры юл сызу. Һәр ике сөйләүче бик зур дикъкать берлә тыңланып, соңында җанлы фикер алышу берлә тәмамланды.

**Харбин мөхбире**

## ТУКАЙНЫҢ 50 ЯШЕ

Харбинда шагыйребезнең туган вакыты яңа әдәбиятыбызның беренче рухание «Хисаметдин менла»-ның дөньяга килүенә 50 ел тулган көненә туры китерелеп, җомга көн 12 июньдә аңа 50 яше тулу көнне үткәрелде. Бу көн шәрифенә Милли идарә вә яшьләр тармагы һәркемгә үтемле буларак арзан бәһале бер кичә ясап уздырдылар.

Сәхнә ачылгач та, матур чәчәкләрдән бизәлгән Тукайның рәсеме күзгә ташланып тора. Аның күзләренең моңлы карашы моңа кадәр Идел-Урал төрк-татарларының күпме михнәт күргәнлеге хакында җырласа, бу ел аңар 50 яшь тулуга: «Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым», — дип сөйли кебек тоела иде.

Әхмәт Виргаз әфәнде тарафыннан бу көннең нинди тарихи көн икәнлегенә мөкаддәмә эшләнгәч , «Тукай рәсеменә...» дигән шигыре укылып чыгыла. Мәрхүмгә ихтирам йөзеннән шигырь халык тарафыннан аякка басып тыңланыла. Шуннан соң Маһинур туташ Виргаз тарафыннан Тукайның тәрҗемәи хәле сөйләп үтелә. Зөһрә туташ Аги тарафыннан «Хисаметдин менла» вә аның мөхәррире Муса Акъегетзадә тугрында кыскача мәгълүмат бирелгәннән соң, сәхнәдә шагыйрьнең иҗатыннан төрле декламацияләр эшләнде вә

җырлар җырланды. Кыллы оркестр тарафыннан «Тукай маршы» вә башка көйләр уйналды. Шәмсенур туташ Солтан пианинода «Тукай маршы»н уйнап бик каты алкышланды.

Кичәгә килгән халык, бигрәк тә яшьләребез бик күп булганы хәлендә, бик күңелле вә рухлы узды.

Бу кичәдә, хатирәле буларак, шагыйрьнең исем вә туган иле язылган яшел төсле тасмалар тартылды.

**Мөхбир**

## ШАНХАЙДА ИСТӘЛЕК КӨННӘРЕ

Идел-Урал төрк-татарларының соңгы мөфтисе вә дин галиме Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең ел билгесе һәм бөек шагыйрь Габдулла Тукайның вафатына 24 ел тулу көнен искә алу мөнәсәбәте белән Шанхай төрк-татарының мәдәният җәмгыяте 15 апрельдә украиннар клубында махсус утырыш ясады. Мәҗлес сәгать 8дә җәмгыять рәисе Кәшшаф әфәнде Әхмәд тарафыннан ачылды. Шанхайда яшәүче илдәшләрнең хезмәтендә буш булганнары хазир иде. Нанкиннан Галимә туташ Әхмәди вә төркестанлы кардәшләребездән доктор Мәсъгуд бәк килгәннәр иде. Шулай ук җәбһәдәшләребездән украина җәмгыятенең рәисе доктор Квашинко вә башкалар хазир иделәр. Мәхәллә имамы Әхмәди әфәнде Җәмалетдин, Коръән укып, савабын мәрхүмнәрнең рухларына багышлап дога кылгач, бүгенгә каратып нотык сөйләде. Моннан соң Мәдинә ханым Әхмәди Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең дин галиме, тарихчы вә мөхәррир буларак эшләгән эшләре хакында мәгърузә эшләде.

Ун минут тәнәфестән соң Шанхай төрк-татар дини-милли мәктәбендә укучы шәкертләр шагыйрь Габдулла Тукайның шигырьләрен сөйләделәр, җырладылар. Мәдинә ханым Әхмәди, Тукай шигырьләренең балалар кыйсемен алып, «Балалар тәрбиясе» мәүзугында мәгърузә укыды. Рәхмәтулла әфәнде Фәтхулла «Габдулла Тукай — халык шагыйре» мәүзугында мәгърузә эшләде. Балаларга бүләкләр бирелде, ханымнар тарафыннан чәй өстәле хазирләнеп, килгән халык чәйгә дәгъвәт ителде. Чәй арасында доктор Квашинко һәм Апувичко милли-мәдәният вә аның милли хәрәкәте тәэсире хакында сүз сөйләделәр.

Кәшшаф әфәнде Әхмәди, бу мәҗлесне оештыруда ярдәм иткән ханым вә әфәнделәргә, мәгърузәчеләргә вә барча мәҗлестә булган кардәшләребезгә рәхмәт укып, мәҗлесне япты.

**Якташ**

## ӨЧ СӘГАТЬ ТУКАЙ МОҢЫНДА

Шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 24 ел тулу көнендә, 15 апрельдә, Харбин төрк-татар мәхәлләсендә эшләнгән Тукай кичәсе гаять дәрәҗәдә бер уңышлык белән узды.

Кичә башланыр алдыннан хәзерге көнне Ниппонда җәмгыять эше белән булган Мөнир хәзрәтнең ләвазимен үтәүче имам тарафыннан Ризаэтдин бине Фәхретдин мәрхүм хәзрәтнең (вафатына бер ел тулу уңае белән) һәм Габдулла Тукайның рухына Коръән укылды.

Сәхнә пәрдәсе күтәрелер алдыннан Милли идарә рәисе Хәбибулла әфәнде Сали кичәнең тәртибен игълан итте. Коръән уку мәрасиме мәктәбе «Гыйният» укучылары тарафыннан да күмәк рәвештә үтәлеп, сәвабы ике олуг мәрхүмнең рух шәрифләренә багышланды.

Шуннан соң Маһинур туташ Чурай, тәфсилле рәвештә шагыйребезнең тәрҗемәи хәленә тукталып, Тукайның тормышы вә яратышы хакында исемле язучыларның мәкаләләреннән өземтәләр китереп, мәгърузә эшләде. Икенче мәгърузәче — мөгаллимә Маһинур туташ Виргаз. «Тукай — халык шагыйре» мәүзугында сүз сөйләп, аның иҗаты хакында мәгълүмат бирде. Мәгърузәче туташлар икесе дә хазирун тарафыннан самими рәвештә алкышландылар.

Балалар тарафыннан күмәк җыр «Туган тел» җырлангач, алар арасыннан ялгыз чыгышлар белән Тукайның берничә шигырьләре укылды, шуның белән кичәнең беренче бүлеге тәмам булды.

Программаның икенче кыйсеме шагыйрьнең «Шүрәле»сен күренешләндерү белән башланып китте. Монда «Тукай» әсәрен укып торучы ролендә Маһирә туташ Лаеш, Шүрәле ролендә Сәгыйть әфәнде Килки, утынчы егет булып Кәримдар әфәнде Виргаз иштиракъ иттеләр. Шүрәленең мөгезләре ярты аршыннан озын, бармаклары, гомумән, бу «куәт очарлык әллә нинди нәрсәнең» кыргый тавышы вә этенешләре караучылар өчен бер яңа нәрсә булып чыктылар. Ай яктысы төсендәге утлар яктылыгында бирелгән бу күренеш халыкка бик ошады. Мәшһүр «Өзелгән өмид»тә үзенә махсус көй белән яшьләрнең күмәк җырлаулары илә шагыйрьнең аһәңенә муафыйк шул ук моң яктысында иҗра ителде.

Маһирә туташ Лаеш белән Суфия туташ Чурай «Нәсыйхәт» шигырен «Тәфтиләү» көенә җырлап бирделәр. Кәримдар әфәнде Виргаз «Су анасы» белән чыгыш карауаучыларның күңелен ачты.

Фәридә туташ Аги «Өзелгән өмид»нең беренче юлларын вә халыкның соравы буенча кабат чыгышында «Эшкә өндәү»не җырлап алкышланды. «Үз-үземә» шигырен Зөһрә туташ Аги укып чыкты. Хөсәен әфәнде Габдүш «Милли моңнар»ны «Әллүки» көенә җырлап, тыңлаучыларның үтенүе буенча тәкрар чыгышларны да халыкка бик ошаган бер «яңа» иске көйгә «Сайра, сандугач» шигырен вә «Сакмар суы»н җырлады.

Кичәне музыка ягыннан рәсмиләндерүдә һәрвакыттагы кебек бөтен хезмәтне пианинода оста уйнаучыбыз Шәмсенур туташ Солтан башкарды. Мәгълүм ки, яшьләребез музыка тәрбиясенә бик мохтаҗдыр. Шунлыктан яхшы уенчы безгә бик тансык. Шәмсенур туташ исә хәзерге көнне дә пианинода тәхсилен тәгәлләүдә дәвам иткәне хәлдә, еллар буенча сәхнәбездә милли көйләребезне уйнап, халкыбызның мәхәббәтен казанып килә.

Бу кичәдә исә уенчы аеруча бер рух белән җырлаучыларга кушылып, иң соңгы ялгыз чыгышында «Тукай көе»н (маршын) зур бер осталык белән уйнап, кичәнең программын тәмам итте.

Кичәдә Ерак Шәрык төрк-татарларының дини-милли мәркәзе рәисе могавиннәренең ләвазимен үтәүче Әхмәдшаһ әфәнде Гыйззәтулла күрше мәхәлләләребездән Хайлар төрк-татарлары милли идарәсе әгъзасы Әхмәдшаһ әфәнде Аги хазир иделәр.

Шулай итеп, карауаучылар өч сәгать буена Тукайның шигъри моңында калып, кичәдән бик мәмнүн булганнары хәлдә өйгә таралдылар.

Сәхнәдә Тукайның яшел тасма белән әйләндереп алган рәсеме эленгән. Аның өстенә шагыйрьнең «Үз-үземә»сеннән ошбу юллары язылган иде:

Күңел берлән сөям бәхтен татарның,
Күрергә җанлылык вакытын татарның.

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын.

**Мөхбир**

## ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Мукден Идел-Урал җәмгыяте идарәсе, яшьләр түгәрәге вә хатын-кызлар түгәрәге һәм мәктәп шәкертләренең иштиракы белән 25 апрельдә мәктәп бинасында шагыйребез Габдулла Тукайга багышланган кичә ясалды.

14 апрельдә мәрхүм мөфтиебез Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең вафат булуының еллык истәлеге булганлыктан, идарә Тукай кичәсен, елдагыча 15 апрельдә ясамыйча, берничә көн соңрак ясарга карар ителгән иде.

Кичә җәмгыять идарәсенең хатибы Әхмәтшаһ әфәнде Гыйззәтулла тарафыннан кичке сәгать 10да ачылгач, Ибраһим әфәнде Яуш тарафыннан мәрхүм шагыйребезнең рухына багышлап Коръән укылды. Мәктәп шәкертләре тарафыннан күмәкләп «Нигә үлдең, Тукай?» шигыре җырланды. Моннан соң Әхмәтшаһ әфәнде Гыйззәтулла Тукай кичәләренең әһәмияте вә аларның тәрбияви мәгънәсе хакында сүз сөйләде. Яшьләр түгәрәге рәисе Мансур әфәнде Арысланбәк Тукайның тәрҗемәи хәлен сөйләде. Шәкертләр тарафыннан Тукайга багышланган вә Тукай тарафыннан язылган шигырьләр берәм-берәм сөйләнде вә күмәкләп җырланды. Рокыя туташ Мөхәммәдиш Тукай иҗаты хакында сөйләп, Тукай шигъриятенең рухы, Тукай шигырьләрендәге миллият хисе вә Тукай иҗатының бүгенге вә киләчәктә уяначак роле хакында мәгълүмат бирде. Сара ханым Нияз Тукайның «Нәсыйхәт»ен, Мансур әфәнде Арысланбәк «Чын белән Ялган»ын укып чыктылар. Ибраһим Яуш вә Газизулла Айдар әфәнделәр, «Кыз белән егет»не сөйләп, халыкны көлдерделәр. Мансур әфәнде Арысланбәк «Милли моңнар»ны әүвәлге көенә җырлады. Шәкертләр тарафыннан «Тукай маршы» җырланып, сәхнә кыйсеме тәмам булды.

Кунакларга хатын-кызлар түгәрәгенең идарә әгъзалары Галия ханым Җиһаншаһ вә Сара ханым Нияз карамагында хәзерләнгән чәй тәкъдим ителде.

Гадәттә, Тукай кичәләре яшьләрнең тәшәббесе вә иштиракы белән ясалып килгәнгә, бу елгы «Тукай кичәсе»ндә Мукден яшьләренең бик аз иштиракъ итүләре, кичәнең башка яктан уңышлы чыгуның кыйммәте төште вә бу хакта сөйләүчеләр тарафыннан тәәссеф бәян ителеп, киләчәктә яшьләр өстенә йөкләнгән бурычка кимчелек китермәүгә дикъкать итүләре тәүсыя ителде.

Мәҗлес Кятиб әфәнденең Тукай кичәсенә тырышып хәзерләнгән шәкертләргә вә мөгаллимәләре Разыя ханым Дәүләткилдегә рәхмәт уку белән тәмам булды.

**Минһаҗетдин углы**

## ТУКАЙ КӨНЕ

**Нагояда:** Нагояда Идел-Урал төрк-татар мөселманнарының мәдәният җәмгыяте карамагындагы динимилли мәктәптә 15 апрельдә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның истәлеге уздырылды. Мәктәп шәкертләре тарафыннан Коръән укылып, мәрхүм шагыйребезнең газиз рухына багышланды. Аннан соң мәктәп диварында, өлкән Тукайның рәсеменә карап, мәктәп шәкертләре тарафыннан «Нигә үлдең, Тукай?» шигыре җырланды. «Туган тел», «Казанга китү», «Васыятем», «Өзелгән өмид» шигырьләре укылды. Мәгълүм Гыймадетдин бай Мөхәммәди тарафыннан шагыйребезнең тәрҗемәи хәле, тар тормышы хакында озын вә тәфсилле рәвештә мәгълүмат бирелде. Аннан соң мәктәп шәкертләре тарафыннан салават укылып, Тукай истәлеге шуның белән тәмам булды.

**Мөхбир**

**Тәнзиндә:** 15 апрельдә мәктәп залында бөек шагыйребез мәрхүм Габдулла Тукайны искә алу тупланышы ясалды.

Хатыйп хәзрәт Халиди мәҗлесне ачып, Тукайның милләтебез каршында булган кадәре вә аны ни өчен искә алуыбыз турында сөйләгәннән соң, Тукайдан башка шагыйрьләребез исемнәрен зикер итеп, алар хакында да кыскача мәгълүмат биргәч, Коръән укып, мәрхүм Тукай рухына багышлады.

Соңра Хатыйп хәзрәт олуг мөфтиебез Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең вафатына бер ел тулуны халыкка белдереп, мөфти хәзрәтләренең тәрҗемәи хәлен, гыйльми хезмәтләрен, актык сулышына кадәр күп газап вә авырлыклар эчендә дин сафында хезмәт итүен сөйләп, Коръән укып, савабын Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең рухына багышлады.

**Айсылу**

**Хайларда:** бу ел апрельнең 15ендә көндез сәгать 3тә гадәттәгечә ошбу көнне бөек шагыйребез мәрхүм Габдулла Тукайга багышлап, аның вафатына 24 ел тулу мөнәсәбәте белән һәйәте тәгълимия тарафыннан мәктәп балалары күләмендә сөекле шагыйребезне искә алу мәҗлесе ясалды. Бу көнне мәктәптә уку булмады. Мәҗлес мөдәррисе Заһирә туташ Күгүш тарафыннан ачылып, мәҗлеснең мәгънәсе аңлатылды. Моннан соң шәкертләр тарафыннан Коръән укылып, мәрхүм шагыйребезнең рух шәрифенә багышланды. Укытучы Фатыйма туташ Кавәси тарафыннан шагыйрьнең тәрҗемәи хәле укылып чыкты. Заһирә туташ Күгүш «Тукай — халык шагыйре» мәүзугында нотык сөйләде. Соңра сәхнә кыйсеме башланып, шәкертләр тарафыннан шагыйрьнең йөрәк шигырьләреннән «Өзелгән өмид»е җырланды вә шагыйребезнең энҗе бөртекләредәй шигырьләре бер-бер артлы сөйләнделәр. Аннан соң «Тукайга» дигән шигырь «Тукай маршы» көенә күмәкләп җырланды. Хәнифә туташ Күгүш үзенең «Тукайга» дигән шигырен укыды. Мәҗлес сәгать 5тә ябылды.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ 25 ЕЛЛЫГЫ

***Мукден Идел-Урал җәмгыятендә,***
***Хайлар дини-милли мәктәбендә,***
***Кижү Идел-Урал оешмасында,***
***Фозан милләтчеләрендә, Харбин мәхәлләсендә.***

**Үтәмеш**

Мәрхүм шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу уңае белән Мукден Идел-Урал җәмгыяте тарафыннан 15 апрельдә кич сәгать 10 да мәктәп бинасында истәлек тупланышы ясалды.

Җәмгыятьнең хәзинәдары Сөләйман әфәнде Аети мәҗлесне ачу белән Гаяз Уразбәхет тарафыннан мәрхүм шагыйрьнең рухына Коръән укып багышланды. Яшьләр түгәрәгенең рәисе Мансур әфәнде Арыс-

ланбәк шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен сөйләп, мәрхүмнең аяныч тормышын бер-бер артлы күз алдыннан уздырды. Рокыя туташ Мөхәммәдиш Габдулла Тукай иҗаты хакында мәгълүмат биреп, Тукай шигъриятенең моңына иң башлыча сәбәп булган милләтебезнең әсарәтенә озын тукталды. Тукай шигъриятенең милли барлыгыбызга бәйлелеген аңлатканның соңында, сүзнең ахырында мөһаҗәрәт тормышыбыз өчен Тукай иҗатының милли-тәрбияви кыйммәте хакында сөйләде.

Мәктәп шәкертләре тарафыннан «Нигә үлдең, Тукай?» шигыре күмәкләп җырланды.

Моннан соң бөтен кунаклар Сара ханым Нияз вә Галия ханым Җиһаншаһларның иҗтиһады белән хәзерләнгән чәй өстәле янына чакырылдылар. Яңадан Тукай рәсеме белән бизәлгән сәхнә ачылып, шәкертләр тарафыннан Тукайга багышланган шигырьләр укылды.

«Өйләнү түгел сөйләнү» ирләрчә киенгән Наҗия Рамазан һәм Кавия Мөдәррис туташлар тарафыннан искиткеч осталык белән үтәлеп, Тукай хатирәсе моңында тынып калган мәктәп эчен көлке, алкыш тавышлары белән тутырды. Кызлар, өзлексез алкышланып, сәхнәгә тәкрар чыгарга мәҗбүр булдылар. «Милли моңнар» шул ук туташлар тарафыннан «Зиләйлүк» көенә җырланды.

Мансур әфәнде «Пәйгамбәр»не җырлады вә, икенче мәртәбә сәхнәгә менеп, «Сөбханалла, сөбханалла» һәм «Чын белән Ялган»ны сөйләп бик алкышланды. Хафиз әфәнде Шахмай «Монафикъка»ны укып чыкты. Моннан соң Мансур әфәнде «Тукай маршы»н мандолинада уйнап, әле генә шагыйрьнең көлке белән тулган шигырьләреннән бер гөж килеп торган залны тирән бер тынлык, моң эченә батырды.

Иттифакый рәвештә генә кичәгә Анзан шәһәреннән килгән Халидә туташ Кодаки, халыкның соравы буенча, «Әллүки» көенә «Милли моңнар»ны матур тавыш белән җырлап, Тукай кичәсенә аерым матурлык, шигърият бирде. Җырчының шигырьдәге «Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә татар күңеле ниләр сизгәнен» сүзләренең зарыны аерым рәвештә хисси матурлык белән тасвир итүе күңелне илгә, Тукай моңы белән бергә Болгар һәм Агыйдел буйларына алып китте. Зал тагы тынлык эченә батты. Тагын мәҗлеснең башындагы моң хөкем сөрә башлады... Халидә туташ туктаусыз алкышлар эчендә сәхнәдән төшкәч, Тукай истәлеге кичәсенең рәсми кыйсеме ябылды.

Вафатына 14 апрельдә ике ел тулган мәрхүм мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең газиз рухына Коръән укып багышлану белән тупланыш тарала башлады. Тик яшьләр генә кичәне уен-көлке эчендә төнге 3 кә кадәр дәвам иттерделәр.

* * *

**Айсылу**

Төрк-татар әдәбиятының кояшы, бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына бу ел 25ел тулу уңае белән апрельнең 15ендә көндез сәгать 3 тә Хайлар төрк-татар мөселман мәктәбенең һәйәте тәгълимиясе тарафыннан истәлек мәрасиме ясалды.

Мәрасим шәкертләр өчен тәртип ителгән булса да, мәхәлләнең бөтен олуглары вә ата-аналар да хосусый рәвештә мәрасимгә чакырылган булганга, мәктәп эче мәрасимгә катнашучылар белән шыгрым тулы иде. Мәктәпнең бу бөек истәлек көненә килешерлек төстә җыештырылган сәхнәсенә кадерле шагыйребезнең матур зур рәсеме эленгән иде.

Мәҗлес мәктәп мөдәррисе Заһирә туташ Күгүш тарафыннан ачылгач, шәкертләр тарафыннан гүзәл, моңлы мәкам белән күмәкләп Коръән укылып, мәрхүм шагыйребезнең газиз рух шәрифенә багышланды. Мөгаллимә Фатыйма туташ Кавәси тарафыннан шагыйрьнең тәрҗемәи хәле укылып чыкты. Заһирә туташ Күгүш, 25 еллык истәлеккә багышланган озын тәэсирле нотык сөйләп, сүзләрен түбәндәгечә тәмам итте: «Халык шагыйре Габдулла Тукайның моңлы каләме тибрәлмәүгә инде 25 ел тулса да, аның онытылмаслык тавышы без төрк-татарларның йөрәкләрендә мәңге яңгырап торачак! Яшәсен җан азыгы Тукай шигырьләре, яшәсен Тукай белән бергә туган телне сөючеләр вә шулар белән бергә яшәсен төрк-татар милләте!» Моннан соң Шаһгъзам әфәнде, кереш сүз алып, истәлек мәрасименә багышланган нотык укып чыкты.

Шагыйрьнең энҗе бөртекләре — балалар кыйсеменнән алынган матур шигырьләр — шәкертләр тарафыннан бик әсәрле итеп укылдылар. Тукайның «Өзелгән өмид», «Туган тел», «Тәэсир» исемендәге шигырьләре Заһирә туташның пианинода уйнавы астында шәкертләр тарафыннан күмәк җырланды.

Мәҗлес ахырында Фатыйх әфәнде Илбик һәм Әхмәдшаһ әфәнде Аги тарафыннан мәрасимгә багышланган кыйммәтле сүзләр сөйләнде.

* * *

**Кижү мөхбире**

15 апрельдә кич сәгать 7дә мәрхүм шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу уңае белән Киҗү милләтчеләре идарә йортында махсус мәҗлес ясадылар.

Бу истәлек мәҗлесе Киҗү Идел-Урал җәмгыятенең рәисе Фазлыйәхмәд әфәнде Хаҗиәхмәднең көннең әһәмиятен аңлаткан нотыгы белән ачылды. Мәхәллә имамы Габдулла әфәнде Хәким рәиснең үтенече буенча мәрхүм шагыйрьнең рух шәрифенә Коръән укыр алдыннан апрельнең 14ендә бөек мөфтиебез Ризаэтдин бине Фәхретдин җәнапларының вафатына 2 ел, вә 18 апрельдә Ш.Мәрҗани хәзрәтләренең вафатына 49 ел тулуын сөйләп, укылачак Кәляме Шәрифнең савабын, илебезнең бөек мәрхүмнәренең рух шәрифләренә багышлауны үтенде.

Коръән укылганнан соң, Габдулла әфәнде Хәким шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен укып чыкты вә аның кыйммәтле иҗатын аңлатып сүз сөйләде.

Мәктәп шәкертләре тарафыннан шагыйрьнең бик күп шигырьләре берәм-берәм укылып һәм күмәкләп җырланып чыкты. Моннан соң кунакларга милли ашлар белән чәй бирелеп, истәлек мәҗлесе төнге 11 гә кадәр сузылды.

* * *

**Фозан мөхбире**

Фозан шәһәрендә яшәүче Идел-Урал төрк-татар милләтчеләре, мәрхүм Габдулла Тукайның үлүенә чирек гасыр узуны сызып китәр өчен, Вәлиәхмәд хәзрәт Габдулла йортында махсус зыяфәт ясарга карар иттеләр вә бөтен милләтчеләр тупланган хәлдә 15 апрельдә истәлек мәрасиме уздырылды.

Хәзрәт тарафыннан мәрхүм шагыйрьнең газиз рухына Коръән укып багышланды. Тормышы һәм иҗаты хакында мәгълүмат бирелеп, шагыйрь иҗатындагы иң характерлы шигырьләре укылып чыгылды. Кунакларга чәй тәкъдим ителеп, мәҗлеснең ахырында вафатына 14 апрельдә 2 ел тулып узган мәрхүм мөфти Р.Фәхретдин җәнапларының рухына Коръән укып багышланды.

* * *

**Углан**

Харбин төрк-татарлары Тукайның 25 еллыгын әдәбият кичәсе эшләү белән билгеләп үттеләр. 15 апрельнең алдагы көнне мөфти хәзрәтләренең вафаты белән багланып, шулай ук кайгы көнебез булганлыктан, кичәдә имам Мөнир хәзрәт Хәбибулла тарафыннан ике зур кешебезнең рухларына Коръән укылды.

Кичәне «Олуг кешеләр» мәүзугында элек сүзне алган «Гыйният» мәктәбе укытучысы Маһирә ханым Кодаки башлап җибәрде. Аның соңында шул ук мәктәптә укытучы Маһинур туташ Виргаз Тукайның тәрҗемәи хәлен искә төшереп, үз [...]* белән икенче чыгышында Ризаэтдин хәзрәткә багышланган сүзен әйтте.

Шагыйребез яратышы хакында сөйләгән Маһинур туташ Чурайдан соң шул ук мәүзугъта сүзен нигезләгән Әхмәд әфәнде Виргаз чыкты.

Бөтенлеге белән Тукай әсәрләреннән чигелгән әдәбият бүлемендә шагыйребезнең балаларга калдырган бай мирасыннан чүмереп алган шигырьләре белән мәктәбе «Гыйният» балалары ялгыз-ялгыз чыгып алкышландылар.

Яшьләр түгәрәге әгъзалары күмәкләшеп, мәшһүр «Өзелгән өмид»не җырлап, «Пәйгамбәр»не «Мөхәммәдия көе»нә салып әйттеләр, җырлы-музыкалы ялгыз чыгышларында туташлардан «Татар кызына» белән Суфия Дибуш, «Милли моңнар» белән Суфия Чурай, беренче «Киңәш» белән Маһирә Лаеш, «Үкенеч» белән Сәгыйдә Агиш, «Мәхәббәт» белән Фәридә Кусый (...) алкышландылар.

Кат-кат чыгуы үтенелгән Маһинур туташ Виргаз «Тукайга» (Солтан шигыре) һәм Тукайның «Кичке теләге»н осталык белән үтәде. «Бәрәңге» шигырен Таһирә туташ Аги әйтеп бирде. Тукайның берничә сайланган шигыре белән чыккан Кәримзад әфәнде Виргаз өлешенә дә уңыш төште. Җырлаучыларга пианиносы белән булышкан вә соңыннан үзе дә ялгыз чыгып бик оста хәзерләнгән моңлы Тукай көен уйнап алкышланган Шәмсенур туташ Солтан кичәнең «моңлы ягы» уңышлы үтүгә талымсыз ярдәмдә булынды. Аның шәкертләреннән Мөнирә Хәсбиулланың пианинода «Галиябану»ны уйнавы да килешеп чыкты. Әйтеп торучылыкны Маһинур туташ Бичура үтәде.

Кичәгә иттифакый тугры килеп чыккан мәркәз башкарма рәисе могавинын үтәүче Әхмәдшаһ әфәнде Гыйззәтулла, Мөнир хәзрәт, Ибраһим әфәнде Акчура һәм Кәримә ханым Ишмөхәммәд берничә сүз әйттеләр.

Сәхнәнең башына «Якынрак Тукай белән туган телгә!» дигән шигарь язылып, шагыйрьнең рәсеме астында исә аның «Үз-үземә» исемле шигыреннән дүрт юлы кертелеп язылган иде.

**Хәбәрче**

## ТАМПЕРЕДА ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Бу ел апрельнең 15ендә сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте берлә Финляндиянең Тампере шәһәрендә яшәүче төрк-татарлар, олуг шагыйрьләрен искә алып узар өчен, гаять гүзәл вә тантаналы бер Тукай кичәсе уздырдылар. Тампереның зур залларының берендә Тампере төркләр берлеге тарафыннан тәртип ителгән бер кичәгә шәһәребездә яшәүче бөтен төрк-татарлар ире-хатыны, баласы-чагасы берлә килгәннәр иде. Кичәне Тампере төркләр берлегенең рәисе Гыйбадулла әфәнде Мортаза ачып, килгән кунакларга «Хуш килдегез!» сүзләре берлә мәрхүм шагыйребез вә бүгенге тәртип ителгән кичә хакында кыска гына, ләкин бик матур сүзләр сөйләп, хазирун сөекле шагыйребезнең рухына хөрмәтән бер дәкыйка аякка калкып сөкүт итүне, соңрадан, Коръән укып, аның газиз рухына багышлауны тәкъдим итте.

Коръән укылып багышлангач, Тампере төрк-татар мәктәбендә укучы шәкертләр тарафыннан күмәкләп «Тукайга» дигән шигырь җырланды. Моннан соң бер-бер артлы мәктәп шәкертләре тарафыннан Тукайның гүзәл шигырьләре укылды. Шәкертләрне мәгълүмебез Гыйбадулла әфәнде бик яхшы иттереп хәзерләгәнгә күрә, алар халык тарафыннан бик алкышландылар һәм кат-кат сәхнәгә чыгарга мәҗбүр булдылар. Шәкертләребезнең телләренең арулыгы да күзгә чарпырлык дәрәҗәдә сизелә һәм барыбызны да сөендерә, йөзебезне көлдерә иде. Соңра Тукайның «Шүрәле»се күренештә күрсәтелде. Мәктәп шәкертләреннән малай: Әсгад Байбулат (Шүрәле), Хәмитрахман Хәкимҗан үзләренең рольләрен бик оста башкардылар һәм бик алкышландылар. Тампере туташлары хор берлә «Пар ат»ны җырладылар.

Бераз тәнәфестән соңра чәй эчкәч, Мәхрүсә Вафа тарафыннан халык шагыйре Габдулла Тукай һәм аның безнең өчен, вә билхасса балаларыбыз өчен, илсезлек хәятыбызда роле вә әһәмияте хакында нотык сөйләнде. Сөйләүче Тукай кичәләре эшләнүнең безнең өчен никадәр кирәклеген һәм аның яшь буыныбызның тәрбиясендә никадәр мөһим икәнлеген аерым сызып узып: «Тукай! Бәхетсез милләтебезнең үксез шагыйре! Син үлмәдең, син яшисең! Төрк-татар милләте бар булдыкча, Син дә яшәячәксең, халкыбызның аңы арттыкча, Синең кыйммәтең артачак! Әй төрк-татар милләтенең үлмәс сөекле шагыйре, рәхәт йокла мәңгелек ятагыңда, рухың шат, җаның җәннәттә булсын!» — дигән сүзләр берлә нотыгын тәмам итте вә, бүгенге кичәне тәртип итүдә иң күп көч сарыф итүче Тампере төркләр берлегенең рәисе мәгълүмебез Габдулла әфәндегә бик күп рәхмәтләр укып, мондый һәрберемез өчен кыйммәтле милли кичәләрнең ешрак эшләнүен теләп сүзен бетерде.

Моннан соң тагы шәкертләр тарафыннан күмәкләп «Туган тел» җырланды һәм шигырьләр укылды. Тукайның «Нәсыйхәт»ен Зәкия Мөхәммәтҗан һәм «Мәрсия»сен кечкенә Фәйзә Билалетдин бик матур иттереп укыдылар, вә халыкның теләве вә кул чабулары аркасында тәкрар сәхнәгә чыгарга мәҗбүр булдылар. «Су анасы», «Таз» күренешен дә күрсәттеләр. «Су анасы»ндагы малай ролен Мансур Байбулат бик оста башкарды вә хазирун тарафыннан гаять алкышланды.

«И мөкаддәс»* , «Милли моңнар» бик матур иттереп туташларыбыз тарафыннан җырландылар. Мәктәп шәкертләре дә күмәкләп «Васыятем»не җырладылар. Бөтен кичә Тукай моңы эчендә узды. Шәкертләрнең барысының да йөзләре көлә, әйтерсең алар: «Әй Тукай! Кыйммәтле шагыйребез, Син безгә үлмәслек шигырьләреңне язып, бүләк итеп калдырдың. Без дә бүген, үлүеңә 25 ел тулганда, бөтен көчебезне берлә Синең кичәңә иштиракъ итеп, Сине зурлыйбыз, Сине искәрәбез һәм шуның өчен шатланабыз», — дигән шикелле тоела иде.

Тукайның рәсеме зур вә бик матур итеп эшләнеп, өстенә дә «25 ел тулу мөнәсәбәте берлә» дигән сүзләр язылып, халыкка сатылды. Тампере туташлары да лотерей тәртип иткәннәр иде, бик җанлы узды. Буфетны да туташларыбыз алып бардылар.

Әлхасыйль, бу тәртип ителгән милли шагыйребез Тукайны искәрмә кичәсе бик җанлы, бик күңелле узды. Җыелган халык та кичәдән, фәүкыльгадә мәмнүн булганнары хәлдә шагыйрьнең мәгъсүм, газиз рухына дога кыла-кыла, бер-берсеннән аерылдылар. Сәгать 6 да башланган кичә 11 нче яртыда гына тәмам булды.

**Яшь истикъляльче**

## КАҺИРӘДӘ ТУКАЙ КӨНЕ

Без, Әл-Әзһәрдә укучы Идел-Уралллы шәкертләр, санybыз күп булмаса да, милли көннәрне сызып үтәбез. Шул җөмләдән бу ел апрельнең 15ендә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте берлә, бу бөек көнне сызып, бер мәрасим уздырдык. Мәрасимгә кушылып, төркестанлы кардәшләребез, илдәшләребез сайгылы Хәмзә Таһир бәк, Әзһәрдә төрк шөгъбәсенең рәисе саягылы Габделхәмид Таһир бәк дәгъвәт ителгәннәр иде. Мәрасим бүлмәсе бөек юлбашчыбыз Гаяз бәк Исхакый, бөек төркче мәрхүм Йосыф бәк Акчура вә искә алынучы шагыйребезнең рәсемләре берлә бизәлгән иде. Мәҗлесебез сәгать 3 ярымда дәгъвәт ителгән затларның һәммәсе хазир булганы хәлдә Галиулла Агишның кереш сүзе берлә башланды, ул сүзнең ахырында төркестанлы Сөләйман әфәндедән шагыйребез рухына Коръән укуын үтенде. Сөләйман әфәнде бик матур мәкам берлә Коръән укып, шагыйребезнең рух шәрифенә багышлады. Коръән укылгач, Ибраһим Хәсән тарафыннан авыз гармунында уйналган «Сөембикә маршы» хазирун тарафыннан аякка басып тыңланылды. Моннан соң сүзләр башланды.

Габдулла Агиш Тукайның тәрҗемәи хәлен укып, бөек шагыйребезнең гомере буе рәхәт күрмәвен, шулай булса да, сәламәтлеген югалткач та, ахыр сулышына кадәр шигырьләр язып, халыкка сәгадәткә ирештерергә тырышуын аңлатып, Тукайны онытмаска, шигырьләрен күбрәк укырга тәүсыя итте вә хазирун тарафыннан бик алкышланды. Габделәхәт Тинеш Тукайның иҗатыннан бәхәс итеп, аның төрк-татар әдәбиятында тоткан урыны, төрк-татар милләтенең уянуында уйнаган гаять зур иҗаби роле хакында тәфсилле мәгълүмат бирде вә шулай ук бик алкышланды. Бу нотыклардан бик мөтәәссир булган Габделхәмид Таһир бәк сүз алып, мондый бөек шагыйрьгә малик булган төрк-татарларның тиз көндә кызыл җәлладлар кулыннан кортылуына ышануын белдерде. Моннан соң кырымлылар исеменнән Рәсим әфәнде Туган, төркестанлылар исеменнән Сөләйман әфәнде Мөхәммәд Ибраһим сүзләр алып, илебездән читтә шундый мәҗлесләр тәртип итүебез өчен рәхмәтләрен белдерделәр вә киләчәктә шундый мәрасимнәрне дошман кулыннан кортылган илләребездә уздыруны бөек Тәңредән теләделәр.

Бу сүзләрдән соң Ибраһим Хәсәннең бик оста итеп гармунда уйнаганы хәлдә күмәкләп «Туган тел», «Милли моңнар» җырланды вә бик алкышланды. Кырымлы кардәшләребез Кырым маршы «Ант әйткәнмен»не җырлап, мәҗлескә җанлылык керттеләр: Габделәхәт Тинеш үзенең соңгы сүзендә, мәҗлеснең рәсми кыйсеме тәмам булуын игълан итеп, кимчелекләребез булса, хазируннан гафу итүне үтенде вә тиз көндә газиз илебезнең истикъляллларына кавышуын теләп сүзен бетерде вә аякка басып тыңланылган «Сөембикә маршы» уйналу берлә милли рухлы мәҗлес тәмам булды.

**Мөхбир**

## ТУКАЙ КӨНЕ

***Харбинда***

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 26 ел тулу көне Харбин мәхәлләсендә самими вә күтәренке бер һава эчендә билгеләнеп үткәрелде.

Шагыйрьне искә төшерү мәрасиме апрельнең 15ендә көндез сәгать 2дә мәктәбе «Гыйният» укучыларының тупланышы белән башланып китте. Зал ата-аналар белән тулгач, мәктәп мөдире имам Мөнир Хисбулла кыска бер кереш сүзе белән мәҗлесне ачты.

Шәкертләр тарафыннан Коръән укылып, мәрхүмнең рухына багышланды. Моның соңында шул ук укучылар төркеме ниппонча гаскәри бер җыр җырлап, Сания Гыйффәтнең «Төрек маршы» көенә салынган «Углымның җыры»н иҗра итте.

Мәктәп укытучыларыннан Маһирә ханым Кодаки балаларга махсус сайлаган мәүзугында берничә сүз әйтеп узды. Тукайның гомер хәятыннан өземтәләр алып, аның чын бер балалар дусты булганлыгын үзенең «Иң бәһале»се белән балаларны дингә, вә «Туган тел»е белән тел һәм милләтебезгә мәхәббәт иттерүен, «Шүрәле»сендә үз илебезнең матур табигатен тасвир итүен сызып, киләчәктә Тукай көннәрен үз ватаныбызда каршы алырга насыйп булсын дигән бер җөмлә вә кунакчыл ниппон Манҗу-Тиго императорларына сәламәтлек теләү белән сүзен тәмамлады.

Моның соңында Тукай шигырьләрен аерым чыгышлар белән сөйләү башланды. Сәхнәләштерелгән «Шүрәле» белән «Су анасы» күренешләре уйналды. Соңгы күренеш өчен Су анасы һәм авыл малае рәсемнәре яшьләр түгәрәге әгъзасы Габдулла әфәнде Әхтәм тарафыннан махсус шул көнгә дип эшләнгән иде. Караучылар аның бу хезмәтен чын күңелләреннән тәкъдир иттеләр. Сүз җаенда әйтеп үтик, яшьләребез

арасында рәссамнарыбыз юк дәрәҗәсендә, шунлыктан бу аланда күренгән хәрәкәт безнең тарафтан алкышлана барырга тиеш.

* * *

Тукай көненең зурларга багышланган бүлеге кич башланды. Зал мәхәлләнең карты, яше белән тулды. Әхмәд әфәнде Виргаз шагыйрь хакында кыскача мәгърүзә ясап, аның яратышын тәхлил итеп күрсәтте.

Моның соңында Шәмсенур туташ Солтанның шәкертләреннән Мөнирә туташ Хисбулла пианинода «Тукай маршы»н уйнады, күмәкләшеп «Нигә үлдең, Тукай?» («Кара урман» көенә) җырланды. Сәхнәдәге авыл өенең тәрәзәсе ачылды да, ай яктысы төсендә яктыртылган күренештә чуар чыбылдык белән ярым каплаулы бишек янында моңлы бер ана сурәте җанланды. Бу — Тукайның «Авыл хатынының бала тирбәткәндәге өмидләре». Бу күренешкә Наҗия туташ, Рамазан белән Хөсәен әфәнде Габдүш катнаштылар. Ана ролен уйнаган Наҗия туташ, үзенең бик ягымлы вә моңлы тавышы һәм табигый хәрәкәтләре белән җырлап («Мөхәммәдия» көенә охшаш бер көйгә), тыңлаучыларның күңелләренә аерым бер тойгылар салды вә шигъри бер сурәт гәүдәләндереп муәфәкъ булды. Нәтиҗәдә, әлбәттә, самими алкышланды.

Хөсәен әфәнде бу күренеш ачылудан элек Тукайның яратышындагы төп кайгы вә хәсрәт сызыгы булуына тукталып үтте дә, Тукай дөньяга килгән чаклардагы аналар газиз балаларының бер әдип вә шагыйрь булып үсүләрен күрү идеалыннан ерак торалар иде әле, диде. Бу хакта сүзне озынайтып тормыйбыз, әнә ул сезнең каршыгызда, шул заманның җанлы бер анасының сурәте, диде. Күренеш тә башланып китте.

Әхмәд әфәнде Виргаз үзенең «Тукайга»сын һәм Тукайның бер шигырен сөйләп алкышланды. Маһирә туташ Лаеш шагыйрьнең «Киңәш» шигырен әйтешле иттереп сөйләп күрсәтте. Күмәк «Тәфтиләү» көенә «Мәхәббәт»не һәм үз көенә «Өзелгән өмид»не җырлады. «Зиләйлүк»не җырлаган Суфия туташ Чурай вә «Милли моңнар» белән чыккан Хөсәен әфәнде Габдүш көчле алкышлар белән каршы алындылар вә алкышлар астында сәхнәдән киттеләр.

Кичәнең уңышына һәрвакыттагыча пианино остасы Шәмсенур туташ Солтан бик күп ярдәм итте.

Килүчеләрнең күкрәкләренә «Тукай көне» диеп язылган тасма тамгалар кадалган иде. Сәхнә түрендә шагыйрьнең рәсеме, аның ике ягында Идел-Урал вә айлы-йолдызлы байракларыбыз һәм Ниппон вә Манҗу-Тиго байраклары асылган булып, диварларда бөек Кушлавыч ятименең шигырьләреннән өземтәләр элүле иде.

***Мукденда***

Мукден Идел-Урал төрк-татар мәдәният җәмгыяте карамагындагы яшьләр түгәрәге 15 апрельдә Тукай көне уңае белән мәктәп бинасында кич махсус бер тупланыш ясады. Җәмгыятьнең карты, яше, мәктәп шәкертләренә кадәр җыелып беткәч, түгәрәкнең рәисе Солтан әфәнде Аети тупланышның максаты моннан 26 ел элек вафат иткән мәрхүм шагыйрь Габдулла Тукайны искә алу икәнлеген аңлатты. Түгәрәк башкармасының вакытлы хәзинәдары Ибраһим әфәнде Яуш мәрхүм шагыйрьнең рухына багышлап Коръән укыганнан соң, халыкка «Габдулла Тукай 1913 — апрель, 15 — 1939» сүзләре язылган тасмалар таратылды. Мәркәз мәгариф шөгъбәсе тарафыннан Габдулла Тукайның вафатына 25 ел тулу уңае белән нәшер ителгән рисалә сатылды. Түгәрәк башкармасының әгъзасы Суфия туташ Агиш шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен озын итеп язылган мәгърузәсеннән укыды. Моннан соң Мукден радио стансасында түгәрәк башкармасының берничә әгъзасы тарафыннан концерт биреләчәк булганга, халык сабырсызлык белән 10 сәгать 40 минутны көтә башлады. Билгеләнгән вакыт җитү белән, радиодан Сөләйман әфәнде Аетиның «Тыңлагыз!» дигән тавышы ишетелде. Башта Сөләйман әфәнде шагыйрьнең кыскача тәрҗемәи хәлен үз телебездә, түгәрәк башкармасының кятибәсе Наилә туташ Рәхим шул ук мәүзугъны ниппон телендә сөйләделәр. Концертта Наилә туташ «Өзелгән өмид»не ялгыз җырлады. «Үтенеч» Наилә туташ һәм Ибраһим Яушлар тарафыннан парлап җырланды. Мәктәп шәкертләреннән кечкенә Морад Гыйззәтулла бик оста һәм ачык итеп «Эшкә өндәү» һәм «Үз-үземә»не сөйләде. Ибраһим әфәнде Яуш «Кичке теләк»не сөйләде. Концерт арасында радио стансасы тарафыннан ниппон телендә аңлатмалар бирелде. Вә концерт дәвамындагы җырлар Разыя ханым Ибраһим тарафыннан пианинода озатылып торылды.

Концерттан соң Рокыя туташ Мөхәммәдиш шагыйрьнең иҗаты хакында сүз сөйләде. Мансур әфәнде Арысланбәк «Осулы кадимче» һәм «Сөбханаллаһ»ны бик оста һәм килешле укып бик алкышланды. Ибраһим Яуш һәм Габделәхәт Хөсәен әфәнделәр «Өйләнү түгел сөйләнү» һәм «Егет белән кыз»ны башкардылар. Ахырда Морад Гыйззәтуллага радиоконцертка катнашуын котлап чәчәк бәйләме бүләк ителде.

Чәйдән соң җәмгыятьнең кятибе Әхмәтшаһ әфәнде Гыйззәтулла, Тукай кичәсе хакында сүз сөйләп, яшьләргә идарә исеменнән рәхмәт укыды.

**Мөхбир**

## КОБЕДА

15 апрельдә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 26 ел тулу мөнәсәбәте белән Аяринкай бинасында Әсгад әфәнде Әхтәмнең җитәкчелегендә Тукай кичәсе уздырылды.

Кобе Идел-Урал җәмгыяте рәис могавине Газиз әфәнде Гали Тукайга каратылган сүзләре белән мәҗлесне ачып, кичәнең тәртибе белән таныштырды. Мәктәп шәкертләре тарафыннан укыган Коръән шагыйрьнең газиз рухына багышланды. Тәрҗемәи хәле укылып, «Өзелгән өмид» Рәхилә туташ Садри һәм «Васыятем» Фәридә туташ Мостафа тарафыннан Фәридә туташ Агиның пианино моңына кушылып җырланды. Галия туташ Аги Тукайның «...га» дигән шигырен чыгып сөйләде.

Соңра мәктәп шәкертләре «Мияубикә» вә «Ел фасылы»н сөйләделәр, вә күмәк җыр белән «Таң» һәм «Идел-Урал маршы»н башкардылар. Газиз әфәнде Гали тарафыннан мәҗлеснең рәсми кыйсеме тәмам булуы игълан ителде вә шушы кичәне ясауда идарәнең үтенечен кабул итеп, көчен кызганмаган Әсгад әфәнде Әхтәмгә вә иштиракъ иткән яшьләргә, мәктәп шәкертләрен матур итеп хәзерләгән мөгаллимә Рабига ханым Дүешкә идарә исеменнән рәхмәтләр укылды. Вә (янә) ничә еллардан бирле һәрбер түпланышларның уртасында булып килгән Мәдъяр хәзрәт Шәмгуниның сырхау сәбәпле арабызда була алмавына тәәссеф итеп, тиз көннәрдә сәламәтләнүен һәм яңадан арабызда булуын теләде.

Җәмгыять рәисе Гыйсмәтулла хаҗи Әгерҗи идарә исеменнән «Газизәкәй балдыз» кичәсендә иштиракъ иткән яшьләргә идарә әгъзаларының вә сәхнәдә уйнаучыларның рәсемнәре ябыштырылган матур альбомны яшьләргә һәдия кылды.

Соңра яшь ханым вә туташлар тарафыннан чәй бирелде. Чәй арасында Хайлар мәхәлләсеннән килгән хөрмәтле кунакларыбыздан Хөснетдин әфәнде Сохи сүз сөйләп, мәктәп шәкертләренә 10 сум вә Гыйниятулла әфәнде Тинеш 5 сум бүләк итеп бирделәр. Тукай моңы, Тукай рухында гына үткәрелгән кичә сәгать 10да тәмам булды.

**Мәхрүсә Вафа**

## ТАМПЕРЕДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Идел-Урал төрк-татарларының олуг шагыйре Габдулла Тукайның вафатына 26 ел тулу мөнәсәбәте берлә Финляндиянең Тампере шәһәрендә Тампере төркләр берлеге тарафыннан зур күләмдә, гаять дәрәҗәдә уңышлы бер Тукай кичәсе уздырылды. Кичәдә Тампереда яшәүче бөтен милләттәшләр — яше-карты, баласы-чагасы берлә хәзер булган кеби, күптән түгел Финляндиягә тәшриф ителгән бөек юлбашчыбыз вә әдибебез Гаяз әфәнде Исхакый җәнаплары һәм Ләһстанның Вильно шәһәрендә яшәүче милләттәшебез Гаян Вәисизадә* әфәнде дә бу кичәдә безнең арабызда булып, кичәбезне шәрәфләндерделәр һәм барыбызны да гаять шатландырдылар.

Кичәне Тампере төркләр берлеге рәисе Ногман әфәнде Насыйбулла ачып, җыелган халыкка, билхасса кыйммәтле кунакларыбыз Гаяз әфәнде берлә Гаян әфәндегә «Хуш килдегез!» сүзләрен әйтеп, бөек юлбашчыбызның һәм Гаян әфәнденең бүген безнең арабызда булуларыннан долайы кальбендә тойган шатлыкларын белдерә.

Моннан соң сүз алган мөгаллимебез Габдулла әфәнде Мортаза, бүгенге истәлек кичәсенең ни өчен тәртип ителүе хакында вә олуг шагыйребезнең иҗаты хакында мәгълүмат биреп, кыйммәтле нотыгында: «Тукай бөтен илнең һәрнәрсәсен мөкатдәс санап, аны сөюче ватанпәрвәр иде. Хакларыннан мәхрүм ителгән илнең мескенлектә яшәүче халкын да сөюче милләтпәрвәр иде. Ул яшьтән үк милләт хезмәтенә атылды; ул иленең ятим угылы куәтле истигъдады саясында үзенең саф ачык телле шигырьләре берлә милләтен, халкын алга өндәде; милли эшләргә киртә тудыручыны тәнкыйть итте һәм аларның милли вөҗданын уятып, милләтнең алга китүенә аяк чалмауларын теләде. Тукай халыкчыл иде. Халык шагыйре исеме берничә еллардан соңра онытыла торган исем генә түгел. Халкыбыз яшәгән саен милли хисе артып, аның исеме берлә багланган Тукайның да хөрмәте артачак, үсәчәк», — дип сүзен тәмамлап, хазирун тарафыннан бик алкышланды.

Моннан соңра мәктәп шәкертләреннән Хәбибә Бәдретдин тарафыннан бик моңлы һәм матур иттереп Коръән укылып, савабы мәрхүм шагыйребезнең газиз рухына багышланды, мәктәп шәкертләре күмәкләп «Тәфтиләү»не җырладылар. Мөгаллимебез Габдулла әфәнде тарафыннан гаять яхшы хәзерләнгән шәкертләребез бик һәйбәт тел берлә, берәм-берәм чыгып, Тукай шигырьләрен әйтеп, вә күмәкләп «Туган

тел»не җырлап, халык тарафыннан самими рәвештә алкышландылар. Моннан соң мәрхүм шагыйрьнең «Бала белән күбәләк», «Шүрәле» һәм «Кәҗә белән Сарык» күренешен дә күрсәттеләр. Шәкертләр һәрберсе, өсләренә төшкән рольләрен бик оста үтәп, карауччыларның күңелен ачтылар. Билхасса утынчы егет ролендә Әсгад Байбулат һәм Шүрәле ролендә Мансур Байбулатлар рольләрен бигрәк оста башкардылар. Кечкенә Фализә Бәдретдин, кулына зур курчак тотып, шагыйрьнең «Бишек җыры»н матур итеп сөйләп, хазирунны бик көлдерде һәм, каты алкышланып, икенче кат та чыгарырга мәҗбүр ителде.

Күптән түгел Тампере төркләр берлеге тарафыннан оештырылган яшьләр хоры, «Милли моңнар», «Пар ат», «Әй мөкаддәс» һәм «Тукай маршы»н гаять моңлы иттереп җырлап, халыкта тирән тәэсир калдырып, бик алкышланды. Пианиноны исә яшь оста уйнаучыбыз Кадрия туташ Вафа алып барды. Туташларыбыз чәй мәҗлесен тәртип итеп буфетны башкардылар.

Кичәнең программы тәмам булгач, хөрмәтле юлбашчыбыз Гаяз әфәнде Исхакый җәнаплары өзлексез алкышлар эчендә сәхнәгә менеп, үзенең бүгенге истәлек кичәсеннән мәмнүн калуын, балаларның бөтен җырларын сөенеп тыңлавын сөйләп, бүгенге кичәне тәртип итүдә иң күп көч сарыф иткән мөгаллим әфәндегә, шәкертләргә һәм яшьләргә чын күңелдән рәхмәтләрен укуын белдерде. Бөек әдибебез сүзенең дәвамында илдән читтә яшәргә мәҗбүр булган халкыбызның үзлеген саклап калып, милли тәрбия бирер өчен мондый кичәләрнең ни дәрәҗәдә әһәмиятлелеген аңлаткач: «Тукай ятим үсеп, ятим яшәп, 27 яшендә ятим үлгән бер кардәшебез. Аның күрмеше татсыз булганга, ул халкының кайгысын да үзенең эчендә хис итеп кайгырткан. Тукай халкыбызның бәхетле, бәхетсез хәлләрен барыбыз аңлардай иттереп язып, көйгә салып, такмаклап биргән. Шуның өчен фәкыйрь, ятим Тукайның үлүенә 26 ел тулгач та, аның хөрмәте олуглана гына бара. Аның байлыгы аны онытмаска чакыра һәм бу көннәрне ясаттыра. Тукай мөһаҗәрәттәге балаларны бер арага җыя. Тукай үзенең тырышлыгы аркасында зур кеше булып өлгергән. Ел үткән саен, аның зурлыгы да үсә бара, — дигәннең соңында, яшьләргә вә картларга каратып: — Сез дә тырышсагыз, халыкның шатлыгын, кайгысын кайгыртышып торсагыз, зур-зур кешеләр булырсыз. Илебездә хәзергә һичнәрсә эшләргә имкян юктыр. Хәлбуки, сез монда теләгән нәрсәләрегезне теләгәнчә эшли аласыз. Менә шуннан файдаланып, вакытны бушка уздырмаенча, тырышып, чын милләтче, укыган кешеләр хәзерләгез. Бу сезнең барыгызның өстегезгә йөкләнгән мөкатдәс вазифадыр. Бөтен эшләрегездә бер дә берлекне югалтмагыз, барыгыз да бергә хәрәкәт итәргә тырышыгыз! Барыгызга да Аллаһ хәерле тормыш биреп, балаларыгызга зур бәхет ихсан итеп, илләренә хезмәт итәргә язсын!» — дип, зур ихлас берлә тыңланган сүзен алкышлар эчендә тәмам итте. Моннан соң кыйммәтле илдәшебез Гаян Вәисизадә әфәнде сүз алып, кальбендә бүгенге кичәдән долайи тойдыгы рәхмәтләрен белдереп: «Яшәсен төрк халкы, яшәсен сезгә мондый милли кичәләрне эшләүдә хөрлек бирүче фин милләте!» — дип сүзен бетерде вә алкышланды.

Шуның берлә сәгать җидедә башланган кичә милли хис эчендә төнге сәгать уникедә тәмам булып, берлекнең рәисе Ногман әфәнде Насыйбулла тарафыннан кичәгә килгәннәре өчен кыйммәтле әдибебезгә, Гаян әфәндегә һәм җыелган халыкка рәхмәтләр укып, мәҗлесне яптылар. Халык та, Тукай моңы астында бу матәмле истәлек кичәсеннән теләр-теләмәс кенә аерылып, өйләренә таралды.

## БЕРЛИНДА ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Халык шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 15 апрельдә 26 ел тулу мөнәсәбәте берлә Берлиндагы милләттәшләребез Тукай кичәсе ясап үттеләр. Бу мәҗлес «Милли юл» идарәсе тарафыннан эшләнеп, мәҗлескә үз ватандашларыбыз чакырылган кеби башка төрк кабиләләреннән мөмәссилләр дә дәгъвәт ителгәннәр иде.

Мәрасим Хәсән әфәнде Аги тарафыннан ачылып, Гайни әфәнде Госман Коръән укыгач, сәвабы мәрхүм шагыйребез һәм моннан биш ел элек 5 апрельдә Варшауда вафат иткән истикъляллчыларыбыздан булган Гариф Кәримиләрнең рух шәрифләренә багышланып дога кылынды. Догадан соң Әхмәт әфәнде Тимер шагыйрьнең тәрҗемәи хәлен укып чыккач, кунакларга чәй тәкъдим ителде. Чәй арасында шагыйрьнең шигырьләре укылып, тупланыш милли хис эчендә төн уртасына кадәр сузылды.

**Хәбәрче**

## ХАЙЛАРДА ТУКАЙ КӨНЕ

15 апрель Тукай көне мөнәсәбәте белән ул көнне Хайлар төрк-татар мөселман мәктәбендә укулар булмады.

Ошбу көнне аерым сызып үтү, халык шагыйре Габдулла Тукайны искә алуның әһәмияте безнең милли-мәдәни хәятыбызда никадәре зур урын тотканлыгын яшүсмерләребезгә яхшырак аңлату фикере белән вә бөек шагыйребезнең вафатына 26 ел тулу уңае белән мәктәп һәйәте тәгълимиясе тарафыннан көндез сәгать 2 дә бөек шагыйребезне искә алу мәҗлесе ясалды.

Мәзкүр мәҗлескә мәхәлләнең могтәбәр әгъзалары да рәсми рәвештә дәгъвәт ителгәннәр иде. Шәкертләрнең ата-аналары вә яшьләр белән мәктәп залы шыгрым тулы иде.

Мәҗлеснең рәсми кыйсеме сәхнәдә үтәлеп, Ниппон, Манҗу-Тиго, дини вә милли байракларыбыз белән бизәлгән сәхнәнең уртасында мәрхүм шагыйребезнең зур итеп эшләнгән рәсеме мәҗлескә аерым бер матурлык бирә иде.

Мәктәпнең мөдирәсе Зөһрә туташ Күгүш мәҗлесне ачып, көннең әһәмиятен вә тупланышның максатын халыкка аңлаткач, шәкертләр тарафыннан Коръән укылып, бөек шагыйребезнең рухына багышланды.

Моннан соң Габдулла Тукайның тәфсилле тәрҗемәи хәле, мәктәпнең югары сыйныф шәкертләре: Афзал Тинеш, Әдип Таһир, Шәүкәт Айгынин, Шәүкәт Сохи һәм Газиз Агилар тарафыннан бүленеп, бик осталык белән сөйләнде.

Зөһрә туташ Күгүш «Тукай — халык шагыйре», «Тукай теленең хосусияте», «Соңгы зарлары» мәүзугъларында мәгърузә ясады.

Мәгълүм Шаһәгъзам әфәнде Кирүш «Тукайда милли хис» мәүзугында мәгърузә ясады.

Соңрак әдәбият бүлеге ачылып, шәкертләр тарафыннан бер-бер артлы Тукайның энҗе бөртекләре зур осталык белән сөйләнделәр.

«Тукай маршы» җырланганнан соң, мөдирә туташ тарафыннан мәҗлеснең ябылуы игълан ителде.

**Тыңлаучы**

## ХАРБИНДА

Сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына 26 ел тулу мөнәсәбәте белән Харбин Идел-Урал төрк-татар яшьләр түгәрәге 15 апрельдә кич сәгать 5тә Тукай истәлеге хөрмәтенә радиоконцерт бирергә булган иде. Һәм шул хакта телеграммалар белән Мукден, Гизин, Синьзян, Хайлар вә Кобе идарәләренә хәбәр дә бирелгән иде. Әмма шул көн 5 сәгатьтә Токиодан трансляция булу сәбәпле, Тукай көненә багышланган концерт 17 апрель, кич сәгать 5кә кичектерелде.

Радиоконцерт яшьләр түгәрәге рәисе Әнвәр әфәнде Акчураның, бу концертның Идел-Урал төрк-татарларының бөек шагыйре Габдулла Тукай истәлегенә багышланып, аның әсәрләреннән бирелүен аңлатуы белән башланды. Бу кереш сүзләр русчага тәрҗемә кылынганнан соң, яшь һәвәскәрләребездән Таһирә Лаеш, Суфия Чурай, Наҗия Рамазан, Сәгъдия Агиш туташлар, Хөсәен Габдүш, Сәгыйд Килки, Әмрулла һәм Мәхмүд Дүеш, Заһидулла Чурай һәм Фатих Бикбай әфәнделәр тарафыннан Шәмсенур туташ Солтанның пианинода уйнавына кушылып, күмәкләп «Нигә үлдең, Тукай?» дигән җырын җырладылар. Күмәк җыр ифрат көчле һәм матур чыкты. Илһам яисә энҗе данә шагыйрьләрен югалтуны тирән моң белән зарланып аңлату чын безнеңчә иде. Шул ук күмәк, Тукайның «Өзелгән өмид»ен бик төз һәм моңлы итеп җырлап, Тукай моңын Ерак Шәрыккә чәчте.

Суфия туташ Чурайның матур тавыш белән шагыйребезнең «Мәхәббәт» шигырен «Тәфтиләү» көенә моңлы һәм ачык итеп җырлавы үз халкыбыздан мөрәккәб тыңлаучыларда тирән тәэсир калдырды.

Хөсәен әфәнде Габдүш, Тукайның «Милли моңнар»ын куәтле тавыш, тирән хис, чиксез моң белән җырлап, «өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирде татар күңеле ниләр сизгәнен». Ошбу чыгыш аерым сызып үтәрлек дәрәҗәдә яхшы булганга, вә чит халыктан тыңлаучыларга да яхшы тәэсир итәр дигән ышаныч куәтле булганга, арабызда шундый сәнгатькәрләребезнең булуына күңел куаныч һәм милли горур белән тулды.

Наҗия туташ Рамазан, моңлы һәм ягымлы тавышы белән Тукайның «Авыл хатынының бишек тирбәткәндәге өмидләре» дигән җырын җырлап, татар хатынының бала тирбәткәндә туган татлы өмидләрен, татлы хыялларын моң һәм саф тавыш белән табигый рәвештә моңлы чыгарды.

Концерт Шәмсенур туташ Солтанның гадәттәгечә тирән хис белән ачык итеп уйный торган «Тукай маршы» белән тәмам булды.

**Габделкәрим Рәхим**

## МИЛЛИ ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАП

Хөрмәтле бөек шагыйребез Губдулла Тукай хакында «Милли байрак» җаридәсендә ничә еллар буена төрле мәүзугъта мәрхүмнең тәрҗемәи хәле һәм иҗаты мөкәммәл рәвештә язылып килгәндер. Бинаән галәйһи, бу урында аның тәфсилатенә керешергә ихтыяҗ юктыр. Ләкин бөек шагыйребезнең вафат булуына утыз ел үтү мөнәсәбәте илә мәрхүмне ядкарь һәм ихтирам кылу йөзеннән түбәндәге берничә җөмләне сызып үтәм.

Мәрхүм шагыйребез Тукай төрк-татар шагыйрьләренең иманы, тел вә әдәбиятыбызны зиннәтләүче бик сирәк табыныла торган бер остаз иде. Үзенең кыска гына бер гомер парчасында аз гына заманда төрк-татар тел вә әдәбияты олуг бер маддә җәүһәр илә зиннәтләде. Милләтенең яшь буыннарына бетмәс-төкәнмәс зур бер дәүләт һибә итеп дөньядан кичте. Аның шигырьләре галәм әһелләренең күкрәкләрене ялтырата, күзне нурландырадыр. Ул мөбарәк, гомумән, безнең милләт әдәбиятыбызга зур бер байлык инсан итте.

Бу көнгә кадәр Тукайның мәгънән шәкертләре булган мөһаҗәраттәге яшьләребез күңелләрендә кайнап чыккан дини, милли хисләр вөҗүдкә ашырган моңлы шигырьләре «Милли байрак» җаридәсендә 7 ел дәвамында язылып килде вә язылып тормактадыр.

«Милли байрак»та язылып тормакта булган бу шигырьләр халыкларыбызның күңелләрендә бер нурлы кызыксыну тудырды вә сөелеп укылдылар һәм укылмактадырлар. Мәзкүр шигырьләр диңгезгә яуган ягъмур тамчылары гаиб булган кеби югалып, гаиб булып китмәсеннәр өчен бу шигырьләрне бу санда бер җиргә җыеп, китап буларак басып чыгару мәтлубтыр. Бу китап чит илдәге халыкларыбыз өчен бердәнбер җан азыгы булачак һәркайсы да мәгалмәмнүниять акчаларны биреп, бу китапларны алачаклардыр. Бу шигырьләрнең китап буларак басылуы горбәттәге шагыйрьләребезнең дәртләрен арттыру, рухларын күтәрүдә хезмәт итү белән бәрабәр. Алар өчен аз гына бер нәрсә булса да, мөкяфәт урынына да туачактыр. Шулай ук мөһаҗәраттәге халыкларыбызга укыр өчен күңел таянычы бер китап та булыр иде. Мәркәз башкарма гәзитендә милли мәктәп дәреслекләре бастырырга махсус тупланган акча булса, шундый кирәкле әдәби китапларны бастырырлык аерым бер фонд, тәәссефкә каршы, мәркәзебездә юктыр. Ихтимал ки, бәгъзе бер дәүләти сәүдәгәрләр бу китапның басылу мәсарифен бөтенләй үз өстләренә алулары да мөмкиндер.

**Мәктәп мөхбире**

## ХАЙЛАРДА ТУКАЙ КӨНЕ

Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына утыз ел тулу истәлеге, яшьләребезнең күбесе Хайлардан читкә китүләре сәбәпле, 14 апрельдә үткәрелде.

Бу мәҗлес мәктәп һәйәте тәгълимиясе вә яшьләр түгәрәге белән берлектә ясалган дүрт бүлектән гыйбарәт иде: 1 нче көнгә — гаид мәгърузәләре, 2 нче — мәктәп бүлеге, 3 нче — чит урта мәктәпләрендә укучы шәкерт бүлеге һәм яшьләр түгәрәгенең аң-белем тарату бүлеге.

Мәҗлесне алып баручы итеп Тукай һәйәтләре тарафыннан милли идарә рәисе могавине Фатыйх әфәнде Илбәк сайланган иде.

Мәҗлес мәктәп бинасында кичке сәгать 6га тәгъйин ителгән иде. Сәхнәдә мәрхүм шагыйрьнең рәсеме күренеп тора, сәхнәнең алды Ниппон, Манҗу-Тиго һәм үзебезнең милли байракларыбыз белән бизәлгән иде.

Мәҗлес рәисенең кереш сүзе белән ачылды. Әбрар хәзрәт Акбирде тарафыннан Коръән укылып, мәрхүм шагыйребез Габдулла Тукай вә мөфтиебез Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең рух шәрифләренә багышланды. Байракларга хөрмәт күрсәтү рәсмияте үтәлде. Корбан булган гаскәриләр бер минутлык тынлык белән искә алынды.

Шагыйрьнең тәрҗемәи хәле яшьләр түгәрәге рәисе могавине Шәфигулла әфәнде Хаҗи тарафыннан укылды. Мәктәп мөдире Фатыйма ханым Акчура «Тукай вә балалар», Маһинур Акбирде «Тукайны күмү мәрасиме», Зөһрә ханым Кирүш «Төрк-татар әдәбиятының кояшы — Габдулла Тукай», Әхмәтсафа әфәнде Аги «Вафатына утыз ел тулу уңае белән», Зиннәт туташ Нурмөхәммәт «Тукайны искә алганда», Хәдичә ханым Күгүш «Тукайны искә алу», Шаһәгъзам әфәнде Кирүш «Тукайны искә алу», Зөһрә Сизгән «Тукай — халык эшчесе», Килтан Таһири «Бөек шагыйрьгә баглап», Рокыя туташ Сиракляз «Тукай вә милләт» мәүзугындагы мәгърузәләр укыдылар.

Мәктәп шәкертләре бүлеге «Тукай маршы»н күмәкләп җырлау белән башланды. «Шагыйрьгә» шигыре сөйләнде. Тукай шигырьләреннән «Үз-үземә», «Туган тел», «Пар ат», «Эш», «Туган авыл» сөйләнделәр. Ике шәкерт тарафыннан «Иртә» җырланды. «Бичара куян», «Кызыклы шәкерт», «Су анасы», «Бала белән күбәләк» җанлы күренешләрдә күрсәтелделәр. Шәкертләр программасы «Васыятем»не күмәкләп җырлау белән тәмам булды.

30 нчы югары халык мәктәбендә укучы шәкертләребез «Тәэсир» вә «Өзелгән өмид» шигырьләрен җырлап алкышландылар. Аерым чыгышларда «Ике иптәш арасында» һәм «Сөекле шагыйрьгә» үтәлде. Тукай көйләре кыллы коралларда уйналды.

«Аң-белем тарату һәйәте» тарафыннан хәзерләнгән 4 нче бүлектә дә шагыйрьнең «Кемне сөяргә кирәк?» — Зөһрә ханым Кирүш, «Нигә үлдең, Тукай?» — Рокыя Айгыйин, «Казанга китү» — Зиннәт Нурмөхәммәт, «Сабыйга» Азат Сохи һәм Фатыйха Күгүшләр тарафыннан бик матур итеп җырландылар. Югары мәктәп шәкертләреннән Әнвәр Аги Кәман да «Васыятем» көен оста уйнап алкышланды.

Сәхнә бүлекләре тәмам булгач, мәҗлес рәисе Фатыйх әфәнде Илбәк шушы истәлекне вөҗүдкә китерүче һәйәтләргә рәхмәтләрен белдерде. Шушы мәҗлескә мәгърузәләр вә Тукай шигырьләрен сөйләп катнашкан оешмабызның туплануына аерым рәхмәтләрен белдерде. Киләчәктә милләтебез эченнән Тукай кебек дамелланың чыгуын теләп сүзен тәмам итте.

Гомумән, милли шагыйребезне искә алу мәҗлесе картыбыз-яшебез, бала-чага бергә тупланган хәлендә мәктәп бинасы шыгрым тулы булып, бөек хиссият эчендә узды. Җыелган халык, бик мәмнүн булып, сәгать 10да таралды.

**Мөхбир**

## БӨЕКЛӘРЕБЕЗНЕ ИСКӘ ТӨШЕРГӘНДӘ

Апрель үндүрте, унбише һәм унсигезе Идел-Уралның бөекләре хатирәсе белән багланганлыктан, бу көннәр Нагоя Идел-Урал төрк-татар мөселманнары мәдәният җәмгыяте карамагындагы милли мәктәптә аерым рәвештә сызылып узылдылар.

Апрельнең 14ендә илебезнең бөек галиме һәм мөфтисе Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләренең вафат булуына җиде ел тулу уңае рухына багышлап, намаз һәм Коръән укылды.

Мәктәптә укытучы Зәйтүнә туташ Шакир шәкертләргә Ризаэтдин хәзрәт, шагыйрь Габдулла Тукай һәм атаклы галимебез Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре хакында сөйләде. Апрельнең 18 ендә бу мөхтәрәм затның вафат көне булуын аңлатып, Шиһаб хәзрәтнең милли тарихыбызга булган хезмәтләрен сөйләп бирде. Ахырда шәкертләрне төрк-татар каберстанына алып барып, вафат булганнарның рухларына Коръән укылды.

Тукайның вафатына утыз ел тулу уңае белән мәктәп залында зур тупланыш ясалып, бу мәҗлестә җәмгыятьнең бөтен әгъзалары һәм шәкертләр дә хазир булдылар.

Тукайны искә алу имам Хәсән әфәнде Килки тарафыннан укылган Коръән белән башланды. Милли байракларга хөрмәт күрсәтелде вә корбан төшкән Ниппон гаскәрләре хөрмәтенә бер дәкыйка сөкүт сакланды. Җәмгыять рәисе Тимербай Хәмидулла һәм Дәүләтшаһ Сизгән әфәнделәр Габдулла Тукайның иҗаты белән таныштырдылар.

Моннан соң сәхнә бүлеге башланды. Нурия Хәмидулла һәм Касыйм Сәедгали «Бала белән күбәләк» һәм «Туган тел»не җырладылар. Әдһәм Килки һәм Әсгад Сизгән «Бичара куян»ны сөйләделәр. «Кәҗә белән Сарык хикәясе»ндә Хәсәнулла Сәедгали — кәҗә һәм Сәгыйдь Хәмидулла сарык ролен башкардылар.

Зуррак шәкертләр «Урал суы буенда» пьесасын уйнадылар. Шәмсенур Сәедгали, Маһинур Сизгән, Сәгыйд Хәмидулла, Әдһәм Килки һәм уенга катнашкан башка шәкертләр рольләрен бик яхшы башкардылар.

## МАНҖУРИЯДӘ УТЫЗ ЕЛЛЫК

Ошбу 15 апрельдә, Манҗуриядә Идел-Урал төрк-татарлары милли идарәсенең карары буенча, мәктәп шәкертләре тарафыннан шагыйребез Габдулла Тукайның вафатына утыз ел тулу уңае белән әдәбият кичәсе ясалды.

Мәктәп шәкертләре тарафыннан укылган Коръәннең савабын мәрхүм Габдулла Мөхәммәдгариф углы Тукайның рух шәрифләренә багышлап дога кылганнан соң, шагыйрьнең тәрҗемәи хәле сөйләнде. Мөгал-

лимә Мәйсәрә туташ Нәбиулла тарафыннан өйрәтелгән шәкертләр Тукай шигырьләрен сөйләделәр. Балалар чыгышында «Уянмас йокы»сы уйналды. Һәрбер шәкертнең шигырьләрне осталык белән үтәве кичәнең көтелгәннән артык күңелле үтүенә сәбәп булды. Ахырда шәкертләргә һәм кичәгә килгән халыкка чәй бирделәр. Сәгать 8дә башланган кичә төнге 2гә кадәр тартылды.

## ТУКАЙНЫҢ УТЫЗ ЕЛЛЫГЫ СИНКИН ҖӘМГЫЯТЕНДӘ

Синкин Идел-Урал төрк-татар мәдәният җәмгыяте идарәсе бөек шагыйребез Габдулла Тукайның үлүенә утыз ел тулуны истәлек мәрасиме белән билгеләп узды.

Әлегә кадәр идарәбезнең үз йорты булмау сәбәпле, милли барлыгыбыз белән баглы булган шундый көннәребез вә милли дини бәйрәмнәребезне тәрле җирдә үткәрергә туры килеп, оешма тормышыбызга кирәкмәгән уңайсызлыклар туа торган иде. Шул кимчелекләрне каплар өчен идарә иҗарәгә булса да йорт алырга карар итеп тәшәббескә кереште. Вә әгъзаларның күбрәге яши торган Коаунчинзеда (Синкинның бер урамы) бер йорт алып, шуны яхшылап төзәттерде һәм җәмгыять өчен кирәк булган җиһазлар алды. Җәмгыятебезнең бинасын ачу мәрасимендә илебезнең атаклы шагыйре Габдулла Тукайның истәлеге көнен дә уздырырга карар кылынды.

Истәлек кичәсе 15 апрельдә уздырылып, кичәгә барча әгъзаларыбыз килгәннәр вә милли хәрәкәтебез белән кызыксынучы ниппонлы дусларыбыз да тәшриф ителгәннәр иде. Шулар арасында: Си-ху-хой оешмасыннан мәркәз бүлегенең башлыгы Яма-сан, аның ярдәмчесе Дауви-сан, полис мөдирияте әҗнәби бүлеге башлыгы Иссаси-сан бар иде.

Идарә йортыбыз яшәдегебез илләренең һәм үзебезнең милли байрагыбыз белән бизәлгән түргә урта бер җирдә бөек юлбашчыбыз Гаяз әфәнде Исхакыйның рәсеме эленгән. Як-якка Габдулла Тукай, мөфти Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләре, Шәркый Асиядәге мөфтиебез мәрхүм Мәдъяр хәзрәт Шәмгунинең рәсемнәре куелган вә Тукайның ялкынлы сүзләре язылып куелган иде.

Истәлек кичәсенә барлык әгъзалар катнашсыннар өчен, шул көнне бөтен төрк-татар кибетләре өйләдән соң ябылып, көндез сәгать 5тә җәмгыять рәисе Фәссахетдин әфәнде Гыйльмани мәҗлесне ачты. Башта идарә йортыбызның ачылу рәсмияте үтәлеп, шуннан соң бөек шагыйребезгә багышланган истәлек мәрасиме үтеләчәге игълан ителде. Галинур әфәнде Мөхәммәтҗан Коръән укыды, дәүләте тәгъзыйм рәсмияте үтәлде. Бөек Шәркый Асия сугышында корбан төшкән каһарман ниппон гаскәрләре хөрмәтенә бер дәкыйка тынлык сакланды. Идарә рәисебез йортыбызның ачылу шатлыгын бүлешергә килгән кунакларга рәхмәт укыды. Әгъзаларыбызны ачылган бинабыз янында берләшеп хәрәкәт итәргә чакырды. Идарә кятибе Әмрулла әфәнде Аги әгъзаларны идарә йортының ачылуы белән тәбрик итте. Милли хәрәкәтебез вә дөньяның бүгенге барышы хакында сөйләде. Большевик хәрәкәте һәм англо-саксон хуҗалыгы кулындагы мөселманнарның аяныч вазгыятьләренә тукталды. Яшьләрнең милли тәрбияләренә игътибар итәргә тиеш булу хакында һәм киләчәгебез өчен милли хәрәкәтебездә нык булуның әһәмиятен аңлатып, бүгенге сугышта Ниппонның вә мөттәфикъларының җиңеп чыгуларын теләде. Галинур әфәнде Мөхәммәтҗан үз бинабызның ачылуы белән котлады вә дини рухны куәтләндерергә чакырды. Яшьләр түгәрәге рәисе Заһидулла әфәнде Ишкин яшьләрнең идарә йорты янында берләшәчәкләрен вә моңа кадәр хәрәкәтсез яшәгән яшьләребезнең яңа ачылган [...]* йөрәктән котлауларын белдерде. Таһирә ханым Кодаки сүз алып, идарә йорты ачылуын тәбрик итте. Идарә рәисе һәм идарә кятибенә бу эшне вөҗүдкә чыгаруда бик күп хезмәт сарыф итүләрен, безгә ирек бирүдә хөкүмәт даирәләренә тәшәккерләрен белдерде. Яшьләрне берлеккә чакырып, милли хәрәкәтебезгә ят булган фикерләрдән ерак булырга үтенде вә ялкынлы нотыгын Тукайның милләтебезгә каратып әйткән сүзләре белән бетереп, халык тарафыннан алкышланды. Шуның белән идарә йорты ачылуга каратылган сүзләр тәмам булып, Габдулла Тукай истәлегенә күчелде.

Галинур әфәнде тарафыннан Коръән укылып, савабы шагыйребез Габдулла Мөхәммәдгариф углы Тукай һәм вафатына апрельнең 14ендә җиде ел тулган мөфтиебез Ризаэтдин бине Фәхретдин җәнапларының рухларына багышланды. Идарә кятибе Габдулла Тукай һәм Ризаэтдин бине Фәхретдиннәрнең тәрҗемәи хәлләре һәм халкыбызга калдырган кыйммәтле мираслары хакында мәгълүмат бирде.

Моннан соң әдәбият бүлеге башланып, яшьләр күмәге тарафыннан шагыйрьнең үз әсәрләреннән «Өзелгән өмид» һәм «Милли моңнар» җырланды. Фәризә, Фәгыйлә Аги туташлар һәм Шамил әфәнде Таһирлар «Уянмас йокы»ны көйләделәр. Вәли Рамазан, Шамил Таһир «Егет белән кыз»ны бик оста итеп баш-

кардылар. Шәкертләрдән Камил Гыйльмани «Чын вә Ялган»ны, Зәкиулла Мигрин «Эш»не сөйләп алкышландылар.

Ханымнар тарафыннан кунакларга чәй тәкъдим ителде. Чәй дәвамында балалар тарафыннан Тукай шигырьләре сөйләнде. Бигрәк тә 5 яшьлек Зөләйха Арыслангәрәй, 4 яшьлек Рәшидә Аги һәм 2 яшьлек Фуад Агиларның чыгышлары туктаусыз алкыш белән каршы алындылар.

Ахырда идарә кятибе сүз алып, йортны иҗарәгә алуда һәм аны төзәтү вә кирәк яраклар белән тәэмин итүдә матди-мәгънәви булышлыгы зур булган идарә рәисенә рәхмәтләр укыды һәм идарәнең рәис әфәндегә ике мең гоби бурычлы икәнлеген белдерде. Бу — безнең халыкның оешма эшләре илебездә, мөһаҗәрәттә дә, фәкать үз җилкәсендә генә яшәгәнлеген сөйләп, шушы мәҗлестә үк әлеге бурычны каплар өчен иганә җыярга тәкъдим ителде.

Идарә рәисе үзе 500 гоби иганә итүен игълан итте. Моңа башка әгъзалар да катнашып, шул арада бер мең сигез йөз ун сум акча тупланды.

Заһидулла Ишкин, Шакир Хәмидуллалар 250, Хәсән Арыслангәрәй, Хөсәен вә Әмрулла Агилар 200, Исмәгыйль Кямкин 100, Галинур Мөхәммәтҗан, Нуретдин Һадиулла, Сираҗетдин Кодакилар 50, Фатыйх Рамазан 30, Әмрулла, Сәгыйдә Диүшләр, Хәмзә Бирики (Фосин) 25, Габдеррахман Асан, Гали Айгын (Кирин), Гариф Әхмәд 20 — барлыгы 1810 гоби.

Яңадан чәйгә утырылды. Кичә милли моң эчендә 11 сәгать ярымга кадәр дәвам итте. Рәис әфәнде кунакларга вә мәҗлесне корышкан ханым һәм туташларга рәхмәт укып тупланышны япты.

## АМЕРИКА ХӘБӘРЛӘРЕ

1973 елның 29 апрелендә җәмгыять рәисе хөрмәтле Салих Апакайның гадәти оста эшчәнлеге белән Тукай кичәсе үткәрелде.

**Әмрулла Аги**

## ИСТАНБУЛ ХӘБӘРЛӘРЕ
## ТУКАЙ КИЧӘСЕ

Казан төркләре мәдәни һәм үзара ярдәмләшү җәмгыяте тарафыннан 1974 елның 26 май көнендә җәмгыять клубында милли шагыйребез Габдулла Тукай вафатының 61 елы тулу уңае белән бер истәлек көне уздырылды.

Истәлек кичәсендә Истанбул һәм Әнкарада яшәүче якташларыбыз, Төркестан кардәшләребез катнаштылар. Кичә Фәрит Бичуриның җыелышның әһәмиятен күрсәткән чыгышы белән ачылып, мәгълүм Шамил Алукай шагыйрь Тукай тормышын киң бер рәвештә алган лекциясендә күзәтү ясады. Шуннан соң Чыңгыз Айгөн, Фатыйх Айгөн һәм Әльмира Гүвән Тукай шигырьләреннән үрнәкләр бирделәр. Пьеса авторы һәм шагыйрь Шаһвәли Келәүле Илдәрнең «Асламчы» исемле әсәренең сәхнәгә куелуы белән дәвам итте.

Әнкаралы якташларыбыздан Рәсим Бәгъдәш белән истанбуллы Нәргис Күгүш белән берлектә ике милли уен күрсәттеләр, янә Әнкаралы якташларыбыздан Зөһрә Кирүш тә кичәнең вә Тукайның Казан төркләре өчен әһәмиятле роль уйнавын күрсәтте һәм истәлек кичәсе ихтирам ителгән милли ашларыбыздан корылган чәй мәҗлесеннән соң тәмам булды.

*** * ***

Җәмгыятебезнең мәдәни эшчәнлегеннән булган Тукай истәлек көнен апрель аенда үткәрү мөһим. Бу кичәне бөтен әгъзаларыбыз Казан төрк әдәбиятының онытылмас кояшы Габдулла Тукайга лаеклы бер рәвештә (формада) оештырылуын телиләр. Моның өчен дә бу кичәдә Казан төркләренең театрыннан, фольклорыннан һәм милли ашларыбыздан мосафирларыбыз үрнәкләр күрсәтү теләкләрен белдерделәр. Бөтен эшләнмәләрне оештыру өчен бигрәк тә хатын-кызлар белән яшь әгъзаларның олы ярдәменә ихтыяҗ бар. Аеруча апрель аенда балаларыбыз өчен 23 апрель Балалар бәйрәмен матур итеп билгеләп үтү, май аенда газап чигүче аналарыбыз көне булган Аналар көне, аларны гүзәл бер шәкелдә котларга телибез. Язда һәм җәен җәмгыять әгъзаларыбыз өчен кырга һәм диңгезгә чыгарга, аеруча тирә-юньне тану йөзеннән туристик сәяхәт ясау теләгебез җәмгыятебезнең мәдәният эшчәнлегенә бәйләнешле, һәммәсен белгән кебек «Казан» мәҗмугасы таратуны дәвам иттерүдәдер. Мәҗмуганы бастыруда һичбер матди ярдәм буларак шартлар тудыруда эшләгән якташларыбызга никадәр рәхмәтләр әйтсәк тә аздыр. Фольклорыбызны Төркия тарафында танытыр өчен ТРТ белән мөнәсәбәт урнаштыру кирәк булды. Истанбул радио-

сыннан теләсә нинди бер программада Казан төркләре фольклор музыкасын билгеле вакытларда радиодан тарату өчен мөрәҗәгать тә ителгән иде. Җәмгыятебезнең зур мәсьәләсе булган җирле проблеманы хәл итү өчен рәисебез Әхмәтвәли Мәңгәр бәйнең җитәкчелегендә эшкә керешергә булынды. Максатка ирешү өчен бөтен члennарыбызның да матди ярдәм итүләренә ихтыяҗыбыз бардыр. Үтенечебез: взнос бурычлары булган членнарыбыз иң кыска вакытта бурычларын түләсеннәр иде.

Сүземне тәмамлап, чакыруыбызга килгән бөтен член һәм якташларыбызга рәхмәтемне белдерәм.

## ӘНКАРА ХӘБӘРЛӘРЕ

23 апрель көнне җәмгыять бинасында Милли бәйсезлек, Балалар бәйрәме һәм милли шагыйребез Габдулла Тукайны искә алуны берлектә котладылар. Зөһрә Кирүш ханым 23 апрельдәге әһәмиятле темага чыгыш ясады, җәмгыятьнең рәисе Садия Кирүш ханым да ачылыш тантанасында чыгыш ясады. Балалардан төзелгән хор 23 апрельгә бәйләнешле җырлар җырладылар һәм шигырьләр укыдылар. Гаяз Акчура аккордеонда һәм Нәгыймә Сәзгән мандолинада уйнап тордылар. Аеруча кечкенә кызлардан төзелгән фольклор ансамбле фольклор уеннарын югары осталык белән башкардылар һәм килгән мосафирлар тарафыннан ярату һәм хуплау белән алкышландылар. Төркемдә булганнар: Эльмира Кодаки, Наилә Моззафар, Нәгыймә Сәзгән һәм Нурия Айгөннәр.

Аннан соң Тукайны искә алу көне дә ясалды һәм Зөһрә ханым Тукайның балалар өчен язылган шигырьләре һәм аның әһәмияте хакында доклад сөйләде. Соңыннан Тукай шигырьләре һәм җырлары җырланды. Бөтен балаларга бүләкләр биреп, аларны сөендерделәр. Ханымларның китергән затлы ризыклары белән җәмгыять әгъзаларын хөрмәтләделәр, эчемлекләр эчтеләр һәм көн шатлык белән тәмам булды.

## ИСТАНБУЛ ХӘБӘРЛӘРЕ

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай исеменә 10 майда Тукай кичәсе үткәрергә карар бирелде. Кичәдә сәхнәгә кечкенә бер пьеса куелуы һәм милли биюләребезне ясар өчен эш бүлеше ясалды. Пьесаның режиссерлыгы доктор М.Алукайга бирелде. Кичәдә чәй мәҗлесен оештыруны исә хатын-кызлар үз өсләренә алдылар.

## ИСТАНБУЛ ХӘБӘРЛӘРЕ

Бөек вә милли шагыйребез Габдулла Тукайның үлүенә 62 ел уңае белән җәмгыятебез клубында 10 май көнне матур бер кичә үткәрелде. Кичәдә якташларыбыз күпчелеге катнашу белән янәшәдә Алманиядән ялга килгән Тукай клубын төзүчеләрдән Фәрит Аги һәм хатыны Гайшә ханым, Ерак Шәрыкъ мөһаҗәрәт хәятыбызның Харбин шәһәрендә яшьләр төзелешләрендә эшләп, яшьләрне оештыруда күп көч куйган Маһинур Латыйф ханым һәм Әнкарадан килгән мосафирлардан башка Истанбулдагы «Хөррият» гәзитеннән дә журналистлар килделәр.

Кичәнең программы алдан тәкъдим ителгәнгә күрә, мохтәсиб ачу чыгышыннан соң җәмгыять рәисе Фәрит Бичури көннең әһәмиятен һәм җәмгыять эшчәнлеген ачыклаган кыска бер доклад ясады. Аеруча бу кичәне оештыруда ярдәмнәре булган доктор М.Алукайга, хатын-кызлар рәисе Равилә Мусабайга, билетларны таратуда күп көч куйган Бибинур Дәвешигә, милли уеннарыбызны әзерләүдә һәм идарәсендә зур тырышлык куйган Әнкарадан Рәсим Бәгъдәшига, чәй мәҗлесен әзерләгән һәм ярдәм иткән ханымнарыбызга һәм лотерея өчен кулдан бәйләнгән шәл бүләк иткән Фатыйма Җәнгизбайга рәхмәтләрен белдерделәр.

Һәр ике пианистыбызга уңышлар теләп тәбрик итәбез. Аннан соң балаларыбыз чыгышын оештыруга зур көч куйган Гөлсәрән Садыйк ханымга да рәхмәтләребезне җиткерәбез.

**Җәүһәр Туганай**

## ФИНЛЯНДИЯ ХӘБӘРЛӘРЕ

— Садрый Хәмит тарафыннан чыгарылган «Ак юл» мәҗмугасының 59 нчы саны Габдулла Тукайның тууына 90 яшь тулуга багышлап нәшер ителде.

— Хельсинки шәһәрендә Тукай кичәсе уздырылды.

## ӘНКАРА ХӘБӘРЛӘРЕ

Ататөрек һәм Тукайның бөек портретлары чәчәкләргә күмелгән. Программадан соң балаларга бүләкләр тапшырылды. Гаиләләренә дә чәй белән хөрмәт күрсәтелде, шатлык белән истәлекле көн эшләнде. Аеруча Габдулла Тукайның 90 еллыгы уңае белән уздырылган тантана балалар күңеленә матур хатирә булarak кереп калды. Җыелыш сәгать 6га кадәр дәвам итте. Аңа ике сәгать вакыт бирелгән иде. Кичә сәгать 8 дә кабат дәвам итеп, төн уртасында гына тәмам булды.

**Әмрулла Аги**

## ИСТАНБУЛ ХӘБӘРЛӘРЕ

— Җәмгыять рәисе Фәрит Бичури чәй мәҗлесендә хатын-кызлар һәм килгән мосафирларга мөнәсәбәтле рәхмәтләрен белдереп, бу төрле җыелышларның файдалы булганын сөйләгәннән соң, 19 мартта һәм апрельдә милли шагыйребез Габдулла Тукайның истәлек көннәре эшләнәчәген әйтеп узды. Ул шулай ук якташларыбыздан матди ярдәм итүләрен теләде.

— 4 апрельдә җәмгыять бинасында милли шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 92 ел мөнәсәбәте белән бер искә алу көне билгеләп үтелде. Искә алу көнендә Тукай хакында чыгышлар ясалды, шигырьләр укылды.

— Истанбулда җәмгыять бинасында эшләнгән Тукай истәлеге көнендә яшь бер шагыйребез үзе язган матур шигырь белән якташларыбызның дикъкатен җәлеп итте. Киләчәктә аның танылган бер шагыйрь булып үсеп алга баруын телибез. Бу яшь шагыйребез Әдип вә Исламия Таһирларның кызы Шәһназ булып, ул язган шигырь «Миллият баласы» журналының 1978 елның 14 нче санында, 65 нче битендә басылды.

**Башкарма**

## ТУКАЙ

1914 елның апрелендә Тукайга багышлап чыгарылган «Ил» гәзитенең махсус санына ия булган кардәшләребездән аны башкармабызга җибәрүләрен үтенәбез. Бу гәзит, файдаланылганнан соң, ияләренә кайтарылып биреләчәк.

## ИЛ ХӘБӘРЛӘРЕ

«Тукай» исемле әсәр: «Кызыл Татарстан»ның 29 сентябрь санында язылуына күрә, Әхмәт Фәйзи тарафыннан «Тукай» исемле бер театр әсәре язылып, бу елгы театр репертуарына кертелгән.

## ТЫҢЛАГЫЗ!

15 апрельдә көндез сәгать 5тә Тукай туган көне уңае белән Харбин төрк-татарлары тарафыннан Харбин радиосында концерт булачак.

## ТУКАЙГА БАГЫШЛАП

Кызыл Мәскәүнең халкыбызны руслаштыру юлында туктаусыз эшләп ятуының нәтиҗәсе бик шәптән түгел булырга кирәк. Халкыбыз элекке төсле милли үзлегенә тартылуында дәвам итә. Милли барлыкларының кыйммәтләре кызыл тәзйикъ аркасында яңара гына бара.

«Милли юл»ның соңгы 136 нчы санында хәбәр басылды. Драматург Әхмәт Фәйзи тарафыннан шагыйребез Тукайга багышланган «Тукай Җаекта» исемле икенче пьеса басылып чыкты. Бу пьеса «Совет әдәбияты» мәҗмугасының бу елгы 3–4 нче саннарында 9 бит күләмендә басылган.

**ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР**

*12 бит.* **М.Х.Ф. Тормыш сагышы** *(Габдулла Тукайның үлүенә егерме ел тулды)*. «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 5 нче санында «М.Х.Ф.» имзасы белән басылган. Әлеге тәхәллүсне Л.Гайнанова һәм яшь галим И.Мансуров Рәшит Рәхмәти Аратныкы булуын ассызыклый. Текст шуннан алынды.

*13 бит.* **Шаһвәли Келәүле Илдәр. Габдулла Тукайга.** «Яңа милли юл» журналының 1936 ел, 6 нчы (100) санында Шаһвәли Келәүле имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Шаһвәли Келәүле* – Шаһвәли Риян улы Келәүле (1900—1970), шагыйрь, драматург. 1949 елдан Төркиядә яши. «Милли байрак» гәзите һәм «Казан» журналының актив язышучысы.

*14 бит.* **Солтан (Әхмәт Виргаз). Тукай рәсеменә.** «Милли байрак» гәзитенең 1936 ел, 3 июль санында Солтан имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*15 бит.* **М.Ф. Тукай өчен.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 1 май 8 нче (345) санында «М.Ф.» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды. Галим И.Мансуров бу тәхәллүсне Рәшит Рәхмәти Аратныкы булуын яза.

*16 бит.* **Солтан (Әхмәт Виргаз). Шагыйрьгә.** «Казан» журналының 1971 ел, март санында Солтан (Әхмәт Виргаз) имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*16 бит.* **Шаһвәли Келәүле Илдәр. Тукай эзеннән.** «Казан» журналының 1971 ел, март санында Шаһвәли Келәүле Илдәр имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*17 бит.* **Ил йолдызы.** «Казан» журналының 1971 ел, март санында Шаһвәли Келәүле Илдәр имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*18 бит.* **Сания Ишыкай. Габдулла Тукайга 90 яшь тулу уңае белән.** «Казан» журналының 1976 ел, 17 нче санында Сания Ишыкай имзасы белән басылган. Шигырьне төрекчәдән сүзгә-сүз төзүче-автор тәрҗемә итте. Текст шуннан алынды.

*19 бит.* **Минһаҗ. Даһи Тукайны искә алу.** «Казан» журналының 1978 ел, 22 нче санында Минһаҗ имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*21 бит.* **Гаяз Исхакый. Тукай истәлеге** (Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә). «Яңа милли юл» журналының 1932 ел, 11 нче санында Гаяз Исхакый имзасы белән басылган. Бу мәкаләне әдәбият галиме Х.Миңнегулов «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» дигән китабында нәшер итте. Текст китаптан алынды.

*«Тәрҗеман»ның 50 еллыгын бәйрәм итү* — гәзит Бакчасарай шәһәрендә И.Гаспринский (1851–1914) мөхәррирлегендә 1883 елда басыла башлый. 1918 елда яшәүдән туктый.

*...күбесе милләтчелектә гаепләнеп, Соловкига җибәрелеп бетерелгәнгә* — XX гасырның 20 нче еллар ахырында башланган репрессиядә бик күп татар зыялылары, милләтчелектә гаепләнеп, башта Соловкига, аннан тоташ төрмәләргә төренгән СССРның башка төбәкләренә озатыла. Алар арасыннан азларына гына исән-имин кайту бәхете татый.

*Ерак Шәрыктән Хөсәен Габдүш әфәнде* — Хөсәен Рәхимҗан углы Габдүш (1901–1944), журналист, әдип, режиссер, актер. Октябрь инкыйлабыннан соң Кытайга китә. Харбин шәһәрендә яши. «Милли байрак» гәзитенең актив язышучысы.

*«Мәҗмугаи асаре»н бастырырга безнең мөһаҗәрәттә матди көч юк* — бу җыентык 1933 елда Ерак Шәрык төрк-татар мөһаҗәрәтенең матди ярдәме белән Токиода нәшер ителә.

*24 бит.* **Шакир Йосыф. Искә алганда** *(Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә).* «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 4 нче санында «Шакир Йосыф» имзасы белән басылган. Бу мәкаләне Л.Гайнанова Казан утлары журналының 2002 ел, 3 нче санында нәшер итә. «Шакир Йосыф» тәхәллүсен Л.Гайнанова һәм яшь галим И.Мансуров Р.Рәхмәти Арат имзасы булуын язалар. Текст «Казан утлары» журналыннан алынды.

*27 бит.* **Гали Биктимер. Эзләнгәндә**. «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 5 нче санында Гали Биктимер имзасы белән басылган. Бу текстны Л.Гайнанова «Казан утлары» (2002, 3 нче санында) журналында кириллицада нәшер итте. Текст «Яңа милли юл» журналыннан алынды.

*Гали Биктимер* — әлеге тәхәллүсне Л.Гайнанова һәм яшь галим И.Мансуров Рәшит Рәхмәти Аратныкы булуын язалар.

Рәшит Рәхмәти Арат — Габдрәшит Гыйсмәтулла улы Рәхмәтуллин (1900–1964), күренекле тюрколог, «Яңа милли юл» журналында актив язучылардан берсе, публицист.

*30 бит.* **Тукайны аңлар өчен.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 5 нче санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*33 бит.* **Солтан (Әхмәт Виргаз). Габдулла Тукайның үлүенә 22 ел тулу уңае берлә.** «Яңа милли юл» журналының 1935 ел, 7 нче санында «Солтан» имзасы белән басылган. Бу текстны күренекле галим Х.Миңнегулов «Казан утлары» журналының 2002 ел, 1 нче санында кириллицада нәшер итте. Текст «Яңа милли юл» журналыннан алынды.

*Күпме михнәт күргән безнең халык...* — шигырь юллары Тукайның «Милли моңнар»ыннан алынган.

*...инглизнең Байронын* — Байрон Джордж Ноэл Гордон (1788–1824), инглизләрнең атаклы романтик шагыйре. Тукай аның шигырьләрен яратып укыган һәм тәрҗемә иткән.

*...алманнарның Гётесын* — Гёте Иоганн Вольфганг (1749–1832), немец халкының күренекле шагыйре, фикер иясе.

*35 бит.* **Рокыя Мөхәммәдиш. Тукай көне.** «Милли байрак» гәзитенең 1936 ел, 22 нче санында (1 апрель) Рокыя Мөхәммәдиш имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Рокыя Мөхәммәдиш* — Мөхәммәдиш Рокыя (1908–1989), публицист һәм тәрҗемәче. Мукденда нәшер ителгән «Милли байрак» гәзитенең җаваплы хезмәткәре, төп авторларының берсе. Сталин төрмәләрен узган Р.Мөхәммәдиш Казанда вафат була.

*«Купме михнәт күргән безнең халык өч йөз елда»* — бу шигырь юллары «Милли моңнар»дан. Ләкин мәкаләдә ул азрак үзгәртелгән. Тукайда:

Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен, —

рәвешендә язылган. Автор әлеге шигырьнең фикерен генә җиткерергә теләгәндер, күрәсең.

*39 бит.* **Хөсәен Габдүш. Бөек Кушлавыч ятиме** *(шагыйрьгә 50 яшь тулу уңае берлә).* «Яңа милли юл» журналының 1936 ел, 5 нче санында Хөсәен Габдүш имзасы белән басылган. Текстның ахырында «Харбин, 12 апрель, 1936» дип куелган. Бу мәкаләне әдәбият галиме Х.Миңнегулов «Казан утлары» (2002 ел, 1 нче сан) журналында кириллицада нәшер итте. Текст «Яңа милли юл» журналыннан алынды.

*Чыгып барганда, дөп-дөп типкәлиләр...* — бу шигырь юллары «Осулы кадимче» исемле әсәреннән алынган.

*Габдулла бәк Батталның кыйммәтле әсәре «Казан төркләре»ндә...* — Батталов Абделбари Абдулла улы (1883—1969), тарихчы, публицист. 1921 елдан чит илдә яши. «Казан төркләре» хезмәтенең беренче басмасы 1925 елда Истанбулда һәм тулыландырылган икенче басмасы 1966 елда Әнкарада дөнья күрә.

*Хәмид Зөбәер* — Хәмит Зөбәер Кошай (1897—1978), профессор. 1924—1925 елларда Берлин университетында этнография һәм музей эше буенча белемен камилләштерә. Төркия, Германия, Венгрия, Финляндиянең күп кенә фәнни институтлары, җәмгыятьләренең әгъзасы, ЮНЕСКОның ачык һавадагы музейлар комитеты рәисе.

*«Мәҗмугаи асаре»ннән* — Тукайның үзе тарафыннан төзелеп һәм Җамал Вәлиди кереш мәкаләсе белән Казанда «Мәгариф» типографиясендә 1914 елда басылган җыентыгы турында бара. Бу тупланма шулай ук «Мәҗмугаи асарь» исеме белән 1933 елда Токиода да дөнья күрә.

*...шагыйрь Сәгыйть Рәмигә язган бер мәктүбендә...* — монда Тукайның 1911 ел, 4 март датасы белән Казаннан Әстерханга С.Рәмиевкә җибәргән хатындагы сүзләре истә тотыла.

*Чыңгыз «Яса»сыннан* — Чыңгызхан (Темучин, Темуҗин) (1155 еллар — 1227) — Монгол мәмләкәтенә нигез салучы олуг хан (1206), җиһангир. Ул монгол дәүләтенең бердәм ясасын (кодекс, законнар җыелмасы) төзи. Садри Максуди Арас хезмәтеннән күренгәнчә, яса төрки кануннарга нигезләнеп төзелгән.

*Карлейль* — Карлейль Томас (1795–1881), күренекле әдип, публицист, тарихчы, философ.

*Шекспир* — Шекспир Уильям (1564–1616), инглизләрнең күренекле драматургы һәм шагыйре.

*45 бит.* **Сәгадәт Чагатай. Габдулла Тукай.** «Яңа милли юл» журналының 1936 ел, 6 нчы (100) санында Сәгадәт Чагатай имзасы белән басылган. Бу мәкалә әдәбият галиме Х.Миңнегуловның «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» исемле китабына кертелгән. Әлеге китапта текст тулы түгел. Мәкалә текстының тулы варианты «Яңа милли юл» журналыннан алынды.

*Сәгадәт Чагатай* (1905—1989) — татар галимәсе, Гаяз Исхакыйның кызы. Гомеренең күп өлешен Төркиядә үткәрә.

*48 бит.* **Рокыя Мөхәммәдиш. Тукайны искә алганда.** «Милли байрак» гәзитенең 1937 ел, 16 апрель санында Рокыя Мөхәммәдиш имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*51 бит.* **Хөсәен Габдүш. Тукай — ил углы.** «Милли байрак» гәзитенең 1937 ел, 16 апрель санында Хөсәен Габдүш имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Габдрахман Сәгъди* — Сәгъдиев Габдрахман Гайнан улы (1889—1956), тел, әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1949), профессор (1929).

*«Кавагыйде әдәбия»сеннән күчерелгән...* — «Мөхтәсар кавагыйде әдәбия» китабы — урта һәм югары сыйныфта укучы татар шәкертләре өчен төзелгән дәреслек. 1911 елда Уфада басылып чыга.

*Тарас Шевченкога* — Шевченко Тарас Григорьевич (1814—1861), күренекле украин шагыйре, рәссам, фикер иясе.

*Җәгъфәр Сәед Әхмәднең* — Җәгъфәр Сәед Әхмәд (1889—?), мөһаҗирлектәге кырым татарлары милли хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе. Журналист һәм язучы. Аның «Кырым» (французча 1920, поляк телендә 1930) һәм 1934 елда чыккан «Гаспралы Исмәгыйль бәк» исемле китаплары бар.

*К.Әмири* — Әмири Кәрим Хөсәен улы (1893—1962), шагыйрь һәм драматург.

*Ф.Бурнаш* — Бурнаш Фәтхи (Бурнашев Фәтхелислам Захир улы) (1898–1942), язучы, Октябрь инкыйлабыннан соң Тукайны татар укучысына танытучыларның берсе.

*55 бит.* **Гаяз Исхакый. Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә.** «Яңа милли юл» 1938 ел, 4 нче (121) санында Гаяз Исхакый имзасы белән басылган. Соңрак бу мәкаләне А.Кәримова «Казан утлары» журналының 1999 ел, 4 нче санында һәм күренекле галим Х.Миңнегулов «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» (Казан, 2004) хезмәтендә нәшер итәләр. Текст «Яңа милли юл» журналыннан алынды.

*Сәгыйть Рәми* — Рәмиев Сәгыйть Лотфулла улы (1880—1926), шагыйрь, драматург, публицист. Г.Ибраһимов С.Рәмиевне Тукай иҗатына каршы куя.

*Тик милләткә хезмәткә мәхәббәт миндә бар!..* — Бу юллар «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» шигыреннән алынган. Г.Исхакый мәкаләсендә шигырь шактый үзгәртелгән. Тукай шигыре болай яңгырый:

Тик фәкать милләткә хезмәткә мәхәббәт бәндә бар;
Бәнчә, бунда ямь дә бар, ләззәт тә бардыр, тәм дә бар!

*...Пушкиннан, Лермонтовтан, фәләннән кеби* — Г.Тукай рус әдәбияты күренекле шагыйрьләренең әсәрләрен теләп тәрҗемә итә. Алар иҗади тәрҗемә ителгәнлектән чын Тукайча, милли шигырь буларак яңгыраш ала.

*Фатих Әмирхан* — Әмирхан Фатих Зариф улы (1886—1926) — күренекле татар язучысы, Тукайның якын дусты.

*Галимҗан Ибраһимов* (1887—1938) — күренекле татар язучысы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе. «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә Тукай иҗатына кимсетеп карау сизелә. Ул татар шигъриятенең таҗы итеп С.Рәмиев һәм Дәрдемәндне таный.

*Дәрдемәнд* — Рәмиев Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы (1859—1921), шагыйрь, меценат, алтын приискасы хуҗасы.

*Хөсәен Ямаш* — Ямашев Хөсәен Минһаҗетдин улы (1882—1912), XX йөз башы революцион хәрәкәтендә актив катнаша, публицист.

*«Мөхәммәдия», «Бакырган»нардан өлге алып* — татар мәдрәсәләрендә яратып укылган дини әсәрләр. «Мөхәммәдия» — төрек дини шигърияте ядкәре. Мөхәммәд Чәләби (?—1451) әсәре. 1845 елдан башлап Казанда күп тапкыр басылган. «Бакырган» шигъри әсәре дә болгар-татар халкы арасында популяр булган.

*«Сөбател-гаҗизин», «Бәдәвам»* — татар мәдрәсәләрендә яратып укылган дини эчтәлектәге әсәрләр. «Сөбател-гаҗизин» Әстерхан ягыннан Урта Азиягә киткән төрки телле суфи шагыйрь һәм дин эшлеклесе Суфи Аллаһияр (1616–1713) әсәре. «Бәдәвам» исә — дини эчтәлектәге әсәр. Бу да татар шәкертләре арасында яратып укылган.

*о Тукайны кымызга җибәрү, Кырымга озату* — Г.Тукайның 1910–1912 елларда авыруы көчәя. Якын дуслары аңа дәваланырга кирәклеген искәртеп торсалар да, ул бу тәкъдимнәрне кабул итәргә ашкынып тормый. Бары 1912 елның яз һәм җәй айларында гына Троицкига барып кымыз эчеп кайта. Күпмедер вакытка хәле яхшыра.

*Казанның бер хастаханәсендә вафат итә* — Г.Тукай 1913 елның 2 апрелендә (яңа стиль белән 15.04.) Клячкин хастаханәсендә үлә. Г.Исхакый хастаханәнең исемен ни өчендер төгәл атый алмаган.

*63 бит.* **Сәгадәт Чагатай. Габдулла Тукай** *(үлүенә 25 ел тулу уңае берлә).* «Яңа милли юл» журналының 1938 ел, 4 нче санында Сәгадәт Чагатай имзасы белән басылган. Бу мәкаләне әдәбият галиме Х.Миңнегулов «Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты» исемле китабында бастырды. Текст «Яңа милли юл» журналыннан алынды.

*«Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә»* — Тукай томнарында бу исем «Таян Аллага» рәвешендә тәкъдим ителә.

*Әйдә халыкка хезмәткә, хезмәт эчендә йөзмәккә...* — бу шигырь юлларын С.Чагатай ни өчендер «Мужик йокысы»ннан булуына ишарәли. Әмма шигырь юллары «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?»дән алынган.

*Горький* — Пешков Алексей Максимович (1868–1936), күренекле рус язучысы.

*Минем гомерем караңгы төн.*

*Кояшлы һәм аем тугмас...* — «Күңел йолдызы» шигыреннән алынган әлеге юлларны мәкалә авторы азрак үзгәрешләр белән тәкъдим итә. Без һәркемгә аңлаешлы булсын өчен Тукайның соңгы биштомлыгындагыча урнаштырабыз.

69 *бит.* **Хөсәен Габдүш. Тукайсыз, Тукай берлә.** «Яңа милли юл» журналының 1938 ел, 5 нче санында Хөсәен Габдүш имзасы белән басылган. Мәкаләнең ахырында «Харбин, 14. III. 1938» дип куелган. Текст шуннан алынды.

*«Казан төркләре» китабының кереш сүзләре...* — сүз Габделбари Батталның «Казан төркләре» исемле китабына язган кереш сүзе турында бара. Хезмәт беренче тапкыр 1925 елда Истанбулда дөнья күрә.

*Гомер* — Борынгы Грециянең легендар эпик шагыйре. Атаклы «Илиада» һәм «Одиссея» поэмалары авторы.

*Вергилий* — Вергилий Марон Публий (б.э.к. 70–19), борынгы рим шагыйре. Рим республикасы җимерелүенең шаһиты.

*Сервантес* (1547–1616) — испан шагыйре.

*«Кораблы» Дәрдемәнд* — «Кораб» шигыре беренче тапкыр «Шура» журналының 1908 ел гыйнварында чыккан 1 нче санында басылган. Шигырьнең фикри тирәнлеге тәнкыйтьтә һәм әдәбият фәнендә төрле аңлатмаларга этәргеч бирде. Х.Габдүш шуңа ишарә бирә.

*«Таң вакыты» һәм «Перчатка»лы Сәгыйть Рәми кеби ...* — С.Рәмиев «Таң вакыты» шигырен беренче тапкыр 1908 елның 2 гыйнварында ислахчылар оештырган әдәбият кичәсендә сөйли. Бу шигырь шул заман гәзитендә бәхәс тә уята. Хәтта Ф.Әмирхан да шигырьнең эчтәлегенә ризасызлыгын белдерә. «Перчатка» шигыре исә беренче мәртәбә «Казан мөхбире»нең 1910 ел, 23 июнь (382) санында басыла.

*Тукайның мәхәлли шивә берлә язуын яратмыйча язды...* —Тукайның башлангыч чор иҗатында төрек теле тәэсире шактый зур. Соңга таба ул төрекчелектән акрын гына китә һәм чын татар телендә яза башлый. Гомумән, бу мәсьәләдә Тукай белән «Тәрҗеман» гәзите арасында бәхәсләр дә булгалый.

*75 бит.* **Рокыя Мөхәммәдиш. Илсезлектә Тукай белән.** «Милли байрак» гәзитенең 1938 ел, 19 нчы (118) (22 апрель) санында Рокыя Мөхәммәдиш имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*...тәнкыйтьчебез Җамал Вәлиди* — Вәлидов Җамалетдин Җәләлетдин улы (1887—1932), тел, әдәбият галиме, тәнкыйтьче.

*Япон-рус сугышында...* — патша Россиясе 1904—1905 елгы Рус-япон сугышында җиңелүгә дучар ителә.

*Эшкә дәгъвәт итте кемдер...* — мәкаләдә бу шигырь юлының да «безне» сүзе төшеп калган.

*...өлкәнең мәркәзе Казанга омтыла* — Г.Тукай 1895 елдан алып 1907 елга кадәр Җаек (Уральск) шәһәрендә яши. 1907 елда исә солдатка каралыр өчен Казанга килә. Шагыйрьнең хатларыннан, бу елларда язылган шигырь һәм публицистик язмаларыннан күренгәнчә, Казан аның өчен илаһи шәһәр буларак кабул ителә. Әмма озакка түгел. Илдә башланган реакция һәм шәхси тормышындагы бәхетсезлек нәтиҗәсендә җәмгыятькә, кешеләргә ышанычсызлык, яшәвендә өметсезлек чоры башлана.

*Күк булып күкрәр...* — мәкаләдә бу шигырь юлының «һавада» сүзе төшеп калган.

*78 бит.* **Хөсәен Габдүш. Тукай һәм яшьләр** *(үзек фикерләр).* «Милли байрак» гәзитенең 1938 ел, 19 нчы (118) (22 апрель) санында Х.Габдүш имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*...шагыйрьнең «Мәҗмугаи асаре» белән* — шагыйрьнең үзе тарафыннан төзеп калдырган җыентыгын 1914 елда Җ.Вәлиди Г.Тукай иҗатын анализлап язган мәкаләсе белән Казанда «Мәгариф» типографиясендә бастыра.

*81 бит.* **Габдулла Тукайның егерме биш еллыгы.** «Милли байрак» гәзитенең 1938 ел, 19 нчы (118) (22 апрель) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*...нәшер ителәчәк «Тукай рисаләсе»* — Мукден шәһәрендә Ерак Шәрык Идел-Урал төрк-татар мөселманнарының дини, милли мәркәзенең мәгариф бүлеге 1938 елда, Г.Тукайның үлүенә 25 ел тулу уңае белән 20 мәкалә һәм күп кенә шигырьләрен кертеп, 98 бит күләмендә «Габдулла Тукай» исемле җыентык төзеп бастыра.

*84 бит.* **Рокыя Мөхәммәдиш. Габдулла Тукай** *(вафатына 26 ел тулу уңае белән)*. «Милли байрак» гәзитенең 1939 елгы (163) (14 апрель) санында Рокыя Мөхәммәдиш имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Габделкаюм Насыйри* (1825—1902) — күренекле татар мәгърифәтчесе, календарьлар төзүче, язучы һәм педагог.

*...20 елдан бирле күкрәгендә ил кайгысын ташучы...* — 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң татар халкының күп кенә зыялылары, сәүдәгәрләре, большевик басымыннан качып, чит илләргә агыла. Г.Исхакый мәкаләләреннән күренгәнчә, 100 мең чамасы төрки кавем, алар арасында 10 меңнән артыграк татар-башкортлар Ерак Шәрыкка барып урнаша. О.Лебедев «Генофонд и прогресс» мәкаләсендә исә 1917 елдан 1924 елга кадәр 2 млн. чамасы Россия гражданнары чит илләрдә үзләренә сыену урыны табуын күрсәтеп уза.

*«Шагыйрь» Солтан* — Әхмәт Виргазның Г.Тукайга багышлап язган шул исемдәге шигыре.

*... бит.* **Мәдинә Салиәхмәт. Тукайның мәгънәвияте әтрафына.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 18 нче (345), 19 нчы (346) (1 май һәм 10 май) саннарында Мәдинә Салиәхмәт имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Мәдинә Салиәхмәт* (1897—1964), укытучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Ерак Шәрык милли хәрәкәтендә актив катнаша. 1932 елда Шанхайга күчә. Гомеренең соңгы көннәрен Төркиядә уздыра.

*Зыя Күк Алып* — Зыя Гүкалып (1876—1924), төрек халкының күренекле шагыйре һәм фикер иясе, публицист, төрекчелек идеясен алга сөргән.

*Ага оглы Әхмәт* — Әхмәт Агаоглы (1869—1939), төрек халкының күренекле фикер иясе, публицист, чыгышы белән Азәрбайҗаннан. Аның «Төрек йурду» журналында 1924—1926 елларда «Өч мәдәният» исемле хезмәте дөнья күрә.

*Галимҗан Ибраһимов* (1887—1938) — күренекле татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе һәм галим.

*Фатыйх Сәйфи* — Сәйфи-Казанлы Фатыйх (Сәйфуллин Мөхәммәтфатыйх Камалетдин улы) (1888—1937), язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Ф.Сәйфи исән вакытта Тукай иҗатына уңай мөнәсәбәттә була. Инкыйлабтан соң аның әсәрләр җыентыгын төзеп бастыруга да зур өлеш кертә. Бу очракта Тукай иҗатына карата кинәт үзгәрүе аңлашылмый.

*Язучы Куприн* — Куприн Александр Иванович (1870—1938), рус язучысы. Инкыйлабтан соң 17 ел чит илдә яши. 1937 елда авыру хәлендә Россиягә кайта.

*Ацыбашевларның* — Ацыбашев Михаил Петрович (1878—1927), рус язучысы. Октябрь инкыйлабыннан соң чит илгә китә. 1908—1912 елларда күп кенә әсәрләре эротик планда язылуына ишарә.

*Сәгыйть Сүнчәләй* (1888—1937), шагыйрь, тәрҗемәче, педагог, җәмәгать эшлеклесе.

*93 бит.* **Габдулла Тукайның мәгънәвияте әтрафыннан.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 19 нчы (346) (10 май) санында Мәдинә Салиәхмәт имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*«Шура»да язылган...* — «Шура» журналы 1908—1917 елларда Ризаэтдин Фәхретдин мөхәррирлегендә Оренбург шәһәрендә басыла. Барлыгы 240 саны дөнья күрә.

*Толстой белән чагыштыра* — Толстой Лев Николаевич (1828—1910), күренекле рус язучысы һәм фикер иясе. Тукай аның иҗатына уңай мөнәсәбәттә була.

*...мәрхүм Шәмгуни хәзрәт* — Шәмгуни Мәдъяр (1874—1938), Кобе шәһәре мәчетенең имам-хатибы. Ерак Шәрыктә төрк-татар милли хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе.

*Шиһаб хәзрәткә каратып* — Тукайның «Шиһаб хәзрәт» исемле шигыре «Аң» журналының 1913 ел, 2нче (1 гыйнвар) санында басылгаан. Мәкалә авторы шул шигырьне истә тота.

*Ататөрекнең тел-хәреф инкыйлабларын...* — Ататөрек — Мостафа Кәмаль патша (1881—1938), Төркия Җөмһүриятенең беренче президенты. 20 нче елларда төркләр Ататөрек фәрманы нигезендә гарәп алфавитыннан латинга күчәләр.

*99 бит.* **Надир Дәүләт. Казан төркләре һәм Габдулла Тукай (26.IV.1886—15.IV.1913).** — «Казан» журналының 1971 ел март санында Надир Дәүләт имзасы белән басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче-автор эшләде. Текст күрсәтелгән чыганактан.

*Надир Дәүләт* (1944) — тарихчы, тарих фәннәре докторы (1985), 1972–1984 елларда Мюнхенда «Азатлык» радиосында эшли. Бер үк вакытта Төркиядә 1970—1980 елларда «Казан» журналы мөхәррире.

*28.IV.1886.* — Мәкалә авторы Тукайның туган көнен 28 апрель белән тәкъдим итә. Бу редакция хатасы булуы да ихтимал.

*«Нур»* — беренче татар гәзите «Нур» 1905—1914 елларда С.Петербург шәһәрендә Гатаулла һәм Сафа Баязитовлар мөхәррирлеге һәм наширлегендә басыла. Тукай «Нур»ның нәшер ителүен хуплап каршы ала.

*...үлгән вакытта 28 яшендә...* — мәкалә авторы азрак төгәлсезлек җибәрә. Г.Тукай үлгәндә аның әле 27 яше дә тулып җитмәгән була. Туган көне яңа стиль белән 26 апрельгә туры килә.

*Н.Ашмарин* — Ашмарин Николай Иванович (1870—1933), тел галиме, тюрколог, СССР Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы (1929).

*Акчурин* — Йосыф Акчурин (1875—1935), тарихчы, Төркиядә яши.

*Вильямсның мәкаләсе...* — Вильямс Горальд(?), тәрҗемәче. Тукай шигырьләрен инглиз теленә беренчеләрдән булып тәрҗемә итүче.

*Казанда Р.Радимов тәрҗемәләре...* — Радимов Павел Александрович (1887—1967), рәссам, шагыйрь, педагог. Тукайның «Шүрәле» поэмасын һәм аерым шигырьләрен рус теленә беренче тәрҗемә итүче.

*C.Cermanetto* — Джерманетто Джованни (1885—1959), итальян язучысы.

*о Луи Арагон* (1897—1982) — француз язучысы һәм сәясәт эшлеклесе. Тукай шигырьләрен француз теленә тәрҗемә итүче.

*Фуад Көпрүлү* — Көпрүлүзадә Фуад (1890—?), төрек галиме, Төркиядә беренчеләрдән булып Тукай үлеме хакында «Төрек йурду» журналында зур мәкалә бастыра. Шагыйрьне бөтен төрк дөньясына таныта.

*И.Нуруллин* — Нуруллин Ибраһим (1923—1995), әдәбият галиме, филология фәннәре докторы (1968). Тукай шәхесен һәм иҗатын өйрәнүгә зур өлеш керткән шәхес.

*Г.Акыш* — Акыш Гали (Али) Хисаметдин улы (1918), җәмәгать-сәясәт эшлеклесе, публицист.

*Н.Бинарк* — Бинарк Наилә (1940), укытучы, шагыйрь. Берничә китап авторы.

*103 бит.* **Әхмәт Тимер. Габдулла Тукай** *(үлеменә 60 ел тулу уңае белән).* «Казан» журналының 1973 ел, 10 нчы санында профессор Әхмәт Тимер имзасы белән басылган. Текст төзүче тарафыннан иҗади тәрҗемә ителде. Мәкалә журналдан алынды.

*Әхмәт Тимер* — Яруллин Әхмәт Рәшит улы (1912—2003), төрки һәм монгол телләре галиме. Әнкара университеты профессоры (1962). Татар мәдәнияте һәм тарихы (шул исәптән Г.Тукай) турында мәкаләләр циклы авторы.

*Мотыйгулла хәзрәткә* — Төхфәтуллин Мотыйгулла (1846–1920), дин эшлеклесе, мөдәррис. Тукайда шигърияткә мәхәббәт уятучыларның берсе.

*Камил Мотыйгый* — Төхфәтуллин Камил Мотыйгулла улы (1883–1941), җырчы, нашир һәм журналист.

*1905 елда «Фикер» гәзите чыгара...* — «Фикер» гәзите 1905—1907 елларда Камил Мотыйгый, В.Хәмидуллин мөхәррирлегендә Уральск шәһәрендә басыла. Демократик рухтагы гәзит Столыпин реформасы башлану белән ябыла. Тукай беренче шигъри әсәрләрен шунда бастыра.

*«Әлгасрелҗәдид» мәҗмугасы басыла башлый* — бу журнал 1906–1907 елларда Камил Мотыйгый мөхәррирлегендә Уральскида басыла. Әлеге мәҗмуганы да «Фикер» язмышы көтә, озак тормый ябыла. Бу журналда да төп вазифаны Тукай алып бара.

*«Уклар» исемендә бер юмористик мәҗмуга...* — журналның барлыгы 6 саны 1906 елда Камил Мотыйгый мөхәррирлегендә дөнья күрә. Тукайның үткен телле юмор-сатира әсәрләре шунда басыла.

*«Вакыт» гәзите* — «Вакыт» гәзите 1906—1918 елларда Оренбург шәһәрендә Фатыйх Кәрими мөхәррирлегендә һәм Мөхәммәдзакир (Дәрдемәнд) Рәмиев наширлегендә басыла.

*«Әл-ислах»та эшләр* — гәзит 1907—1909 елларда Вафа Бәхтияров (төп мөхәррире Ф.Әмирхан) мөхәррирлеге һәм наширлегендә басыла. Тукай бу гәзиттә актив язышa.

*«Яшен» исемле юмористик мәҗмугасы...* — журнал 1908—1909 елларда Казанда нәшер ителә.

*о «Ялт-Йолт» журналы чыга башлый* — 1910—1918 елларда чыккан әдәби, фәнни вә сәяси журнал. Мөхәррире һәм нашире Әхмәт Урманчиев була.

*«Кояш» гәзитендә* — «Кояш» гәзите 1912—1918 елларда Казан шәһәрендә Зәкәрия Садретдинов мөхәррирлеге һәм наширлегендә басыла.

*«Аң» мәҗмугаларында* — «Аң» журналы 1912—1918 елларда Казан шәһәрендә Әхмәтгәрәй Хәсәни мөхәррирлеге һәм наширлегендә басыла.

*107 бит.* **Хөсәен Габдүш. Нидән мин кечкенә «Апуш»тан бөек «Тукай» булдым?** «Казан» журналының 1973 ел, 10 нчы санында Хөсәен Габдүш имзасы белән басылган. Текст төзүче тарафыннан төрекчәдән иҗади тәрҗемә ителде. Мәкалә журналдан алынды.

*Хәтерегезгә китерегез! Яшьтән дөнья куйган Габдулла Тукай...* — Г.Исхакыйның «Мөгаллимә» әсәрендә җөмлә түбәндәгечә бирелә: «Кичә генә үлгән Габдулла Тукаевны, гомерендә бер мәртәбә татар кызыннан сөйкемле сүз, сөйкемле бер хәрәкәт күрмәгән шул татар шагыйренең хәлен, трагедиясен уйнагыз!»

*...үз каләменнән калдырган «Хәтеремдә калганнар»ында...* — бу китап татар укучысына «Исемдә калганнар» исеме белән билгеле.

*...лирик шигырьләрнең таҗы булган «Җимерелгән өмет»ендәге...* — Тукайның бу исемдәге шигыре билгеле түгел. Шигырьдән китерелгән өзектән күренгәнчә, сүз шагыйрьнең «Өзелгән өмид»е турында бара.

*109 бит.* **Надир Дәүләт. Габдулла Тукай шигырьләреннән үрнәкләр.** «Казан» журналының 1973 ел, 10 нчы санында Надир Дәүләт имзасы белән басылган. Мәкалә төзүче тарафыннан төрекчәдән иҗади тәрҗемә ителде. Текст шуннан алынды.

*115 бит.* **Шәмсия Апакай. Мин Казанда.** «Казан» журналының 1976 ел, 17 нче санында Шәмсия Апакай имзасы белән басылган. Төрекчәдән иҗади тәрҗемәне төзүче-автор эшләде. Текст күрсәтелгән басмадан алынды.

*«Болгар» һәм «Сарай» кунакханәләре бар* — Г.Тукай Казанга кайтуы белән «Болгар» номерларына урнаша. Ул анда, кыска-кыска күченүләрне исәпләмәгәндә, 1912 елның декабренә кадәр яши. 1908 елның гыйнвар аенда В.Бәхтияров белән «Сарай» номерларында (Париж Коммунасы урамы, 9 нчы йорт), 9 нчы бүлмәдә яшәп ала.

*... яшь имам белән көрештек* — бу урында Тәлгать Таҗетдин турында әйтелә булса кирәк. Ул башта Бохара мәдрәсәсендә укый һәм соңыннан Каһирәнең Әл-Әзһәр мәдрәсәсендә белем ала.

*Тукай абзасының кызы Газизәнең...* — Зәбирова Газизә (1877—1963), Тукайның апасы, аталары бер, аналары башка.

*118 бит.* **Надир Дәүләт. Татар диаспорасы һәм Тукай.** «Казан утлары» журналының 1997 ел, 5 нче санында Надир Дәүләт имзасы белән басылган. Язманы матбугатка Ә.Сибгатуллина хәзерләгән. Язылу вакыты итеп Истанбул, 1995 елның июне күрсәтелгән. Текст журналдан алынды.

*...кыргызларның «Манас» дастанына* — кыргыз халкының атаклы дастаны. Ярты миллион чамасы шигъри юлдан торган әсәрдә кыргыз милләтенең чит ил басып алучыларына каршы көрәше гәүдәләнә. «Манас»ның тулы басмасы 1917 елдан соң гына дөнья күрә.

*...үзбәкләрнең (әмир) Тимергә* — Аксак Тимер (1336—1405), атаклы яубашы, дәүләт эшлеклесе.

*...казакъларның Абай Кунанбаевка* — Кунанбаев Абай (1845—1904), казакъ милләтенең күренекле мәгърифәтчесе, шагыйрь, яңа язма әдәбиятын тудыручыларның берсе.

*...башкортларның профессор Зәки Вәлиди-Туганга* — Вәлиди-Туган Әхмәтзәки Әхмәтшаһ улы (1890—1970), революция һәм милли азатлык хәрәкәтләре эшлеклесе, шәркыятьче галим, тюрколог, профессор (1925).

*...төрекмәннәрнең Мәхтүм Колыйга* — Мәхтүмколый (туган һәм үлгән еллары билгесез), XVII гасыр төрекмән шагыйре.

*Мәҗит Гафури* — Гафури Габделмәҗит Нургани улы (1880—1934), татар-башкорт язучысы, публицист. Башкортстанның халык шагыйре (1923).

*Зариф Бәшири* — Бәшири Зариф Шәрәфетдин улы (1888—1962), язучы һәм шагыйрь.

*Нәҗип Думави* — Туктамышев Нәҗип Сибгатулла улы (1883—1933), шагыйрь һәм язучы.

*Укмасый* — Зәбиров Миргазиз Габделкаюм улы (1884—1946), шагыйрь.

*о Зыя Ярмәки* — Насыйров Зыя Шәйхи улы (1887—1965), шагыйрь.

*Хөсәен Садыйк* (1906—1973) — Финляндиядә яшәп иҗат иткән шагыйрь.

*Әмди Гәрәйбәйнең «Тукайга»* — Һәмди Гирәйбай (1901—1930), Кырым татар шагыйре. Бу авторның Бухарестта 1994 елда 85 шигырен эченә алган «Яшь татарларга» исемле китабы басыла. «Тукайга» шигыре шунда урнаштырылган.

*128 бит.* **Тукай кичәсе.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 5 нче санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

**Варшауда.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 5 нче санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

**Хельсинкифорс.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 6 нчы санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*Хельсинкифорс* — Хельсинки шәһәренең швед телендәге атамасы.

**Таммерфорста.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 6 нчы санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*Таммерфорс* —Тампере шәһәренең швед телендәге атамасы.

**Або.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 6 нчы санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*Або* — Финляндиядәге Турку шәһәренең швед телендәге атамасы.

*Исмәгыйль Гаспринскийга багышлап...* — Гаспринский (Гаспралы) Исмәгыйль Мостафа улы (1851—1914), җәмәгать эшлеклесе, педагог, нашир.

*130 бит.* **Углан. Матбугат дөньясында. Шагыйрь.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 6 нчы санында Углан имзасы белән басылган.

*Шиһаб хәзрәт* — Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889), күренекле татар мәгърифәтчесе, тарихчы һәм дин галиме, педагог.

*131 бит.* **Халык җырлары һәм аның укымышлыларының идеалы.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 6 нчы санында «Углан» имзасы белән басылган. «Харбинское время», 27 март гәзитеннән алынган. Текст журналдан алынды.

*Фатих Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә»* — бу әсәр 1907 елның 18–21 октябрендә язылып, шул ук елда «Әл--ислах» гәзитенең 4 нче санында «Дамелла» имзасы белән басылган.

*Кәбир Бәкернең* — Бәкеров Кәбир Кәрим улы (1885—1944), драматург, театр тәнкыйтьчесе.

*132 бит.* **Харбин мөхбире. Тукайның 50 яше.** «Милли байрак» гәзитенең 1936 ел, 3 июль санында «Харбин мөхбире» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*«Хисаметдин менла»ның дөньяга килүенә* — Муса Акъегетзадәнең бу әсәре беренче тапкыр 1886 елда басыла.

*Әхмәт Виргаз* — шагыйрь, журналист, һәвәскәр артист. Чыгышы белән Мордовия төбәгеннән.

*...аның мөхәррире Муса Акъегетзадә* — Акъегетзадә Муса (1864–1923), күренекле мәгърифәтче язучы. Татар реалистик әдәбиятына нигез салучыларның берсе. Гомеренең күп өлеше Төркиядә уза, кабере дә шунда.

*133 бит.* **Мөхбир. Шанхайда истәлек көннәре.** «Милли байрак» гәзитенең 1937 ел, 23 нче (73) (30 апрель) санында «Мөхбир» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Ризаэтдин бине Фәхретдин* (1859—1936) — күренекле галим, язучы, 1922—1936 елларда Идел-Урал һәм Себер мөселманнары мөфтие. 1936 елның 14 апрелендә вафат булган. Р.Фәхретдингә багышлап «Яңа милли юл» журналы һәм «Милли байрак» гәзите тулы саннар нәшер итә. Тукай кичәләрен уздырганда, һәр ел саен Р.Фәхретдинне да искә алалар, аның рухына дога кылалар.

*134 бит.* **Якташ. Өч сәгать Тукай моңында.** «Милли байрак» гәзитенең 1937 ел, 23 нче (73) (30 апрель) санында «Якташ» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*136 бит.* **Мөхбир. Тукай кичәсе.** «Милли байрак» гәзитенең 1937 ел, 23 нче (73) (30 апрель) санында «Мөхбир» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Мансур Арысланбәк* — бу шәхес «Милли байрак» гәзитен чыгаруда актив катнаша. Хәреф җыючы булып эшләүче Мансур гәзитне таратуда да башлап йөри. Соңрак өйләнеп Хайлар шәһәренә барып урнаша. Гомеренең соңы Төркиядә уза.

*137 бит.* **Минһаҗетдин углы. Мөхбир. Айсылу. Тукай көне.** «Милли байрак»ның 1937 ел, 24 нче (74) (7 май) санында «Минһаҗетдин углы», «Мөхбир», «Айсылу» имзалары белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Хатыйп хәзрәт Халиди* — Хатыйп Халиди (1893—1977), Хайлар шәһәрендә имамлык һәм мөдәррислек иткән. Икенче бөтендөнья сугышының соңгы айларында, инде Хайлар мәчете җимерелгәч, күпчелек татарлар әкренләп Төркиягә күчеп китә.

*138 бит.* **Үтәмеш. Айсылу. Киҗү мөхбире. Фозан мөхбире. Углан. Габдулла Тукайның 25 еллыгы.** «Милли байрак» гәзитенең 1938 ел, 20 нче (119) (6 май) санында «Үтәмеш», «Айсылу», «Киҗү мөхбире», «Фозан мөхбире», «Углан» имзалары белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Үтәмеш* — Рокыя Мөхәммәдиннең тәхәллүсе.Гәзиттә Басылган күп кенә мәкаләләрне үзенә язарга туры килгәнгә, туган авылы исемен (Тәтеш районы) тәхәллүс итеп ала. Бу гәзиттә язышучыларның азлыгына да бәйле. Истәлекләр шуны раслый.

*Ш.Мәрҗани җәнапларының вафатына 49 ел ...* — Ш.Мәрҗани (1818—1889) — күренекле татар мәгърифәтчесе, тарихчы һәм дин галиме. Аның үлеменә 1938 елда нәкъ 49 ел тула.

*Фозан-Туган* — Көньяк Кореядәге шәһәр. Кёнсан-Намдо провинциясенең административ үзәге.

*143 бит.* **Хәбәрче. Тампереда Тукай кичәсе.** «Яңа милли юл» журналының 1938 ел, 6 нчы (123) санында «Хәбәрче» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*145 бит.* **Яшь истикъляльче. Каһирәдә Тукай көне.** «Яңа милли юл» журналының 1938 ел, 6 нчы (123) санында «Яшь истикъляльче» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Әл-Әзһәрдә укучы* — Каһирәдәге Әл-Әзһәр мәдрәсәсе Идел-Урал мөселманнарына 1917 елгы инкыйлабка кадәр шактый еллар белем биргән. Алар арасыннан татар халкының күренекле шәхесләре үсеп чыга һәм XX гасыр татар мәдәниятендә әһәмиятле урын биләгән Яңарыш дәверен тудыруда үз өлешләрен кертәләр. Мөһаҗәрәттә яшәүче татарлар Әл-Әзһәр мәдрәсәсенә үз укучыларын белем алырга җибәрергә ирешә. Ерак Шәрыктән 10 яшьлек егет 1936 елның 9 июлендә пароход белән Каһирәгә юл ала. Финанс чыгымнарын җирле мөселманнар үз өстләренә ала. Ләкин матди ярдәмнең тиешле дәрәҗәдә булмавы сәбәпле, алар максатларына ирешә алмый калалар.

*... бөек төркче мәрхүм Йосыф бәк Акчура...* — Йосыф Акчура (1876—1935), сәясәтче, публицист, тарихчы. Гомеренең күп өлешен Төркия белән бәйләгән шәхес.

*146 бит.* **Мөхбир. Тукай көне. Харбинда.** «Милли байрак» гәзитенең 1939 ел, 23 нче (164) (21 апрель) санында «Мөхбир» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Сания Гыйффәт* — Кадыйрова Сания Хәбирҗан кызы (1899—1957), шагыйрь, драматург, язучы. Мөһаҗәрәттәге татар әдәбиятын әйдәп баручыларның берсе. «Яңа милли юл» һәм «Милли байрак» журнал-гәзитләрендә языша.

*Ниппон, Манҗу-Тиго императорларына* — Россиядә булып узган Октябрь инкыйлабыннан соң дөньяның төрле почмакларында озак еллар дәвамында бертуктаусыз баш күтәрүләр кабатланып тора. Бигрәк тә бу эшләр Ерак Шәрыктә еш кабатлана. Бер яктан Совет, икенче яктан Япония гаскәрләре Кытайга һөҗүм итә. 1931 елның ахырында Япония Төньяк-Көнчыгыш Кытайны басып ала һәм 1932 елдан Манҗу-Тиго дәүләте төзеп, аңа Цин династиясеннән Пу Ине император итеп куялар. Ул идарә иткән елларда Япония яклавы астында төрк-татарлар милли-дини оешмаларын барлыкка китерә, шактый гына уңышлы эш башкаралар.

*«Авыл хатынының бала тибрәтүдәге өмидләре»* — Тукай шигыренең исеме, тик «тирбәткәндә» урынына «тибрәтүдәге» дип язылган.

*149 бит.* **Мукденда.** «Милли байрак» гәзитенең 1939 ел, 23 нче (164) (21 апрель) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*150 бит.* **Мөхбир. Кобеда.** «Милли байрак» гәзитенең 1939 ел, 24 нче (28 апрель) санында «Мөхбир» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*151 бит.* **Мәхрүсә Вафа. Тампереда Габдулла Тукай кичәсе.** «Яңа милли юл» журналының 1939 ел, 5 нче (133) санында Мәхрүсә Вафа имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*«Әй мөкаддәс»* – Г.Тукайның «Өзелгән өмид» шигыре күз алдында тотыла.

*«Тукай маршы»н гаять моңлы иттереп җырлап...* — мөһаҗәрәткә китәргә мәҗбүр булган татар халкы Г.Тукайның «Туган тел» шигырен Тукай маршы рәвешендә җырлаган. Моны чит илләрдә яшәүче милләттәшләренең тарихын барлауга һәм өйрәнүгә күп көч куйган тарихчы Н.Дәүләт язмалары да раслый.

*154 бит.* **Берлинда Тукай кичәсе.** «Яңа милли юл» журналының 1939 ел, 5 нче (133) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*Гариф Кәрими* — Кәримов Мөхәммәтгариф Гыйльман улы (1887—1935), күренекле әдип, журналист, нашир Фатыйх Кәриминең бертуган энесе. Инкыйлабтан соң чит илгә китә. Мөһаҗирлектә яшәп килгән төрк-татар милли хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе. «Яңа милли юл» журналында эшли. Татарлар арасында ул «Госман» тәхәллүсе белән дә таныш. Варшавада үзенең квартирасында 1935 елда сәер шартларда үлә.

*155 бит.* **Хәбәрче. Хайларда Тукай көне.** «Милли байрак» гәзитенең 1939 ел, 48 нче (156) (13 октябрь) санында «Хәбәрче» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*156 бит.* **Тыңлаучы. Харбинда.** «Милли байрак» гәзитенең 1939 ел, 48 нче (156), (13 октябрь) санында «Тыңлаучы» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*157 бит.* **Габделкәрим Рәхим. Милли шагыйрьгә багышлап.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 18 нче (345) (1 май) санында Габделкәрим Рәхим имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*Габделкәрим Рәхим* — Сингишу шәһәрендә яшәүче төрк-татарларның имамы. Милли хәрәкәттә актив катнашкан.

*159 бит.* **Мәктәп мөхбире. Хайларда Тукай көне.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 19 нчы (346) (10 май) санында «Мәктәп мөхбире» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*161 бит.* **Мөхбир. Бөекләребезне искә төшергәндә.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 19 нчы (346) (10 май) санында «Мөхбир» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*162 бит.* **Манҗуриядә утыз еллык.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 19 нчы (346) (10 май) санында «Мөхбир» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*162 бит.* **Тукайның утыз еллыгы Синкин җәмгыятендә.** «Милли байрак» гәзитенең 1943 ел, 19 нчы (346) (10 май) санында «Мөхбир» имзасы белән басылган. Текст шуннан алынды.

*165 бит.* **Америка хәбәрләре.** «Казан» журналының 1973 ел, 10 нчы санында имзасыз басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды. Текст шуннан алынды.

*166 бит.* **Әмрулла Аги. Истанбул хәбәрләре. Тукай кичәсе.** «Казан» журналының 1974 ел, 12 нче санында Әмрулла Аги имзасы белән басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды. Текст шуннан алынды.

*166 бит.* ******* «Казан» журналының 1975 ел, 14 санында имзасыз басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды. Текст шуннан алынды.

*... рәисебез Әхмәтвәли Мәңгәр бәйнең...* — Ибраһимов Әхмәт Вәли улы (1891–1978), татар эшмәкәре, меценат, Ерак Шәрык милли хәрәкәтен әйдәп баручыларның берсе. 1938 елдан Төркиядә яши.

*167 бит.* **Әнкара хәбәрләре.** «Казан» журналының 1975 ел, 15 нче санында имзасыз басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды. Текст шуннан алынды.

*168 бит.* **Истанбул хәбәрләре.** «Казан» журналының 1975 ел, 15 нче санында Әмрулла Аги имзасы белән басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды. Текст күрсәтелгән басмадан алынды.

*168 бит.* **Истанбул хәбәрләре.** «Казан» журналының 1976 ел, 16 нчы санында Әмрулла Аги имзасы белән басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды. Текст күрсәтелгән басмадан алынды.

*169 бит.* **Җәүһәр Туганай. Финляндия хәбәрләре.** «Казан» журналының 1976 ел, 17 нче санында Җәүһәр Туганай имзасы белән басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды.

*Җәүгәр Туганай* — Ә.Кәримуллинның «Язмыш, язмыш» китабында Гәүһәр Туганай рәвешендә бирелгән, «Казан» журналында Җәүһәр буларак басылган. Җәүһәр Туганай (1911— ?), шагыйрә. Самарада туган. «Азат хатын» журналында (Казан, 1969) берничә шигыре басыла.

*Садри Хәмит* — Садри Хәмит (1905 — ?), шагыйрь һәм язучы. Чыгышы белән Россиядән, Яңапар авылыннан. Сәүдә белән дә шөгыйлләнгән. 1967 — 1977 елларда «Ак юл» гәзите чыгара. Бары 63 саны дөнья күрә.

*169 бит.* **Әнкара хәбәрләре.** «Казан» журналының 1976 ел, 18 нче санында имзасыз басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды.

*170 бит.* **Әмрулла Аги. Истанбул хәбәрләре.** «Казан» журналының 1978 ел, 22 нче санында Әмрулла Аги имзасы белән басылган. Төрекчәдән тәрҗемәне төзүче башкарды. Текст күрсәтелгән басмадан алынды.

*170 бит.* **Башкарма. Тукай.** «Яңа милли юл» журналының 1933 ел, 2 нче санында «Башкарма» исеме белән басылган. Текст шуннан алынды.

*«Ил» гәзитенең* — «Ил» гәзите С.-Петербург һәм Мәскәү шәһәрләрендә нәшер ителә. Бу очракта сүз 1913—1915 елларда Гаяз Исхакый һәм М.А.Мәүләмбирдиев (Нәҗип Гасрый) мөхәррирлегендә басылган «Ил» (С.-Петербург) гәзите турында бара.

*170 бит.* **Ил хәбәрләре.** «Яңа милли юл» журналының 1938 ел, 12 нче (128) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*Әхмәт Фәйзи тарафыннан «Тукай» исемле бер театр әсәре язылып...* — бу пьеса 1938 елда языла, 1939 елда Г.Камал театры сәхнәсенә Ш.Сарымсаков режиссерлыгында куела.

*171 бит.* **Тыңлагыз!** «Милли байрак» гәзитенең 1939 ел, 30 октябрь санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*171 бит.* **Тукайга багышлап.** «Милли байрак» гәзитенең 1939 ел, 48 нче (156) (13 октябрь) санында имзасыз басылган. Текст шуннан алынды.

*Әхмәт Фәйзи* — Фәйзи Әхмәт Әхмәтсафа улы (1903–1958), язучы, драматург.

*«...Совет әдәбияты» мәҗмугасының...* — «Тукай Җаекта» пьесасы журналда 1939 елның 3–4 саннарында басыла. Язучы әсәрне 1938 елда язып төгәлли. Бу драма (Тукай пьесасы белән бергә) Г.Камал театрында (1939 ел, 18 сентябрь; 1961 ел, 26 апрель; 1986 ел, 26 апрель) куела.

**ЭЧТӘЛЕК**


Кереш сүз. *Зөфәр Мөхәммәтшин* ..................

**I. Габдулла Тукай турында шигырьләр һәм мәкаләләр**

**М.Х.Ф.** Тормыш сагышы. *Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулды* ..................................

**Шаһвәли Келәүле Илдәр.** Габдулла Тукайга .............

**Солтан (Әхмәт Виргаз).** Тукай рәсеменә ...............

**М.Ф.**Тукай өчен ............................
**Солтан (Әхмәт Виргаз).** Шагыйрьгә .................
**Шаһвәли Келәүле Илдәр.** Тукай эзеннән ..............
Ил йолдызы ...............
**Сания Ишыкай.** Габдулла Тукайга 90 яшь тулу уңае белән ......
**Минһаҗ.** Даһи Тукайны искә алу ..................
**Гаяз Исхакый.** Тукай истәлеге. *Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә* ............................
**Шакир Йосыф.** Искә алганда. *Габдулла Тукайның үлүенә 20 ел тулу уңае берлә* ............................
**Гали Биктимер.** Эзләнгәндә ......................
Тукайны аңлар өчен .................
**Солтан (Әхмәт Виргаз).** Габдулла Тукайның үлүенә 22 ел тулу уңае берлә ...............................
**Рокыя Мөхәммәдиш.** Тукай көне ..................
**Хөсәен Габдүш.** Бөек Кушлавыч ятиме. *Шагыйрьгә 50 яшь тулу уңае берлә* ..............................
**Сәгадәт Чагатай.** Габдулла Тукай ..................
**Рокыя Мөхәммәдиш.** Тукайны искә алганда .............
**Хөсәен Габдүш.** Тукай — ил углы ..................
**Гаяз Исхакый.** Тукайның вафатына 25 ел тулу мөнәсәбәте илә ....
**Сәгадәт Чагатай.** Габдулла Тукай. *Үлүенә 25 ел тулу уңае берлә* .
**Хөсәен Габдүш.** Тукайсыз, Тукай берлә ..............
**Рокыя Мөхәммәдиш.** Илсезлектә Тукай белән...........
**Хөсәен Габдүш.** Тукай һәм яшьләр. *Өзек фикерләр* ........
Габдулла Тукайның 25 еллыгы ...........
**Рокыя Мөхәммәдиш.** Габдулла Тукай. *Вафатына 26 ел тулу уңае белән* .................................
**Мәдинә Салиәхмәт.** Тукайның мәгънәвияте әтрафына. *Габдулла Тукайның 30 еллык истәлегенә багышлап* ..............
Габдулла Тукайның мәгънәвияте әтрафыннан
**Надир Дәүләт.** Казан төркләре һәм Габдулла Тукай .........
**Әхмәт Тимер.** Габдулла Тукай. *Үлеменә 60 ел тулу уңае белән* . .
**Хөсәен Габдүш.** Нидән мин кечкенә «Апуш»тан бөек «Тукай» булдым? .................................
**Надир Дәүләт.** Габдулла Тукай шигырьләреннән үрнәкләр ......
**Шәмсия Апакай.** Мин Казанда ...................
**Надир Дәүләт.** Татар диаспорасы һәм Тукай ............
**II. Габдулла Тукайга багышланган кичәләр**

Тукай кичәсе ..............................
**Углан. Шагыйрь.** Матбугат дөньясында ...............
Халык җырлары һәм аның укымышлыларының идеалы .......................
**Харбин мөхбире.** Тукайның 50 яше ................
**Мөхбир.** Шанхайда истәлек көннәре ................
**Якташ.** Өч сәгать Тукай моңында ...................
**Мөхбир.** Тукай кичәсе ........................
**Минһаҗетдин углы. Мөхбир. Айсылу.** Тукай көне . ........
**Үтәмеш. Айсылу. Кижү мөхбире. Фозан мөхбире. Углан.** Габдулла Тукайның 25 еллыгы ....................
**Хәбәрче.** Тампереда Тукай кичәсе ..................
**Яшь истикляльче.** Каһирәдә Тукай көне ..............
**Мөхбир.** Тукай көне. Харбинда ...................
Мукденда ..........................
**Мөхбир.** Кобеда ............................
**Мәхрүсә Вафа.** Тампереда Габдулла Тукай кичәсе .........
Берлинда Тукай кичәсе ...............
**Хәбәрче.** Хайларда Тукай көне ....................
**Тыңлаучы.** Харбинда .........................
**Габделкәрим Рәхим.** Милли шагыйрьгә багышлап .........
**Мәктәп мөхбире.** Хайларда Тукай көне ................
**Мөхбир.** Бөекләребезне искә төшергәндә ..............
Манҗуриядә утыз еллык ..................
Тукайның утыз еллыгы Синкин җәмгыятендә ........
Америка хәбәрләре .....................
**Әмрулла Аги.** Истанбул хәбәрләре. Тукай кичәсе ..........
Әнкара хәбәрләре....................
Истанбул хәбәрләре ..................
Истанбул хәбәрләре ..................
**Җәүһәр Туганай.** Финляндия хәбәрләре ................
Әнкара хәбәрләре .................
**Әмрулла Аги.** Истанбул хәбәрләре ..................
**Башкарма.** Тукай ...........................
Ил хәбәрләре ..............................
Тыңлагыз! ...............................
Тукайга багышлап ...........................
Искәрмәләр һәм аңлатмалар .....................

Литературно-художественное издание

Составитель ***Мухаметшин*** *Зуфар Гумарович*

**Солнце народа. Габдулла Тукай**
**по материалам татарской эмигрантской печати**

Казань. ГУП Татарское книжное издательство, 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Төзүчесе ***Мөхәммәтшин*** *Зөфәр Гомәревич*

**Ил йолдызы. Татар мөһаҗирләре матбугатында**
**Габдулла Тукай**

Мөхәррирләре *Р.М.Кадыйров, Р.М.Касыймова*
Рәссамы *И.Р.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Г.М.Хәбибуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 31.07.2006. Форматы 84×108 1/32. Офсет кәгазе. «Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,08. Шартлы буяу-оттиск 10,50. Нәшер-хисап табагы 9,84. Тиражы 1000 д. Заказ 3-572.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.